# Шигырьләр һәм Поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010
УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Баш)-5
Т70
«Каләмнәр туганлыгы»
сериясе 1994 елда булдырылды.

*Роберт Миңнуллин тәрҗемәсендә*

**Тугызбаева, Ф.Һ.**

Су юлы : шигырьләр һәм поэмалар / Факиһа Тугызбаева; тәрҗ. һәм кереш сөз авт. Р.Миңнуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 239 б.
ISBN 978-5-298-01898-2

Күренекле башкорт шагыйрәсе, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Факиһа Тугызбаеваның бу китабына төрле елларда иҗат ителгән фәлсәфи, лирик һәм публицистик шигырьләре, поэмалары тупланды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Баш)-5

ISBN 978-5-298-01898-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Тугызбаева Ф.Һ., 2010

## Шагыйрәнең су юлы

Безнең татар укучысы Факиһа Тугызбаева исемен, бәлки, белеп тә бетермидер. Андыйлар булса, таныштырып китим алайса: ул – безнең чордашыбыз, замандашыбыз. Без бер үк елларда шигъриятькә килдек, бер үк вакытта матбугат битләрендә күренә башладык. Аннан соң инде бик күп сулар акты, бик күп җилләр исте, әллә күпме шигырьләр, җырлар иҗат ителде, бихисап күп китапларыбыз басылып чыкты. Исем-дәрәҗәләребез бар, ил алдында, халык алдында йөзебез пакь, күңелебез чиста. Тыйнак кына беренче шигырьләребез газета-журнал битләрендә дөнья күргән көннәр әле кичә генә шикелле...

Бүген инде Факиһа башкорт шигъриятенең иң актив, иң күренекле шагыйрьләреннән. Шагыйрьләреннән диюем бер дә юкка түгел, чөнки аның шигъри рухы, шигъри тукымасы, шигырьләрендәге образлары ничектер ирләрчәрәк килеп чыга. Ул – бик тә җитди, хәтта, әйтер идем, - артык җитди шагыйрә. Бу аның иҗатка мөнәсәбәтеннән дә, милләтпәрвәрлегеннән дә, иҗатының олылыгыннан да аермачык күренеп тора.

Ләкин ни генә булмасын, Факиһа – иң элек лирик шагыйрә. Күренекле башкорт шагыйре, минем дустым Хәсән Назар үзенең бер мәкаләсендә: «Дөньяда хатын-кыз әдәбияты дигән төшенчә юк, әмма әдәбиятка алар гына өсти алырлык затлылык, нәфислек бар. Әгәр без кайсы чакта хатын-кыз шигърияте дибез икән, тик алар гына нәкыш итәр нечкәлекләр, төгәллекләр һәм камиллекләрне күз алдында тотабыз», – дип язган иде. Мин бу үзекне нәкъ менә Факиһага багышланган булганга мисал итеп китердем. Чыннан да, аның иҗатын хатын-кыз күңеле генә тоя, хатын-кыз гына кичерә ала торган шашкын хисләрдән, нечкә тойгылардан башка күз алдына китереп булмый. Мәхәббәт давыллары, югалту ачылары, табышу куанычлары... Туган як яктылыклары, изге туган нигезне юксынулар, балачак хатирәләре, әнкәйләрне сагыну, олылау... Мондый шигырьләрендә лирик герой берчә нәни кыз балага, берчә гашыйк үсмер кызга, берчә мәхәббәтле хатынга, берчә бала җанлы анага әверелә.

Юкка гынамыни аның иҗатында кайчакларда Ахматова белән Цветаеваның алымнары, аларның чалымнары чагылып китә. Бу, минемчә, бик тә табигый, әмма Факиһа Тугызбаева чиста лирик яисә камерный шагыйрә генә түгел, ул – философ та, тарихчы да, публицист та, сәясәтче дә… Башкорт шигъриятендә Факиһа кебек тагын Тамара Ганиева да бар. Саллы, тирән, дуамал холыклы шагыйрә. Татарлардан, мөгаен, Лена Шагыйрьҗан шундыйдыр...

Әйе, Факиһаның иҗаты шактый киң колачлы, шул ук вакытта бик тирән тамырлы да. Бу – рухи киңлек, фикерләр, хисләр киңлеге, бу – тарихи тирәнлек, милли тирәнлек. Мин аны башкорт поэзиясенең иң матур традицияләрен армый-талмый дәвам итүче шагыйрә дип атар идем. Башкортның бөек халык иҗатына: эпосларына, кобаерларына, халык җырларына һәм тарихи риваятьләренә мөкиббәнлек, Акмуллаларга, Бабичларга, Мостайларга, Рәмиләргә якынлык, башкорт халкының рухи

яңарыш чорын, Башкортстанның мөстәкыйльлеген җаны-тәне белән яклавы, үзенең дә көрәшчеләр рәтендә булуы Факиһаның иҗатын тагын да зурайтып, тирәнәйтеп, киңәйтеп җибәрә. Ул үзен төрле жанрларда сынап карый. Поэмалар. Шәлкемнәр. Реквием. Дастан... Болары да аның файдасына. Ул – чын мәгънәсендә бүгенге чор шагыйрәсе. Олы шагыйрь фәкать шулай гына була ала, олы шагыйрь фәкать шулай гына яши һәм иҗат итә ала...

Факиһа, башкорт иленең олы шагыйрәсе буларак, үз халкының кайгы-хәсрәтләре белән, шатлык-куанычлары белән гомер кичерә. Аның сокландыргыч, тетрәндергеч шигырь юллары бихисап. Менә шундыйлардан бер генә мисал:

Һава калмаганда сулар өчен,
Су калмаган кебек уртларга,
Учак кына булып дөрләр идем,
Мәйданнарга чыгып, уртага,
Үз-үземне әгәр яндырудан
Халкым көнe булса яктырак.
«Сабыр төбе – сары алтын» дигән
Әнкәемме әллә хаклырак?

Нинди көчле, нинди кыю әйтелгән бит! Нинди фидакарьлек, нинди фидаилек! Ир-ат шагыйрьләрнең дә болай ук итеп әйткәннәре юк иде әле. Мондый асыл юлларны бары тик шагыйрәләр генә яза аладыр, күрәсең...

«Су юлы» лирик шигырьләр китабы булгач, мин инде бу мәкаләмдә аның олылар иҗатына ныграк тукталдым. Әмма ил, милләт алдында олы җаваплылык тоеп яшәгән Факиһа Тугызбаева олылар өчен иҗат итүче күренекле шагыйрә генә түгел, ә танылган балалар әдибәсе дә. Аның балалар өчен язылган бик күп проза һәм шигырь китаплары дөнья күрде. Бик күп шигырьләре, поэмалары мәктәп программаларына, башкорт, рус һәм татар телләрендә басылып чыккан дәреслекләргә, дәрестән тыш уку китапларына кертелгән. Ул хезмәт юлын да балалар матбугатында – «Башкортостан пионеры» газетасында һәм «Пионер» журналында башлаган иде. Аннары 1990 елда ул балалар өчен «Акбүзат» журналын оештырып җибәрде һәм әлегә кадәр шул журналны җитәкли. Башкортстан Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе рәисе дә ул. Башкортстан Язучылар союзы белән Балалар фондының идарә әгъзасы да. Җыеп кына әйткәндә, ул бүген – башкорт әдәбиятының әйдәп баручы әдибәсе дә, танылган җәмәгать эшлеклесе дә.

Факиһа Тугызбаеваның әдәби, мәдәни һәм иҗтимагый эшчәнлеген Башкортстан хөкүмәте һәм җәмәгатьчелеге дә югары бәяләп килә. Аңа әле 1995 елда ук «Фатыйхамны бирәм сиңа» дигән китабы өчен Башкортстан Республикасының Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Ул Россия Федерациясенең һәм Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дә, Рәми Гарипов исемендәге әдәби премия лауреаты да…

Факиһа Тугызбаеваның иҗатын миннән дә ныграк өйрәнүче, миннән дә ныграк белүче юктыр кебек хәзер минем үземә. Ни өчен дисәгез, менә ничә айлар инде мин аның әсәрләре белән яшәдем. Шигырь һәм поэмаларын кайта-кайта укыдым, ятышлы рифмалар юлладым, шигырь юлларын татарчага әйләндердем, сүзлекләр актардым, алардан башкортча сүзләрнең мәгънәләрен эзләдем, башкорт теленең тәмен, аһәңен торган саен ныграк тойдым, башкорт теле белән татар теленең уртаклыкларын да, аерымлыкларын да ныграк төшендем. Факиһа белән бергә башкорт дөньясыннан, аның борынгы чорларыннан, чал тарихыннан урап кайттым, Салаватлар, Акмуллалар, Бабичлар белән очраштым, яңадан бер тапкыр Башкортстанның очсыз-кырыйсыз, гүзәлләрдән гүзәл табигате белән хозурландым... Шагыйрә кичергәннәрне мин яңадан да әллә ничә тапкырлар кичердем, шагыйрә уйлаганнарны мин яңадан да кат-кат уйлап карадым. Факиһаның шигъри моңын, асыл шигърриятенең нечкәлекләрен тоярга, аңларга тырыштым. Аңладым да шикелле.

***Роберт Миңнуллин,***
*Татарстан Республикасының*
*халык шагыйре*

## Тарпаннар

Офыкка тоташкан даланың
Күренми иге дә, чиге дә.
Мин җилә̀м толпарда ай-һайлап,
Офыклар еракка чигенә.

Мин җиләм,
Күкрәккә капланып,
Җил исә, и исә каршыма.
Каршыма йөгерә кылганнар,

Каядыр ашыга-ашыга.

Чайкала, айкала җир өзе
Толпарым тоягы көченнән.
Көкләргә яшеннәр чәчелә
Көзендә уйнаган яшеннән.

Ашыккан кылганнар артыннан
Оча көк тарпаннар өере,
Тояктан чагылган чакмадан
Даланың көкрәген көйдереп.

Мин аумам, егылмам, югалмам,
Каршыма ыргыла тарпаннар.
Атканнар аларны,
Тик алар
Далада артканнан-артканнар.

Баш бирмәс, ут кебек киекләр
Ыргылыр, ыргылыр каршыма.
Тәбрикләр көкләрдә ал кояш –
Мин әзер яуларның барсына!

Кушылыр толпарым
Өере
Өермә чыгарган тарпанга.
Ялкынга ялкыннар кушылыр,
Тыялмас бернинди аркан да.

## Хәләл көчем

Сабыйлыктан чабып кына чыгып,
Ерак юллар кичтем, сулар кичтем.
Билгесез бу гомер сәфәренә
Ышандырды мине хәләл көчем.

Өзе бәхет – якты дөньяга мин
Сакламыймын кинә, юк бер өчем.
Кеше генә булып яшәр өчен,
Кешеләргә бирәм хәләл көчем.

Ваткан чакта төшен, чикләвек тә
Кан елата, шарт сындырып тешең.
Йомшаклык та, бәлки, төгелдер ул
Күз-яшь булып аккан хәләл көчем.

Мине сынап кына карарга дип,
Ходай бирә алтын һәм көмешен.
Сабыйлыктан һаман чыкмаганмын:
Җиңөләрем – минем хәләл көчем.

Мин сәфәрдә һаман,
Җир йөзендә
Бетмәгәнгә күрә өз өлешем.
Ташласа да дуслар,
Син ташлама,
Син ташлама мине, хәләл көчем!

Ашыкмый тор әле, гомер кичем,
Минем исем – эшем, уем-хисем.
Янганда да эчем,
Карашымда
Чагыладыр минем хәләл көчем.

## Очсызландык

Хаким хәзер галиҗәнап акча,
Хакы арта бара алтынның.
Җир маеның хакы – яшәө хакы:
Шуның өчен илләр сугыша бит...
Очсызлана бара акылым!

Аксакаллар хәер сораганда,
Акыл кирәк соң ул, йә, кемгә?
Талант илдә артык бер җан булгач,
Даһи әйләнә шул ятимгә,
Мохтаҗ булып яши тиенгә.

Намусның да төште чын бәһасе –
Очсызлана адәм баласы.
Чит-ятларга башкынаен сата,
Артмас микән диеп бәһасе,
Гали галим – илем агасы.

Очсызланмас өчен, әнә Пушкин
Дуэльләргә чыккан йөзгә-йөз.
Сөю хакы, диеп, гомер хакы;
Без бахырлар гына гел төзәбез,
Тезләр катып беткән тезләнеп...

Бала сөяр куллар сөялләнгән...
Ничек аңлатырга сөз белән?
Җанның ярасына сөртер идем
Коргаксыган кара җир маен,
Соранмыймын –
Якты йөзгенәм.

## Вакыт тамгалары

Туганымны бәхет итеп күреп,
Вакыт салган тәөге тамгасын.
Тупсасына дага каккан әткәй,
Догаларын укып исем кушкан,
Нәселемне, дигән, данласын!

Вакыт куласасы әйләндерә –
Тамгалары кала ярылып:
Әнкәемнең итәгендә идем,
Сабыемның җитәгендә хәзер –
Исемемнән генә танырлык.

Төссезләнә бара хыялларым –
Кояш ашый күзнең корычын.
Мин үземә-үзем ят тоелам,
Чын шикелле төгел өткәннәр дә,
Тик исемем менә, әйе, чын!

Яшен атамыни күтмәгәндә,
Вакыт сала һаман тамгасын.
Ә әткәем белгән исемемнең
Яшеннәрдән саклар кыя булып
Еллар өткән саен калкасын.

## Әүлия чишмә

Сине эзләп килдем, чишмәкәем,
Тау-таш ярып, кара урманга.
Ничәмә ел инде эзәрлекли,
Яннарымда әҗәл урала.

Учлап-учлап эчәм суларыңны,
Җаннарыма рәхәт тарала.
Битләремне юам...
Ә күзләрем
Ачылганнар әле кай ара?!

Әй чишмәкәй,
Суың сыгылып-сызылып
Ташлар астыннан да юл тапкан.
Җирнең җиде катын тишеп өтеп,
Агасың син хәзер улактан.

Чишмәкәем,
Өзең әүлиядыр,
Сакчысыдыр урман җанының.
Эчкән суларың бит юып алды
Сырхауларын хаста чагымның.

Чишмәкәем,
Өзең әүлиядыр,
Син исәнлек миңа телисең.
Суларыңны, зәмзәм суы күреп,
Килгән саен килә тәмлисем...

Синең кебек, мин дә минут саен,
Юк, юк, секунд саен үз-үземне
Өр-яңадан килә башлыйсым.
Гөнаһлардан килә котыласым,
Хаталарны алып ташлыйсым...

Тәңкә салам синең төпләреңә –
Төсем итеп сакла...
Ул – ырыс.
Әҗәл үзе кереп адашырлык
Карурмандай җаным тып-тыныч.

* * *

Сәнәгать тә сәнгать булса икән,
Нигә көйсез яңа бу сәгать?
Вәт тамаша:
Алдаша да тора,
Таба алмыйм җанга сәгадәт.

Чәбәләнәм,
Чәбәләнү – бәлам,
Балык кебекмен мин аудагы.
(Балык ише кеше туа җиргә,
Ниләр белән бетәр азагы?)

Ышандырган идем вакытымны,
Яңа сәгать син, дип, заманча.
Көннәр белән төннәр алмашынса,
Беләсеңме шуны: аң кача!

Заманымны гына кабатлыйсың,
Берни булмагандай, әй сәгать.
Ярый әле иман искерми дә,
Ярый әле көңел сәламәт.

Бармы икән соң ул Туфаннарның
Сәгать төзәтөче варисы?
Таба алсам берәр яхшы оста,
Бутамас та идем тарихны.

Алып чыккан Туфан төрмәдән дә
Имгәтмичә генә моң-җанын.
Табылырмы хәзер шундый оста
Төзәтергә заман ялгышларын,
Хаталарын шушы дөньяның?

Табышыгыз, зинһар, озак сузмый,
Мине яклый торган бер оста!
Кем кайтарсын кире?!
Гомеремне
Биреп бетерәм бит бурычка...

## Кырыслык

Несказанные речи
Я больше не твержу.

*Анна Ахматова*

Эчтән генә сызып яшимен мин,
Эчке монологны төшерсәң
Ак кәгазьгә, –
Том-том булыр иде,
Искергәнмендер шул, искерсәм.

Яшен белән яшен чәкәшкәндәй
Орыша да кемдер, оныта.
Ә мин тып-тынычмын.
Яши бирәм,
Әрнү салып җанга, гел утта.

Көңелемдә – әйтелмәгән сүз,
Әйтелмәгән рәнҗеш, аһ-зарлар,
Әйтелмәгән үгет-нәсихәтләр,
Әйтелмичә калган карарлар...

Тик берсен дә ертып ташлап булмый
Йә булмаса утка ыргытып.
Елмаюыма да яшерә алмыйм,
Бар булмышым минем – кырыслык.

Юк, кыргыйлык түгел,
Кырыслык мин –
Тәрбиясен биргән тау-ташлар.
Яратмыйдыр дип уйлама, Кешем,
Авыр булса минем карашлар.

**КӨҢЕЛ ХАЛӘТЛӘРЕ**

## Укучыма

Син дә, мин дә, Кешем,
Симфония
Иҗат итәргә без сәләтле.
Ноталарга гына төшерәсе
Күңелдәге һәммә халәтне.

Синең җаның кебек, минем җан да
Берчә тыныч, берчә давыллы.
Симфония дигән халәтеңнең
Аңлаучысын табу – авыры.

## Намус

Намымны нам иткән намусым,
Нанымны нан иткән намусым,
Каныма тоз салган намусым,
Намусым – иң тугры варисым.

Ниләр бар, ниләр юк күңелдә –
Казынам, казынам, казынам.
Мин сиңа тапшырам, намусым,
Сакларга бар җыйган хәзинәм.

## Илһам

Мин кычкырсам, җиһан җимерелер...
Сабырлык бир, димен Аллама!
Зыян гына килә күрмәсен лә
Йөрәк астындагы балама.

Кыл күпердән Ходай үткәрәдер,
Үткәрәдер бала тапканда.
Тулгак тота – шулай буладыр ул
Яшен аткан, елан чакканда...

## Өмет

Бар Өмете иде йортыбызның
Әниемнең бөртек угланы.
Таркалды шул нигез,
Ташлап киткәч
Теге дөньяларга туганым.

Бар Өметен эзләп йортыбызның,
Әни китте улы артыннан.
Әниемне аңласа да аңлар
Бала кайгыларын татыган.

## Фатиха

Менә-менә ярдан кузгалганда
Дәрьяларга алсу җилкәнең,
Исләреңә төште:
Өйдә калган
Тозың, суың һәм дә икмәгең.

Тоз, су, икмәк –
туган йортыңның ул
Сиңа фатихасы икәнен
Нишләп оныттың соң?
Кайтып әйлән,
Җилкенсә дә җилдә җилкәнең.

## Көнчеллек

Япь-яшь кенә шушы алмагачның
Ак чәчәкле иде язлары.
Ак ялкыны белән эретте ул
Кырауларны, соңгы карларны.

Алмагачны сары алган чакны
Карап торам әле боегып...
Әллә каян гына корт төшкән дә,
Алмалары беткән коелып.

## Дан

Елтыр-елтыр – күзне камаштыра
Әйбәтлеккә дигән күлмәгем.
Модадан да чыгып бара инде,
Ә хакын бит кыйммәт түләдем.

Ситсы күлмәгемә өйрәнгәчтен,
Кияргә дә аны оялам.
Аны кисәң, бизәнергә кирәк,
Тормышта мин сирәк буянам.

## Хәйлә

Акыл белән Хәйлә – бертуганнар,
Урал белән Шүлгән шикелле.
Урал җиргә үлемсезлек бирсә,
Акыл кеше итә кешене.

Көчле булмак булып кан эчсә дә,
Үч һәм Хәйлә генә Шүлгәндә.
Хәйләсе дә һич коткара алмый,
Ажгырыплар үлем килгәндә.

## Шатлык

Нигә эзлисең син борынгыдан,
Хомай кошның бүген мин үзе –
Кояш белән Сәмруг патша кызы,
Якты түгелмени көн йөзе?!

Син һаман да мин белгәнчә димә –
Күзләремә кара ихластан:
Күк капусын ачтым бүген үзем –
Сиңа бүләк итәм бер дастан.

## Кайгы

Баржа тарткан кебек, көн дә тартам,
Язмышмы бу, гади сынаумы?
Тартам да бит, алга китә алмыйм,
Аяк-кулым минем богаулы.

Богауларны чишеп ыргытырга
Тапчы, акыл, тапчы бер әмәл...
Алтыныңны сиңа бирәм, диеп,
Алларыма аумас Ирәмәл.

## Мәхәббәт

Эчәр суым – инешнеке,
Сулар һавам – ылысныкы,
Иккән икмәк – ырысныкы,
Гомер түгел бурычныкы.

Кочагыңа мин сыйганмын,
Кочагың, дим, бар җиһаным.
Газиз балам – сөюнеке.
Хыянәт тә безне күзли,
Ул хыянәт – диюнеке!

## Мәкер

Дустым яла язган югарыга,
Юк, куймаган имза, исемен.
Берни булмагандай елмая да
Какмый керә үзем ишеген.

Сунарчыдай артларымнан калмый –
Салган миңа бүре капкыны.
Җиңелрәк тә булыр иде, бәлки,
Күкрәгемә төбәп атканы.

## Бәхет

Иблис мине бермәл әй котыртты:
«Киеп ал, – дип, – матур битлекләр».
Ярый күреп калдым: аягында –
Измәңне дә изәр итекләр.

Каф тавына сыпырткандыр, ахры,
Үзеп әйткәч: «Барыбер мин ул – мин!»
Чал чәч төшкән чигәмдә бит менә
Туганымнан бирле шул ук миң.

## Зар

Кыңгыраулар какмасаң да була,
Тавышың, Зар, барыбер ишетәм.
Исәнләшергә дә онытып, син
Хәер сорап кердең ишектән.

Хәер таратырга яратсам да,
Акчам калмаган шул, Зар таныш.
Җиләк-җимеш утыртыйк әле без,
Бакчабызда миңа җир казыш!

## Горурлык

Яшьли генә тол калса да әни,
Ялгызлыкта яшен түкмәде,
Җан сакчысы иде Горурлыгы,
Тәмле иде шуңа икмәге.

Урамнардан балкып килгән чакта,
Карый иде ир-ат борылып.
Китсә дә ул якты дөньялардан,
Исем-атын саклый Горурлык.

## Укучыма теләк

Мин тик башын яздым бу әсәрнең –
Иҗат итәрсең син дәвамын.
Ихлас хөрмәтемә хөрмәт кенә,
Рәхмәт кенә булса җавабың.

Күрмәсәм дә сине, без күптән дус,
Аркадашым, тугры сердәшем.
Нота станына тамар микән
Йөрәк каның яки күз яшең?

## Сөйләшәмен Кояш телендә

Әллә ничә гасыр авырлыгы
Белән басасың син йөрәккә,
Акылыңнан язып әфьюннан,
Әйләндермәкче син өрәккә,
Әй заманым!

Баткан Кояш кире чыга бит ул,
Күк йөзендә телем ачылган.
Шуңадыр да күңел күзем күрә,
Ниләр кичерсәм дә башымнан.

Ашыктырма, заман, кан тибешен,
Вакыт кебек булсын табигый.
Ышанмасаң ышан:
Мин үзем дә –
Акыл белән йөрәк табибы.

Сөйләшәмен Кояш телендә мин,
Нур телендә һәм көн телендә.
Заман үтә,
Бары Кояш кала,
Яктыртканга күңел төбендә.

Аралашам Кояш телендә мин,
Йөзем якты, якты күңелем.
Тайфуннарың котырса да,
Заман,
Мин бит күрәм дөнья киңлеген.

Мин бит күрәм тарих киңлекләрен –
Шуңа күрә башым югары!
Әйтерсең лә җирне тотып торган
Урал батырның мин сыңары.

## *XX* гасыр белән хушлашканда...

Шәрабымнан каным кайнарлана,
Комач-кызыл бәллөр бокалым.
Яңа гасыр туа карыныңнан,
Бишек җырын аңа сакладым,
XX гасыр!

Мин тынлыкта аны җырлар идем,
Иркенәер иде сулышым,
Син өзеңә алып калсаң әгәр
Җир тетрәткән барча сугышың,
XX гасыр!

Туган башын туган ашады бит,
Ачлыгың да булды сәясәт.
Баткан кояшыңның шәфәгы да –
Инкыйлабтай кызыл җәрәхәт,
XX гасыр!

Тик нишлисең,
Бөтән язмышым юк –
Күңелемдә сине саклыймын.
Синең җырларыңны җырлыймын мин,
Синең шигырьләрне ятлыймын,
XX гасыр!

Бөтән илем дә юк –
Үземнеке,
Халкымныкы яхшы, яманы.
Син бит барлык гарасатны җиңгән
Иманымның имин-аманы,
XX гасыр!

Синдә тапкан бөтен хәзинәмне
Балаларым өчен сакладым.
Исерсәм дә,ниләр кичерсәм дә,
Бетергәнче эчәм бокалым,
XX гасыр!

* * *

Сабантуйдан башын алып качты
Бәйгедә ал бирмәс акбүзат.
Торып калды күпләр авыз ачып,
Бәйрәм иткәннәрдер, аһ, озак.

Искә килгән чакта исерекләр,
Акбүзаттан җилләр истеләр,
Ачы өкенечкә әйләнде дә
Ерак хыялларга күчтеләр.

Бер талпынса – суның төбендә, ди,
Бер талпынса – күкнең түрендә,
Ди кобаер аның турында,
Ул, ди, бәхетлегә күренә.

Ыжгырыплар җилгән акбүзатка
Елгыр гына сала иярен,
Үер-үер елкы белән бергә

Ай-кояш та аңа иярсен!

...Ап-ак ялкын булып ялкайлары,
Кая җилә икән акбөзат?
Ирек – булмышлары!
Иркен – сулышлары!
Вакытнымы була ул узмак?

Күренгәндәй булды акбөзатның
Тик шәөләсе генә аръякта…
Ак сурәте җилдә ятимсери
Сабантуйдан калган байракта.

## Һава монологы

**1**

Кеше күзләреннән, сүзләреннән
Саклап баскан тавым, урманым.
Ялгыз Һава шулай яшәгәндер:
Өләннәрдән куыш корганмын.

Атып бәрдем көйсез җәмгыятьнең
Тораташлар иткән бар йөген.
Җан кергәндәй була –
Чишмә суын эчсәм,
Табигатькә бала мин бүген.

Күк йөзендә мең-мең йолдыз авы,
Айый алар минем оямны.
Колакларым тонган моңсыз җырдан,
Тыңлыйм әле яңгыр койганны.

Күзем талган нурсыз карашлардан,
Чәчәк бага – сафлык, сабыйлык!
Нигеземә кот китерә тузбаш,
Еланнар юк монда чагарлык.

Күрсә икән ташлар атучылар
Алма коелганны юлыма!
Әйтерсең лә сөю алмалары,
Кояш балалары кулымда.

Алма коелганны ишетер дә
Эзләп табар әле Адәмем.
Куа чыкмас борын албасты күз,
Яшәп калыйм әле җәйдә мин.

**2**

> Имеш, сине Ходай яраткан, ди,
> Чалыш кабыргадан...
>
> *Мостай Кәрим*

Кабыргадан яралган, ди, Һава...
Шул да булган икән риваять!
Рәнҗетмәгез мине,
Китим әле
Ялтылган көнгә җәяөләп.

Җирнең катламнары – шәҗәрәм ул,
Уй-зиһенем җитә ачарга.
Тарих төпләренә төшим әле,
Гасырлардан алыс гасырга.

Мәңгелеккә шаһит Кояш әйтер:
«Һавадан ул бәхет, бар оҗмах.
Ул оҗмахны җиргә алып төште,
Җәннәтләрдән үзе куылгач.

Сөю хакын хаклап, гөнаһтан да
Курыкмыйча, җиргә сөрелде.
Адәмнең дә өзен ул ир итте,
Ул гөл-бакча итте җиремне...

Кешенең дә Һава күзен ачты,
Телен ачты, назлап, көй көйләп.
Ул үзе дә нурдан яралгандыр,
Мондый көч соң каян ул килмәк?

Ир патшаның башын чабып өзгән
Түгелме соң инде Тамарис?
Кая барса, шунда көн башлана,
Күңелләргә нурлар тама ич.

Тайфун-тайфун гаскәрләре белән
Җир йөзләрен баскан патшалар
Аны яратудан алларына
Тезләнепләр килеп басалар...»

Бүгенгем дә шәҗәрәмә торыш,
Арткан гына дәртем-дәрманым.
Оҗмахлыгын саклап җир йөзенең,
Киләчәккә китеп барамын.

Кочагыма алам барыгызны,
Мин – әҗәлнең генә дошманы.
Ходай әмередәй изге миңа
Әнкәемнең бөтен кушканы.

Кабыргадан яралтылган, имеш...
Сөйләмәгез дөрес булса да.
Һаваланып әйтүләрем түгел:
Сезнең сулышыгыз мин – Һава!

**САЛАВАТНАМӘ**

## Юрүзәндә июнь пейзажы

Уйсыз тирбәләмен мин бишектә –
Дулкын чайкалдырган көймәдә.
Исең китмәсен лә, күңелкәем:
Дулкынланма да син, көймә дә.

Йөзә бирәм агым уңаена,
Баш очымда кояш курчалый.
Барыбер лә миңа –
Бишегемне
Яшен ярганда да урталай.

Камышлыкта балык кармаклаган
Малайларның күзе судадыр.
«Ачыктым!» – дип өйгә йөгергәндә,
Артларыннан тузан тузадыр.

Су буена төшкән йөк атлары
Эсседән һәм эштән йончыган.
Баш та бормый алар минем якка,
Бизгәннәрдер миндәй юлчыдан.

Йокымсырый бирә бериш өйләр,
Тын да алалмыйча эсседән.
Су эчендә берни булмагандай
Басып тора әнә өч чилән.

Минем уяулык та черем итә –
Өскә ишелмәкче тау-кыя.
Су карала таулар шәүләсеннән,
Кинәт кенә көймәм янтая.
Юрөзәннең чишмә кебек тыныч,
Берчә шарламадай агымы.
Кыя башларыннан очып төшеп,
Чәчләремә җилләр кагылды.

Урманнарда йоклый бирегезче,
Сез тимәгез, җилләр, теңкәгә.
Алмаштырмам сабыр бу көймәмне
Канатларын җәйгән җилкәнгә.

## Тамырлар

Юрөзәннең ярын язгы ташкын
Кисеп алып суга ташлаган.
Шәрә тал тамырын елга юа,
Туфрагыннан юа, ташлардан.

Биек ярга эленеп калган талны
Тартып алыр инде җил-давыл.
Өянкегә кунган карга гына
Кычкырадыр миңа: «Каравыл!»

Кычкырсаң да, ташкын үткән инде,
Яраланып беткән тамырлар.
Елан кебек бормаланып, алар
Җәһәннәмгә таба агарлар.

Вакыт!
Вакыт!
Тыныч дигәндә дә,
Утлы гаскәр бит син, әй ташкын.
Нәсел тамырларым гасырлардан
Актарылып куйса, мин – таш сын.

Актарылып куйса ак тамырым,
Каршы тора алмый ташкынга...
Теге талның елан-тамырлары
Үрмәләгән кебек башыма.

## Тавыш бирче, Салаватым!

Сине эзли җаным, Салаватым,
Чакырды бит мине Юрөзән.
Ничек әле аны күрмәгәнмен,
Ничек әле ансыз йөрелгән?

Юрөзәннең тонык көзгесенә
Карый-карый, чәчем тарадым.
Юрөзәннең матур чәчәкләрен
Мин таҗ итеп киеп карадым.

Салаватның, әй, кыз туганнары
Яндырылган монда утларда.
Ә җаннары күчкән каеннарга.
Менеп баскан алар тау башына
Яңа көннең тууын котларга.

Әверелгән, диләр, бәллүрләргә
Аналарның ачы күз яше.
Мәгарәдән, батыр, хатирәңне
Кулымдагы шәмем эзләшә.

Янгантауның сүнмәс утларыннан
Ут алгандай җирдә тәү адәм,
Җирдә калган синең эзләреңә
Күч алырга диеп тезләнәм.

Уралтауның туңмас чишмәсенә
Су эчәргә диеп иелдем:
Синең йөзең чагылгандай булды, –
Бер сөендем мин, бер көендем.

Тавыш бирче, батыр, күк таулардан,
Ишетим бер курай моңыңны.
Бөркетләр дә оча алмый торыр,
Күреп калса синең сыныңны.

Әйләнәмдә кешнәп тыпырчына
Сиңа саклап торган бу атлар.
Тавыш бирче, батыр!
Дертләп китсен
Тау битендә яткан быуатлар*.

## Салават кылычы

Музей кинәт дертләп китте кебек,
Яшен яшьнәгәндәй якында.
Күз алдымда йөзе ялтырады –
Суырылган кылыч, аһ, кыннан.

Салаватның булат кылычы бу!
Батыр кылычы бу!
Күр әле!

Ул өр-яңа һаман.
Кирәк икән,
Дошман башын чабып өзмәле.
Салаватның даны сөнмәгәндәй,
Төшмәгән бу кылыч куллардан.
Кылыч өткән, ут-суларны кичеп,
Башкорт өткән бөтен юллардан.

Балкып тора аның ак йөзендә
Көч-куәт тә, ялкын-дәрман да,
Өткерләнгән кылыч
Француз явын
Парижгача куып барганда.

Каны белән раслый яугир башкорт
Рәсәенә биргән һәр антны.
Өлгәндә дә кылыч тотып өлә
Алышларда башкорт солдаты.

Кырык бердә безнең атайлар бит,
Ватан кушты, диеп, ил кушты,
Аждаһадай дошман танкына да
Кылыч белән каршы сугышты.

Салаватның изге ак кылычы
Һаман өткен, һаман өр-яңа.
Башкорт җанын саклый афәтләрдән,
Дәһшәт чәчеп тора дөньяга.

## Туу

*(Поэма)*

Һәр тарафта
　　бөек таш стена
өскә авып бара.
Алар арасында –
　　җир кисәге,
өлән өсми,
җир яргаланган.
Кая карама:
җирдә,
　　тәндә,
　　　　йөрәктә яра.
Зәңгәр күк кисәге
　　баш очында,
кояшы юк,
йолдызлары сирәк;
күрәсең,
　　бу стеналар
кешенең кешелеклелегеннән,
кояштан да биегрәк. –
Дөнья шулай
стеналар белән чикләнгән,
ичмасам,
җил дә сыйпамый чигәдән.

Кул богаулы,
аяк богаулы,

тел кыркылган,
күзен исән калдырганнар,
газапларны,
мыскыллауларны күрсен өчен, –
палач, шулмы синең көчең?..

Йөрәге тибә,
рухы исән,
зирәк акылы –
димәк, буш түгел әле кыны.

Ятар да өләр иде
шушы таш стена арасында,
данласыннар яки каргасыннар –
барыбер түгелме?
Барыбер түгел, күңел!
Өлә җиңел...
Көлгә очты карурманнар,
көлгә очты тоташ авыллар,
канга батты җир.
Ирмен дигән ир,
халкын кыл өстендә калдырып,
теге дөньяга китә аламы?

Ул әле яшәячәк!
Мөһерле маңгаен
югары күтәреп яшәячәк!

Кулы богаулы,
аягы богаулы,
теле кыркылган
килеш тә аның яшәве
намусының аклыгын,
көрәшенең хаклыгын раслый.
Үзенең кылганнарыннан
курыкканнар гына өлә,
тере килеш өлә.

Әлегә ул дөнья белән
богавын чыңлатып хәбәрләшә.
Шушы чың,
таш стена аша чыгып,
кошларга ишетелер.
Ә алар рух чыңын
туган җиргә җиткерер:
Салават тере, тере!

Тарих төпкеленнән бүгенгегә
калыкты салават күпере!

...Уйларым үзелде...
Мин үзем дә әле чак тере,
кояшны кайчан күрермен,
сизмичә оран саламын,
ике кеше өчен тын аламын:
үзем өчен,
туар балам өчен.
Колагымда чыңлый
Салаватның богау чыңы –

саташаммы, әллә чынмы?
Ярсып-ярсып,
миңа диңгез дулкыннары ташлана –
Балтыйк диңгеземе?
Йотмакчымы әллә
минем йортым-нигеземне?
Диңгез белән алышамын
бар көчемә:
аягым,
кулым,
йөрәгем,
акылым
көрәшә.
Ак көлмәкле бер фәрештә
юата мине:
«Тулгак тота, сабыр бул!»
Пышылдыйммы аңа:
«Рәхмәт!..
Шат яшә...»

Каным тамды,
тамды яшем...
Мин дөньяга эндәштем:
«Балам туды,
ба-лам!» –
Рәхәт, иркен тын алам.

...Диңгез тынды,
курай тавышын ишетәм,
кушылып көйлим:
«Бишектә
Салават токымы.
Салават һаман яшәячәк,
Салават мәңге яшәячәк!»

Котлап мине,
чәчәк бирә дуслар,
чутылдаша кошлар...

Күктә кояш,
шатлык йөрәктә.
Сабыемның
яңа җилкән кебек ак бишеген
саф өметем, газиз әниемдәй:
«Үс-үс, балам!» – диеп тирбәтә.

## Иҗат

Шагыйрьләргә шәп шигырьләр килә,
Йоклаганда төнен кешеләр.
Галимнәр дә зур ачышлар ясый,
Черем иткән чакта өчлеләр.

Әйтерсең лә бар дөньядан качып
Иҗат итә җирдә талантлы.
Калыпларны чишеп ыргыта да,
Читкә олактырып таләпне.

Төнге караңгылык һәм тынычлык –
Талантларга насыйп иреклек.

Әрвахлар да ярдәм иткән кебек,
Куәтләгән кебек тереклек!

Күк капусы гөя ачылгандай:
Фикер өткен, зиһен куәтле...
Ә шигырьләр барыбер кояшлылар,
Ачышларда – яшәү кыйммәте.

## Иртәрәк тә түгел, соң да түгел...

*Каләмдәшем Равил Бикбаевка*

Иртәрәк тә түгел, соң да түгел –
Тудырган бит заман сине белеп.
Синең хис һәм акыл кушылганга,
Син яшәгән заман үзе бөек.

Иртәрәк тә түгел, соң да түгел...
Син – җиңүче көрәш мәйданында.
Сиңа карап илне таныйлар бит,
Йөрсәң дә син, шагыйрь, кайда гына.

Берчә баллар, берчә каннар тама
Очларыннан очлы каләмеңнең.
Иртәрәк тә түгел, соң да түгел –
Шагыйрь булып мәңге кала белдең.

Иртәрәк тә түгел, соң да түгел –
Каһарман ир илгә бүген кирәк.
Синең хисең, синең акыл белән
Бөек халкым тагын да бөегрәк.

## Кояшлы каләм

Тезеп-тезеп мин язганга
Шар ачылды сабый күзе –
Аяз күктәй зәңгәр күзе,
Карап торып чак-чак түзде.

И оныгым-оныккаем,
Язмаларны сызды куйды.
Сызды минем кайгыларны,
Сызгалады бөтен уйны.

Чәчәк исе чәчләрендә,
Кулкайлары аның сөтле.
Ертып ташлады оныгым
Күз яшьләрем тамган битне.

Язмаларымның өстенә
Төшерде ул чәчәк, кояш.
Дөньяларым чәчәк кенә,
Кояш кына хәзер тоташ.

Сабыемны чөйдем күккә:
«Үс-үс, балам, үс-үс, балам!»
Телләремдә – бал тәмнәре,
Сүзләрем дә татлы балдан.

Сабый көлә,
Мин дә көләм:
«Яхшы иттең әле, балам!
Кулларыма, синең кебек,
Мин кояшлы каләм алам!»

## Мөхәррир

Баш мөхәррир вазифасы
Дәрәҗә түгел, язмыш.
Ялгышса да бер өтергә,
Җир шарыбыз кинәт кенә
Шартларга да мөмкин ялгыш.

Төзәтә ул хаталарын
Патшаларның, яранның –
Җир йөзендә күпме алар,
Меңәрләгән, әй Раббым!

Галимнәрнең формуласын
Раслап куя култамга.
Философларның ялгышын
Иң беренче ул таба.

Кеше хакын хаклау гына –
Аның иң төп бурычы.
Укый-яза, эрегәнче
Күзләренең корычы.

Компьютер да, интернет та
Аннан акыллы түгел.
Булса икән ул аларда
Мөхәррирдәге күңел?!

Мөхәррирдәге кешелек,
Андагы олы йөрәк!
Ул берүзе булганда да
Бөтен җиһанга терәк.

Йөрәге дә шартлап куя,
Булсын, диеп, ил имин.
Мөхәррир – намус үлчәве,
Хаклык үлчәве, димен.

* * *

Шундый бер көн килер сиңа, җаным:
Ай йөзендә мине күрерсең.
Очып җитмәс күккә талпынудан
Син нишләргә белми йөрерсең.

Шундый бер көн килер сиңа, җаным:
Су йөзеннән сиңа карармын.
Юксынсаң да мине,
Дәрьялардан
Эзләп табалмас шул корабың.

Шундый бер көн килер сиңа, җаным:
Һәр күзгедән сиңа багармын,
Күз карашым белән чакырырмын,
Күз карашым белән чагармын.

Шундый бер көн килер сиңа, җаным:

Сөймәгәнгә кабат сөйкәлмәм.
Хуш, бигайбә!
Әйдә, карап кал син
Тәкәбберлек дигән һәйкәлдән.

* * *

Мөлдерәпләр миңа карамачы!
Башларымны иеп өтенәм.
Бер-беребезне яңа тапсак та без,
Өтеләсе юллар өтелгән.

Яшәләсе еллар яшәлгән шул,
Ышансак та һаман тылсымга.
Сөябез дип көпме алданганбыз,
Хыялларны санап чып-чынга.
Бәлки, синдер ул чын мәхәббәтем,
Синнән кадерлерәк кешем юк...
Йөрәгемдә сине йөртер өчен,
Йөрәгемнең генә көче юк.

* * *

Бу галәмдә әгәр Ходай булса,
Өзгәләнгәнемне күреп торса,
Очраштырырга ул безне тиеш,
Калган булса әгәр Ходай килеш.

Гөнаһларым булса, ярлыкар ул
Минем сөюемнең хакларына.
Ходаемның мәрхәмәтен сорап,
Бәгырьләрем минем актарыла.

Ышанмаса Аллам, сыный бирсен
Оҗмахында яки тәмугында.
Очраштырсын ләкин кайчан да бер,
Күзкәйләрем сине таныганда.

Дөньялыкта җанны кавыштырсын –
Шундый сәгать миңа насыйп булсын!
Әгәр мине аңлый алмый икән,
Ходай үзе үлеп гашыйк булсын!

## Гомер музыкасы

Гаепләргә җыенмыймын беркемне дә,
Күңелләрем менә кинәт җилпенде дә,
Балачакка алып кайтты быргы тавшы –
Быргы тавшы үзе ярсу, үзе ачы.
Өйрәнсә дә ярты-йорты ертык көйгә,
Чакырды ул кабаланып якты көнгә.

Яшьлегемдә өрә каттым мин гимннан:
«Кешелеккә мәңгелек дан! Илемә дан!»
Парадларны барабаннар гел башлады,

Ишетмичә курайчыны йә башканы.

Гомер өткәч, белеп калдым әле ялгыш:
Скрипка икән лә ул минем язмыш!
Көн нурларын кылы итеп уйный-уйный,
Бер дә тынмый: елап туймый, уйлап туймый.

Уйныйдыр ул Илаһ миңа язган көйне,
Еласа да, моңнарының якты йөзе!

## Шәҗәрә

Ничек бармын, шулай яшимен мин –
Һәрбер көнем шундый кадерле:
Сабыр акыл бирә әнкәемнең
Җиргә сеңә барган кабере.

Балакаем бирә миңа өмет,
Атар таңнан хыял иткәнне:
Гомеркәйләр агымсу булса да,
Тоям кызым белән өскәнне.
Уйга талам зиярәт кылганымда,
Акыл – шәҗәрәмнең тамыры...
Бәби кочаклаган кыз баламның
Йөзләрендә балкый таң нуры.

## Су юлы

Авыл очы – чаукалык,
Чаукалыкта – бар халык.
Киленнәр су юлы башлый,
Хәер-фатиха алып.

Шарламасы шарлама да,
Сикерә таштан ташка.
Тауларга китә авазы,
Урала һәр агачка.

Шарлама ыргый кыядан,
Йөгерә уйсулыктан.
Тешне камаштыра суы,
Көч аласың суыктан.

Әнкәйләр шарлама суын
Тоталар чәйгә генә –
Мәтрөшкә чәен эчтеңме,
Яшисең җәйдә генә.

Авыл очы – чаукалык,
Чаукалыкта – бар халык.
Җир җиләге чәчәк ата,
Хуш ис киткән таралып.

Каенның яшь яфраклары
Талымланып торган чак.
Мең-мең төрле чәчәк-өлән
Тамырланып торган чак.

Сирпеп сулар ала килен,
Талмасын беләккәе.
Белэгенә чыдар ла ул,
Талмасын йөрәккәе!

Киявебез бөркет икән,
Чит-ят тимәс киленгә.
Киявебез алып төште
Киленкәйне биергә.

Бие, килен! Бие, кияө!
Такмак әйтә җиңгиләр.
Шарламаны алтын-көмеш
Тәңкә белән бизиләр.

Бөләксез калмый беркем дә,
Һәркемнең өз өлеше:
Һәркемнең өз алтыны ла,
Һәркемнең өз көмеше.

Кызларга – алтын тарак ла,
Йөрсеннәр чәчкә кадап.
Ә егетләргә – сөлгеләр,
Сабантуйда җиңсеннәр.

Әнкәйләргә – шәльяулык,
Телик исәнлек-саулык!

Килен бөләкләр өләшә,
Кемнең килмәс аласы!
Соклана ил агалары,
Соклана ил анасы.

Килен китте вак-вак атлап,
Иңнәрендә – көянтә.
Аксакаллар дога кыла,
Әбиләр теләк әйтә.

Юлына гөлләр сибелә,
Җыр сибелә юлына.
Таш булып батсын киленчәк
Бер төшкән урынына.

Итәк тулы балалары
Тупылдап туып торсын.
Тупылдап өсеп торсын да
Өзләре оя корсын.

Авыл очы – чаукалык,
Чаукалыкта – бар халык.
Сөенче ала малайлар,
Киленнән алда чабып.

## Хатын

Вакыты юк.
Кычкырмас ул:
«Яратам, – дип, – сине, халкым!»
Тик өзеннән өстен куяр
Халык хакын, милләт хакын.

Халык әйткәнгә ышана:

«Ирләр – баш ул, муен – хатын».
Көчлемен, дип аһ та ормас,
Хаклаганга ире хакын.

Көчсезмен, дип тә тормас ул,
Санлаганга бала хакын.
Җир бишеген тибрәтә ул,
Акыллары булгач алтын...

Гомерле син, туган халкым,
Хаклаганга ана хакын:
Сиңа иман, намус бит ул –
Әсәй! Әнкәй! Инәй! Хатын!

## Балага әйткән сөзләр

Иң акыллы сөзләр эзли-эзли,
Сабый күңеленә саламын.
Гомер сәфәрендә юлдаш булсын,
Киңәшчесе булсын баланың.

Аңлата да тора тормыш үзе:
Горур сөзләр – күңел калканы.
Мин аларны төннәр буе сайлыйм,
Сизелми дә таңнар атканы.

Гап-гадәти, күнегелгән язмыш:
Яратканым өчен халкымны,
Сабый күңеленә чәчкән сүзем
Булсын утлы, булсын ялкынлы!

Кешелекле булсын әйткән сүзем,
Бәләкәчкә куйсын пар канат.
Антлар биргән сүзләр генә түгел,
Гади сүзләрем дә – әманәт.

Нурлы сүзләремне әйткән саен
Әй яктыра бара күңелем.
Үстерә бит сабый белән бергә
Туган телем мине – моң телем.

* * *

Җир-сугынам минем,
Җирсөләрнең
Башларымнан гына ашканы.
Җәннәттә дә җанга ямь табалмам,
Үз италмам синнән башканы.

Артык итеп тоям мин үземне,
Яратса да мине башкалам.
Асылының кыргый дулкынына
Колачларны җәеп ташланам.

Менеп басам тагын Балкантауга –
Башын иеп кала кылганнар.
Уклы кылган, әрсез әремнәр дә –
Һәммәсе дә миңа туганнар.

Танышы да, таныш түгеле дә
Үзелепләр әйтә: «Туганым!»
Беркемгә дә мине охшатмагыз,
Мин җиремә охшап туганмын.

Маңгай белән ташлар ярганда да
(Соң булса да шуны аңладым),
Өзем менеп баскан Балкантаудан
Мин биегрәк була алмамын.

Таптырмагыз миннән даладагы
Җан өшеткеч кырыс ялкынны.
Асылының тирәнлеге миндә,
Каннарымда аның салкыны.

Тормый миннән беркем, бернәрсә дә
Изгелеге өчен хак сорап.
Кирәк чакта дәва миңа какы,
Чишмә суы, хәтта аксыргак.

Җиргә ятам –
Карашларым күктә,
Кояш булып җиһан төбәлгән.
Түбәндә дә түбәнчелек түгел,
Чишмә җыры килә түбәннән.

Дулкынланам басу дулкынында –
Күз күреме җитмәс диңгезем.
Алтыннарын каккан шул диңгезгә
Күңелләрем белән игезмен.

Яланнарым, сезгә кайтам бит мин,
Балачакка кайтам, узганга.
Батып киләм чәчәк тузанына,
Кулым бирәм кулын сузганга...

Мәрмәр баскыч, көмеш манаралар...
Ул минеке түгел, башкалам.
Сагынганда җанны имләр өчен,
Асылыга төшеп таш алам.

## Каенлыкка кайтам

Өмет бар бит әле тере җанда:
Чит якларда йончып йөргәндә,
Өзәкләргә өтсә бериш көннәр,
Ватан ни икәнен белмәс җилләр,
Каенлыкка кайта күңелләрем,
Каеннарым – тугры сеңелләрем.

Каен арасында мин дә каен,
Яфрак ярам мин дә һәр яз саен.
Миндә күпме сабый кояш уйный,
Миндә күпме кош баласын сыйлый.
Ургып чәчәк ата җиләклекләр,
Озын гомер тели бар кәккүкләр.

Күңелләрем кайтса дусларымнан,
Икмәк төшеп китә кулларымнан,
Бетәмени җирдә тормыш яме,
Табигатьтә һәрни кеше җанлы,
Каенлыкка кайта җанкайларым,
Каеннарым – газиз әнкәйләрем.

Каен арасында мин дә каен,
Яфрак ярам мин дә һәр яз саен.
Мин яшимен – тагын яфрак коям,
Яшел иде, хәзер сары дөньям.
Саргаюым – кояш сарысыннан,
Яшәө көчле, көчле барысыннан.

Шатлыгымны кемгә өләшергә,
Көлә-көлә генә сөйләшергә?
Бәхетемне кемгә таратырга,
Онытылып китеп яратырга?
Каенлыкка тарта аякларым,
Каеннарым – ап-ак маякларым.

Табигыйлек монда, юк тамаша,
Ап-ак сафлык монда күккә аша.
Югалтмагыз язмыш тарафында,
Мин яшәрмен каен арасында,
Күз яшьләрем татлы, якты кайгым.
Каен яннарында мин дә каен.

## «Калдырмагыз безне!»

Шагыйрьләр Тамара Искәндәриә,
Хисмәт Юлдашев, Әхмәр Үтәбай
һәм мин Ырынбур өлкәсенең Са-
рыкташ районыннан кайтып кил-
гәндә, бер колын, үердән аерылып,
машинабыз артыннан бик озак
ияреп барды.
*1997 ел, сентябрь*

Илебезгә илткән ат юлыннан
Бер без генә түгел узганнар.
Күз яшьләре белән җырлыйбыз бит:
«Аерылышабыз инде, туганнар!»

Әнә теге колын артыбыздан
Томырылып чапты юккамы?
Күз яшьләре акты эзебезгә,
Хәле беткәч кенә туктады.

Ятим бала кебек карап калды,
Чак калмадым төшеп янына...
Ничә еллар хәтердәге колын:
«Калдырмагыз!» – диеп ялына.

Тояк тавышларын ишетәм мин,
Тыңлаганда гимнын илемнең.
Әй илгенәм!
Ябыштырып булмый
Кылыч телеп алган телемең...

«Бүлнеп калганнарны бүре ашый».
Шулай ди бит халык акылы.
Уйга сала
Скрипкага гына
Тарттырырдай чыңлы ат кылы.
Елкылар да үер-үер генә...

Борынгыдан безгә калганы.
Даладагы кабер ташларына
Бәргәләнә дала кылганы.

Ерактагы якын туганнарым,
Сизәсезме гомер акканны?..
Даладагы җилләр генә кага
Сезгә ачып куйган капкамны.

## Ант

Ант кыламын, суда юып йөзләремне,
Йөрәгемнән суырып алып сөзләремне.

Гомеремдә тәөге кабат, соңгы кабат
Тәңрем – Кояш алларында бирәмен ант.

Ант итәмен, кулларыма мин ут алып:
«Ут булырмын, утсыз калса әгәр халык!»

Сөзләремнән кире кайтсам, рәхәт татып,
Өз башыма төшсен өзем биргән антым.

* * *

Ходай миңа мөһер суккан:
Мөһерем минем – башкорт.
Күрмәгәннәр дә күрәдер:
Мөһерем тора балкып!

Ходай мине олылаган,
Дәрәҗәм минем – башкорт.
Башкортлыкны һаман ачам,
Бетерә алмыйм ачып.

Ачып бетерерлек түгел:
Җиргә яшьтәш башкорт мин.
Яңабаштан уйлап куям:
Җиргә җандаш башкорт мин!

Ходай мине бик яраткан.
Җир көчәре – Уралым.
Җир әйләнә, ә көчәрен
Өзем тотып торамын!

Ходайның мин өз баласы,
Иманым минем – башкорт!
Җир белән күкне бәйлимен,
Урал тавына ашып.

## Минем илем

Коллар иле һәм шагыйрьләр иле –
Минем туган илем шул инде.
Минем туган илем шул булганга,
Көнем белән төнем шом инде.

Тел тидерә бу, дип әйтмәгез сез,

Гомер биргән олуг иленә.
Аның туфрагыннан дип әйтмимен,
Яралганмын аның көленнән.

Милли байрак элгән агачны да
Дар агачы иткән катыйльләр.
Бала туган, имләп ил ярасын, –
Шундый йола, шундый акыл бар.

Кол ителгән башкорт йөрәгендә
Салаватның ята кылычы.
Сабый туган саен сөенәм мин,
Бар икән, дим, халкым ырысы.

Коллар иле һәм шагыйрьләр иле –
Минем туган илем шул инде.
Бишек җыры җырлар шагыйрьләре
Җырламый шул – алар кол инде.

## Көнекмә

Буш сәхнәдә милли зур оркестр
Үз-үзенә уйный – көнекмә.
Төшәмнәргә кагыла да моңнар
Чыга алмый кала киңлеккә.

Скрипка китә иңрәп-иңрәп –
«Салават»ның кереш өлеше.
Яугирләрнең ташкын-ташкын булып
Урал иңләп чабып килеше.

Алып оча хыял гайрәт белән,
Кулда – кылыч, җанда – тантана.
Ир-егетнең көчен тойган атлар
Чабуыннан таулар таң кала.

О, Азатлык!
Бары йөрәктә син,
Кылыч очында син әлегә!
Ә әрвах ул болай да бит азат,
Син җан кебек кирәк җанлыга!

О, Азатлык!
Таулар аръягында,
Таулар тарта яңа тауларга.
Чабып барып керә каһарманнар –
Яулар әйди яңа яуларга.

Ничә гасыр чаба ул җайдаклар,
Тояклардан чәчрәп калалар
Ут-ялкынлы еллар чакма булып,
Юкка көрсенәме далалар?!

Милли зур оркестр үз-үзенә
Илһамланып уйный – беркем юк.
Янгын кебек ялмый буш сәхнәне
Мондагы моң, дәрман, кыюлык.

## Халкым үзе таный

*Күренекле шагыйрь Хәсән Назарга*

Хәсән агай, беркатлысың һаман,
Көңелең белән сабый баласың.
Кануннарың катгый, кешелекле,
Ә шигъриятеңдә син Алласың.

Өзгәрешеп бетте дус-ишләр дә,
Заманасы аның шул, имеш.
Тик син генә һаман өзгәрмисең,
Кануннарың һаман шул килеш.

Әйтсәң әйтәсең син шундый итеп,
Кылыч белән гөя чабасың:
Төрәгә дә, акча колына да
Барыбер шагыйрь булып каласың.

Шагыйрь сөзе кеше өтерми ул,
«Кеше сөзе кеше өтерә!» –
Дисәләр дә... Йөрәк җылың сеңгән
Шигырьдәге хәтта өтергә.

Ялганнарны һич тә кичералмый –
Бик югары синең таләбең.
Талантыңны халкым өзе таный,
Таләбеңдә – көчле каләмең.

## Акмулла

Кемнең арбасына утырсаң,
Шуның җырын җырларсың.

*Әйтем*

Чегән арбасыннан төшеп калган
Кешеләр бар безнең арада.
Әй Акмулла! Нинди кодрәт белән
Эләккәнмен синең арбаңа?!

Көмеш кенә төгел, алтын бишек
Синең арбаң миңа, Акмулла.
Шул арбада телем ачылгачтын,
Утыргачтын тәмам акылга,

Төшеп калганмын юл уртасында,
Күрелер дип язмыш кушканын.
Өз йөрәгең типсен җырларыңда –
Шагыйрьләргә, дидең, шул канун.

Әй Акмулла! Бары синең сөзең
Гомерләрем буе арбаган*.
Мин халкыма гына хаҗ кыламын –
Холкым калган синең арбаңнан.

Гасырлардан килер гасырларга
Китеп барасың син, Акмулла.
Ә арбаңнан милләт балалары
Төшә бара, төшә хак юлга.

## Тагын да җыр турында

Ниятләгән чакта изге эшләр,
Дога кылган кебек бер диндар,
Җыр җырлыйсың, башкорт,
көкрәк ки(е)реп,

Бар дөньяга җырлар җырың бар.

Ходаеңа сине җырың илтә,
Илһамыңда – бөек, изге көч.
Өч саклау юк, кинә тоту да юк,
Өксеп елый моңда өкенеч.

Көчен алгансың син һәр җырыңда
Җир-суларның, утның, һаваның.
Җаным белән тоям моңнарыңда
Туфрак, һава, утның дәвамын.

Көңелләрем китә күтәрелеп,
Җырлап җибәрсәң дә бер такмак.
Туганыңнан бирле моң озата,
Кабергәчә бара ул саклап.

Шул җырларың – синең догаларың,
Ул җырларың – синең иманың.
Син бәхетле, башкорт, бәхетсез дә,
Җыр булалган өчен кылганың.

## Бөздәгем

Бу дөньяның ыгы-зыгылары
Тәмам өтеп беткәч өзәккә,
Балачакка кире кайткан кебек,
Мин ашкынып кайтам Бөздәккә.

Каршы ала язын чияләре,
Юлларыма сибеп чәчкәсен.
Якташларның сөзен кабатлыйлар:
«Чәчкәләргә күмелеп яшә син!»

Көзен сыгылганда чияләре,
Көзнең явын алыр уңыштан.
«Тормыш матур һәрбер мизгелдә», – дип,
Чияләргә җырлап сөз кушам.

Туган җирдән килә бар матурлык,
Барлык яхшылыклар бездәге.
Кайда йөресәм дә адашмыймын,
Син булганда җирдә, Бөздәгем.

Син саклыйсың туган нигеземне,
Әткәй-әнкәемнең каберен.
Шуның өчен еллар үткән саен
Арта гына бара кадерең...

Чияләрең чакырып тора кебек,
Өзелгәндә минем өзәгем.
Кайда йөресәм дә, минем өчен
Җир өзәге син ул, Бөздәгем.

## Туганнарым

Телче генә түгел, илче дә мин,
Илгә кирәк икән – юугирмен.
Халкым күкрәгендә көч булырга
Язган, ахры, минем гомерем.

Авыр хәлдә яткан чагымда да

Исләремә төште туганнар:
Яргаланган куллар,
Бу тормышны тотып торганнар.

Олы кунак булып китәм сездә,
Авыз итеп бергә чәй-мәен.
Сездән кадерлерәк кемнәрем бар? –
Җәннәтләрдә инде инәем.

Ятлар ярлыкамас...
Ни булса да,
Көнем сезгә кала, туганнар.
Хатлар язмасам да,
Хәлләремне
Ил тормышы аша тойганнар.

Әйтмәсәм дә,
Йөрәк кагышымны
Көн торышы аша белгәннәр.
Тел дигәндә – телеп салганнар да,
Ил дигәндә – алдан җилгәннәр.

Җирне тәрбияләп яшәгән – сез,
Беркатлылык та ул бер калкан.
Ана китерсә дә дөньяларга,
Әйтерсең лә безне җир тапкан.

Туганнарым,
Гомер өткән саен,
Җан тарта шул сезгә, кан тарта.
Сезнең белән бер чынаяк кына
Чәй эчсәм дә, җанда көч арта.

* * *

Алтын йөгертелгән сөзләреңә,
Алтыныдыр алар көзләрнең...
Акыллылар алар авыр тарта,
Җитди караш, җитди йөзләрең.

Эретим әле синең сөзләреңне –
Алтыннары коела күрмәсен.
Ихласлыктан синең,
Көкри-тетри,
Кочагыңа килә керәсем.

Гадилегең кыйммәтлерәк миңа,
Кадерлерәк бөтен алтыннан.
Алтын йөгертелгән сөзләреңнән
Язам инде, җаным, акылдан.

* * *

Көткән идем синнән башка сөзләр,
Сибелдең дә бушка чәчелдең.
Яшердең дә керфек асларына
Көзләреңнең очкын-яшенен.

Мин дә горур, имеш,
Өз-өземә
Кидергәнмен, имеш, пәрәнҗә.
Иң кадерле сөзләр күңелемдә
Торып калды төптә – тирәндә.

Очты сөзләр, очты...
Алар безне
Әллә кемнәргә бит бәйләде.
Сизмәдең шул:
Өстәлдәге сәгать
Туктап-туктап безне җәлләде.

* * *

Күзеңнең дә синең, сүзеңнең дә
Салкынлыгына мин өйрәндем;
Утка ягам багышлауларымны –
Сүрәләре түгел Коръәннең.

Коръән булса алар тормышыңда,
Ятлап алыр идең бик күптән.
Нигә һаман сине яратам соң? –
Син бит бөтән инде, мин – бөтән.

Баеп барган кояш ялкыннары
Миңа каба – хисләр кузгала.
Нигә һаман сине яратам соң,
Гашыйк булган кебек кыз бала?

Язмыш миңа әллә шәфкатьлеме,
Әллә инде ул бер афәтме?..
Сиңа язган шигырьләрне ягып,
Дөрләтәм мин кичке шәфәкъны.

## Соңладың!

Син соңладың мине коткарырга,
Янып бетте җаным тәмугта.
Бернигә дә сызланмый ул хәзер,
Тик исемен генә танытма.

Бернигә дә җаным куанмый хәзер –
Оҗмах вәгъдә итә карашың.
Хәзер башка берәү
Шигырьләрен,
Гомерләрен сиңа арнасын!

Бер гомергә син соңладың, Сөю,
Өкенүең мине үксетми.
Ялгыз башым менә нишләр идем,
Ярый әле ташлап Уй китми.

Кулларымнан ризык җыймасаң да,
Бер үк һаваларны суладың.
Белә генә торып, күрә торып,
Мине коткарырга соңладың...

* * *

Ялгызлыкка качтым бүген таңда,
Ялгызлыкка постым кешедән.
Су-һавасыз торып калган кебек,
Язып барам, ахры, көчемнән.

Качтым,
Качтым,
Җан көчемә качтым
Урман арасына, тауларга.
Сагыш кына бер сунарчы булып
Куа килә мине ауларга.

Сагыш тарта уйны кешеләргә,
Күз алдымда дусы, дошманы.
Бик күрәсем килә кыялардан
Кояш чүеп бөркет очканны.

Җаннарымны шарламалар белән
Җиргә бәрсәм, тыймый ярсуым,
Яшәү көче кайтыр иде миңа,
Сыпырып ташлагандай аруым...

Бу сагыштан кая качыйм соң мин?
Мин монда да – аның табышы;
Тагын моңландыра
Шәфәкъларның
Ялкынланып канат кагышы.

* * *

Шагыйрьләр ул, бер сандугач булып,
Үлән арасында яши ала.
Алар да бит, бер сандугач кебек,
Җиргә – бала,
Ләкин йөрәк тала.

Шагыйрьләр ул, берәр йолдыз булып,
Күкнең дәрьясында яши ала.
Илһамлылар ул – Илаһка бала,
Әллә шуңа инде тизрәк яна?!

Шагыйрьләр ул, көйгән әрем кебек,
Далаларда яши – чәчәк ата.
Ә азактан
Еллар кәрванында,
Пәйгамбәрләр булып, илгә кайта.

## Җырланыр җыр

Сиңа атап җыр чыгардым,
Җырларсың дип барыбер бер
Минем белән шул җырымны,
Мәхәббәтем – җырланыр җыр!

Мәхәббәтем – нурланыр җыр,
Очасы бар күкләремдә,
Син күтәреп алсаң гына,
Күкләремә күтәрелә.

Мәхәббәтем – җырланыр җыр,
Моң алырсың моңнарыннан.
Язмышыңнан китмәс өчен,
Язмышымда ул яралган.

Мәхәббәтем – мәңгелек җыр,
Җырларсың син барыбер бер
Минем белән шул җырымны,
Нурландырып елларыңны.

## Хәбәр көтәм

Йөрәк астындагы сабыемның
Көткән кебек тизрәк туауын,
Яхшы хәбәр өмет итәм таңнан, –
Хәтерләтә дөнья яу кырын.

Ишегемне кара хәбәр кага:
Сугыш монда, сугыш тегендә...
Бер генә дә алтын көренми шул
Сабырлыкларымның төбендә.

Дәү әнием зарлы җыр калдырган,
Минеке дә шундый сагышлы.
Төшәдер ул, димен, илкәемә
Туганчы ук өлгән каргышы...

Айный алмый һаман аракыдан,
Уяналмый һаман йокыдан,
Минем илем, эшләпәсен сузып,
Хәер сорап тора, чукынган.

Чыгып китәр идем башны алып
Җәһәннәмгә, әллә кайларга!
Кендекләрем алдан бәйләнгән шул
Уралыма сансыз яуларда.

Карында ук дөнья куя сабый,
Кемдер әйтә: «Артык өлеме...»
Ә мин һаман яхшы хәбәр көтәм,
Илкәемнең чөнки төле мин,
Илкәемнең чөнки теле мин.

## Эволюция

Җирнең йөзе дәрья булган, диләр,
Ә хайваннар булган балык сынлы.
Тыныч өткән җыелыштан чыккач,
Искә төшердем соң нигә моны?

Хәзер дә бит туа кайбер кеше
Гел балыкка охшап, ди галимнәр.
Сәбәпләрен тикшергәчтен, алар
Радиацияне гаеплиләр.

Һич шигем юк.
Бәлки, шулайдыр да,
Нинди радиация соң безнең тормыш?
Халык авызына су капкандай,
Илдә өзгәрсә дә бар корылыш.

Авызына халык су капканмы? –
Сөзсез өти юньсез әмерләрне,
Хәйлә кармагына бердәм каба,
Җим көткәндәй көтеп әзерләрне...

Халык күрмәсә дә, балык күрер,
Игелекләр кыл, ди мәкаль.
Дөрес әйтә.
Тик нигә соң кеше кадәр кеше
Балык булып яши күрәләтә?!

## Яңа ел бәйрәменнән соң

Кар-боз сарайларны җимерәләр.
Бәйрәм тәмам. Кирәк яшәргә!
Тәти таккан чыршы, патша булып,
Ялгыз торып, юкка яшәрә.

Карсылу да, Кыш бабай да көптән
Китеп барды хыял иленә.
Җилләр ялый бәйрәм мәйданнарын,
Гел чүп кенә микән телендә?

Кар сыннар да берәм-берәм эри,
Ачылыбрак киткән һәйкәлләр.
Һәйкәл булып калган бу кешеләр
Бөек сүзләр безгә әйткәннәр.

Тик шунысы гына өкенечле:
Әйткәннәре булган боз гына.
Өлө белән,
Алар безгә корган
Корылышлар эреп бозылган.

Бик борынгы балбал булып тора
Җансыз бронза, ямьсез таш сыннар.
Мәңгелеккә җиргә кайткан кебек
Мәңге актармастай ташкыннар.

Тик берәү дә инде табынмый шул
Патшаларга –
Алар искергән.
Гел тискәре сүзләр сөйләсәм дә,
Мин үземне бүген кичерәм.

## Качак

Сырахана – туган өе кебек,
Кая барсын йолкыш теләнче?

Көпертепләр сыра коя «дусты»,
Сыйлый кулларыннан килгәнче.

Таштай каткан икмәк сыныгы да
Ярап тора тамак ач чакта.
Охшатамын аны өзе теләп
Бәхетеннән качкан качакка.

Булгандыр ла аның туган өе,
Ата-анасы да исәндер.
Әмер түгел, бары хәмер генә
Җыяр ризыкларын кискәндер.

Булгандыр ла аның гаиләсе –
Күгәрчендәй гөр-гөр килгәндер.
Бишегендә яткан баш баласы:
«Әттә, әттә!» – диеп көлгәндер.

Булгандыр ла аның туган җире, –
Туйдыручы безне туфрак ул.
Бүген исә туган туфрактан да,
Туган өеннән дә ерак ул.

Күңелендә шайтан туйларыдыр,
Әй Ходаем, ансын кем белсен?!
Кешелектән чыккан кеше менә
Уйландыра инде төрлесен.

Өе генә түгел, ул үзе юк,
Гаиләсе түгел, юк иле.
«Ах, анаңны гына шулай итим...» –
Эчкечеләр бар да бер телле...

Очратмасам яхшы булган икән –
Акыл белән хисләр тартышты.
Тавышыннан танып алдым – бу бит
Байгыш түгел, халык артисты.

Кызлар аңа үлеп гашыйк иде,
Ул буй-сыны, тавыш, ул йөзе!
Шөһрәт толпарында җилдерде дә
Балда-майда гына ул йөзде.

Урал батыр иде ул сәхнәдә,
Яуга ашкындырган Салават.
Йөрәгеннән сүзен суырып алып,
Яши иде җанны дәвалап.

Әллә уйнап, әллә инде уйлап
Шушы көнгә төшкән?
Кем белсен?!
(Әй син, тормыш,
Урал батырга да
Һич кенә дә җиңел түгелсең!)

Нинди рәхәтлекләр өмет итеп,
Үз-үзеннән качкан бу качак?..
Тере чакта ачмас фаҗигасен,
Үлгәч, хатирәләр ачачак.

## Ялвару

Прощай, немытая Россия!
*Михаил Лермонтов*

Хушлашмыймын, Рәсәй, синең белән,
Туган җирдә булыр каберем.
Халкым кичергәнне кичерәмен,
Халкым белән бергә кадерем.

Кайда да бер башым сыяр иде.
Күрдем: җәннәт – диңгез аръягы.
Олылады мине, әйтерсең лә
Тамырымның шунда тармагы.

Хушлашмыймын, диңгез аръягында
Яшәгәннәр әйдә яшәсен...
«Минем кебек син дә ярат мине!» –
Диеп, сиңа килә дәшәсем.

Җирдә минем башка Ватаным юк,
Ананымы сайлап алалар?
Бәхетлебез, бәхетсезләребез –
Һәммәбез дә синең балалар.

Мин ышанам сиңа – алдансам да,
Өметләнәм – өмет бетсә дә.
Бала табам һаман, ата-бабам
Синең өчен шәһит китсә дә.

Хушлашмыймын, Рәсәй, синең белән,
Сабырлыгым килә канымнан.
Җан тарта бит сиңа – аптырамам,
Җәннәттә дә сине сагынсам.

* * *

Коен дисәң, коен түгел –
Өтә дә китә коен:
Аптырата, тынгы бирми
Синең хактагы уем.

Яшәп булмый синсез генә,
Синең белән дә кыен.
Яшәү миңа – синең куен,
Үлем дә – синең куен.

* * *

Эчләремә генә сыялмыйча,
Кичерешем чыкса түсемә,
«Бу һаман да яратадыр», – диеп
Уйлама син, алма исеңә.

Көнләмә дә мине беркемгә дә,
Йөрәгем буш минем, буш бүлмәм.
Яратыр да идем...
Синең хакта

Кирәгеннән артык күп беләм.

* * *

Күзләреңнең явын алсаң иде,
Сарыларга гына сабыштым.
Чәчәк әйтте бугай:
«Җирдән шытып,
Мин кояшым белән кавыштым...»

Җирдә – язмыш...
Җирдән киткәч, мин дә,
Бәлки, чәчәк булып шытармын...
Кавышырга тик кояшым белән,
Шуңа да бит минем шат җырым.

## Сак-Сок

Теләсәң дә, ташлап киталмыйсың,
Синең дөньяң, җаным, мин генә.
Минем моңым килә күңелеңә,
Минем сүзем килә телеңә.

Тирән коеларга тавыш бирсәң,
Минем тавыш килә төбеннән.
Сөю-әнкәебез безгә рәнҗеп,
Сак-Сок булырбыз дип кем белгән?

* * *

Йолдыз белән йолдыз аралыгы –
Безгә билгеләнгән ара шул.
Язмышлардан узмыш булса икән:
Көннәр салкын, төннәр кара шул.

Яратасың мине, ә мин – сине.
Барысы да ачык, бик ябай*.
Әйтерсең лә ишкәкләрсез көймә –
Арабызда йөзә ярты ай.

* * *

Укталам да
Тагын тукталам шул,
Бигрәк биек мәрмәр баскычың.
Баскычларың – мине әйтерсең лә
Җиһаннарга илткән ачкычың.

Аякларым тарта кайтыр якка,
Җиһанымның серен ачалмам.
Яшен генә, кулын изәп миңа,
Күкрәп тавыш бирә асманнан.

## Күнчелгә

Күңеленә нигә сыймыймдыр мин,
Дөньяларга сыям туганнан.

Мин, ахрысы, шундый авыр тартам,
Шушы авырлыкны тойганнан.

Бавырларың таша,
Көчсез көнчел –
Ходай безне шулай яраткан.
Ә мин сине барыбер кичерәмен,
Син – өземә мине караткан!

* * *

Мәкер кабер казый төнен
Намуслыга, талантлыга.
Ә аннан соң, качып кына,
Өтергәнче арттан суга.

Сөю бишек өрә көндез,
Өрә кояш нурларыннан.
Анда котлы бәхет ята,
Өсә сөю җырларыннан.

* * *

Акны ак дип дәлилләргә кайчак
Җитми зиһен, җитми гомерең.
Хәзер инде дәлил эзләмимен –
Сабыр акыл туплап өлгердем.

Акны ак ди барыбер саф көңелле,
Калганнарның өзенең бизмәне.
Уйламас та идем мин бу хакта,
Баткак ерып барам – күз мәле.

* * *

Кул тимәгәч, назлы розаларым
Әйләнгән дә куйган гөлҗимешкә.
Кыргый чәчкәләргә әйләнгәннәр –
Һушым китеп торам шушы эшкә.

Көпме көч түксәм дә,
Гөлҗимеш бит
Роза булып кабат өсә алмас.
Акылыма утырттың син мине,
Чәнечкеләр баскан кыргый агач.

* * *

Һәр кешегә кояш булып булмый,
Ай да булалмамын һәркемгә.
Мин кояшмын кояш арасында,
Мин әреммен өзе әремгә.

Тик яхшылык белән җиңеп була
Яманны, ди мәкаль. Бел, дустым!
Әрем арасында бер әремгә
Әйләндерә ләкин тормышым.

* * *

Өзе бәхет бит ул күреп калу
Таңда кояш канат какканын.
Кадерләре арта һәрбер таңның,
Ачык ишек, ачык капканың.

Бу дөньяны белә барган саен,
Бәхет – күрә кояш баюын.
Шөкер итсәң шушы бәхетеңә,
Күрәчәксең әле ай юлын.

* * *

Кеше туа –
Чәчәк бирә
Якыннары.
Күрми кеше:
Елау гына,
Йоклау гына
Бөтен эше.

Кеше үлә –
Баш очына
Чәчәк сала
Дус-ишләре.
Күрми кеше,
Юкса беткән
Бөтен эше.

## Сөйләшү

– Күрәсеңме, күкләр нинди зәңгәр?!
Мин кош булып очып китсәм әгәр,
Нәрсә диеп җавап бирер идең,
Югалтсалар мине җирдәгеләр?

– Кошка әверелсә әгәр кеше,
Ташлап ыгы-зыгы, бөтен эшне,
Очар иде күккә. Бер кешесез
Калыр иде безнең бу җир өсте.

* * *

Минем кайгым җиһан каршысында
Әллә нинди зур да хәсрәт түгел.
Җаннарымны кая куйыйм соң мин,
Сызлый гына бирә чәчрәп күңел.

Сүндерергә көчем җитәр микән –
Дөрли җаннарымны ялмаган ут.
Әллә нинди зур хәсрәт тә түгел,
Җиңалмасам аны – җиһан да юк.

## Кабер ташындагы язудан

Гөнаһлардан курык!
Кеше күрмәсә дә,
Кояш күрә, төнен ай күрә.

Качып була айдан, кояштан да,
Кереп яткач кына как гөргә.

Гөнаһлардан курык!
Эчәр суың белән
Сулар һаваң әле бар, кешем!
Игелекләр кылсаң, өз-өзеңә
Җирдән, көктән кайтыр бар көчең!

* * *

Көккә бактым.
Сагышымны йотты
Көк әз-әзләп, талгын, җай гына.
Җанга тулды көкнең зәңгәрлеге,
Көңелемдә кояш, ай гына.
Көннәр өтте.
Җир йөзенә бактым,
Сагышымны йотты су-урман.
Җанга тулды җирнең яшеллеге,
Җир кодрәте белән сау торам.

* * *

Зәп-зәңгәр көк.
Төп-төгәрәк кояш.
Аккош оча...
Оча!
Көз җиткән.
Яшелдер дә дөнья, сарыдыр да –
Карыйсың бит нинди көзлектән.

Аккош киткән юлдан ак кар ява,
Төшенмәсәң, төшен серенә:
Биеклеккә көтәрелгән кошның
Көләгәсе төшми җиремә.

* * *

Байлыгым юк минем, дәрәҗәм юк,
Юклыгына китми һич исем.
Гомер бәяләрен белер чагым,
Вакланмыймын мал һәм дан өчен!

Дәрәҗәләр төстер башкаларга,
Өз көчемә яшәө – миңа төс.
Өз көчемә генә яшәгәнгә,
Бу хәйләкәр дөнья ала өч.

* * *

Утка – ут,
Суга – су,
Җилгә җил бирә көч.
Дөнья, ян, суга бат,
Давылда көккә оч!

Юк, килмә, фаҗига:
Сиңа һич җитмәс көч;
Кешегә кеше – яу,
Кешегә кеше – өч!

## Җил йокласа...

Җил йокласа,
кө͏л эчендә очкын
Дөнья гамен тоймый ята бирә.
Җил йокласа,
дулкын дулкын төгел –
Су да изри, сабышкандай чиргә.

Хис йокласа,
йөрәк чакма төгел,
Утның көчен тоймас бер таш кына.
Хис йокласа,
кеше кеше төгел,
Дөнья бизмәнендә бер баш кына.

## * * *

Яңа тәпи баскан сабый кебек,
Поэзия, сиңа сыенам.
Җитәклә дә син атларга өйрәт,
Бәйгеләргә чык, дип, соңыннан.

Яңа теле ачылган сабый кебек,
Поэзия, сиңа омтылам.
Бирче миңа алтын тел ачкычы,
Мәхрүм итә күрмә утыңнан.

Көңелемә шигырь килгән саен,
Сабый хөкемендә каламын.
Әйтерсең лә күзләрен зур ачып
Әнкәсенә баккан баламын.

## Мәхәббәт

Бер кулында – тере сулы касә,
Бер кулында – үле сулы касә.
Икесен дә аның татыдым мин,
Мәхәббәткә тугры хатынмын мин.

Тере суын эчтем – кимемәде,
Үле суын эчтем – кимемәде.
Икесе дә аның татлы икән,
Татлы итеп эчкән хатын икән.

Тере судан һаман теремен мин,
Үле судан аз-маз киремен мин.
Бахыр кебек иде – мин ир иттем,
Үле суын аның мин сер иттем.

## Тарихи хәтер

Яшен яшьнәп, көкләр көкрәгәндәй –
Акбөзатым кешни кайвакыт:
Хисем черем итсә – давыллатып,
Каным тынычланса – кайнатып,
Җирнең өзен куя чайкалтып.

Күк капусы шулчак ачылгандай –
Җиһан микән минем хәтерем?
Кем уйлаган инде, яши торгач,
Миңа шундый бәхет тәтерен?!
Хәтер әйтә Ходай әйтерен.

Адашсам да, кояшлы юл табам,
Намусыма юлдаш – хакыйкать.
Хәтер саклый минем гомеремне:
Яшәү генә җирдә – бар кыйммәт,
Ә калганы – бары кыямәт...

Кеше уйлап тапкан җир юлдашы
Күкне ачмый миңа һичкайчан.
Акбөзатның бер кешнәве була,
Дөньяларга җанны мин ачам,
Минем җаным – үзе бер асман.

## Мәрсия

«Бу ни хәл соң?» – диеп, беркемгә дә
Эндәшәсем килми. Арыткан.
Туган белән туган сугышканга,
Ил-анабыз, инде хәлдән таеп,
Бер сүз әйтмәс булган – карлыккан.

Ә танклар һаман агылалар,
Балаларны төяп, Каф тауга.
Яңалары яуга ташланалар,
Искеләре янып шартлауга.

Аналарның күз яшьләре – дәрья,
Җир өстеннән юа күл-канны.
Милләтләр дә төлсезләнә бара,
Туган үтергәндә туганны.

Бишектәге бала тынмый өкси,
Ишеткәчтен ату тавышын.
Котын ала сугыш елганың да,
Ташларыннан сөрә тау кошын.

Хәсрәтләрдән җирнең төсе кача,
Тетри таулар, калка туфаны.
Каф тавының кара күләгәсе
Калтыратып тота Уфаны.

Улсыз калган ана, дога укып,
Кабер алларына тезләнгән...
Газиз улсыз калган ул аналар
Меңләгән бит алар, йөзләгән.

Инде синнән сорыйсы да килми:
«Бу ни хәл соң?» – диеп, башкала...

Баш очында, кара козгын кебек,
Кара болыт кына чайкала.

* * *

Бөре тими бөрегә, ди хакыйкать,
Карга күзен карга чукымый,
ди мәкаль,
Бөре бугазлап ташлаган бөрене,
дип яза гәзит.

Ике бөре чыкты юлга,
Өзәккә өтә суык.
Яланнарда йөргән атны
Җиталмадылар куып.

Ат бик гади түгел иде,
Затлы иде нәселе.
Карга тигән тояклардан
Уйнап калды яшене.

Йомылды ат, югалды ат
Күк таулар аръягында.
Дөлдел түгел, азык кына,
Бөречә караганда.

Хәлдән тайган карт бөрене
Юлда бер уй туктатты:
«Аяк сузсам, юлдаш бөре
Ботарлап ташлар атны.

Ә ул көчле – минем күрше,
Гайрәте ташып тора! –
Карт хәйләкәр юлдашына
Ажгырып башын бора. –

Ачуың да килерлек шул:
Ул бит әле яшь бөре!
Юк, аңа ал биреп булмый,
Мин дә бит әле тере!»

Бугазыннан ала кинәт –
Хәйләне белгән ерткыч.
Ачлык түгел, дус дигәннең
Көче аңа куркыныч.

Бөреләрнең күзләрендә
Ут уйный – кылыч кебек.
Ә тирә-як йокымсырый,
Тирә-як тыныч кебек.

Яшь бөре яшьрәк иде шул:
Җан бирде авыр сулап.
Җан бирде ул, карны тырнап,
Күктән мәрхәмәт сорап.

Ашады аны өлкән дус,
Утырып, җайлап кына.
Бөредә йөрәк бармыни?!
Анда – теш, тамак кына.

Ашап туйгач, күккә карап
Улап алды ул сузып.

Аның озак улавыннан
Көн дә китте бозылып.

Буран чыкты.
Сынды салкын.
Сынды ул кылыч кебек...
Оясына качты ерткыч,
Тирә-як тыныч кебек.

## Кыңгырау

*(Поэма)*

Йөрәгем
әнә теге тау башында торган
кыңгырау булса,
көмештән коелса,
яңгырар иде шундый итеп –
яңгырар иде, сагыш моңы
ай-йолдызга җитеп.
Яңгырар иде –
сыкрар иде
көнен-төнен,
йолкып алмасалар телен.
Көмеше өчен
аны кире коймасалар –
чың-чыңыннан тыймасалар.
Шушы көнгә кадәр җансыз яткан,
радиация агуыннан каткан
көбәләкләр, бөҗәкләр, тургайлар,
боланнар, пошилар, бөреләр,
терелеп, килер иде телгә,
сөйләр иде илгә:
дистә-дистә еллар аларны
сер итеп тотканнарын,
аннан бөтенләй оныткannарын.
Шаһитларны юк итә яхшырак –
җинаятьченең йөзе яктырак...

Көмеш кыңгырау булса йөрәгем –
сөйләр иде кирәген!

Борынгыдан ата-бабам
суын эчкән Динес елгасы –
Кызылтөш көленнән юл башы –
терелер дә
әкияттәгедән дә
куркынычрак
явызлыкны
итәр иде бәян –
әле ул авызлыклы:
яр читләре чорналган
тимерчыбык белән –
сөйли алмый хәтта ым белән!
Ул сөйләр сөзне мин сөйлимен,
хакым бар –
халкым бар!
Борын-борын заман түгел,
сөйләгәнем ялган түгел,

атам-анам буынына
тигән өлеш
шушы, имеш:
Динес елгасы суының
һәр тамчысы – агу,
агу шундый чагу!
Суыннан халык
чебендәй кырыла,
кырыла яңгырда, корыда.
Балыкларның гаҗәпләнүдән
күзе атылып чыккан,
оясында җан биргән тычкан.
Дөньяны әллә каһәр суккан?
Кешеләр ташлап кача үз кыегын,
җимерелгән авыл нигезләре –
Хиросима белән Нагасаки бит
аларның игезләре.
– Хуш бул, Бирдәнәшем!
– Бәхил булчы, Галикәем!
– Мәңгегә хуш, Сатлыккаем!
Сиңа хәзер атлыкмыймын,
минем кояш, минем аем!
Э-э-э-й-й!
Бер тере җан калмый
күпме авылда,
Чиләбе дә дигән якларда –
җаным актарыла,
кушыла бит аһым
йорт-җиреннән генә, ай, куылган
меӊ-мең кешеләрнең аһларына.
Туганнарым минем,
без бит – кеше!
Ялгыш туганбызмы җиргә?
Нигә язмыш безне һич аямый,
борын-борынгыдан гүя үчле!
(Йөрәгемне кыңгырау итеп куям!
Мин тойганны тойсагыз икән,
мин кичергәнне кичерсәгез икән!
Шулай булмаса –
мәгънәсе юк тормышымның:
Динес елгасы суының
бер тамчысын эчерсәгез икән!)
Йорт нигезләре кала,
язмыш кала,
кала зират –
елый ир-ат.
Туган тел кала,
кала Коръән,
икмәк кала.
Авылны кемдер сөреп чыккан.
Серәешеп калган мичләр
тереләрне хәтерләтә,
тәреләрне хәтерләтә.
Арба-арба төялешеп
китте халык кемдер куган якка.
Сибелеште йомгак кебек! –
күз ышанмас моны күреп.
Артларыннан чапты этләр
улый-улый, елый-елый.
Кайтмагыз оягызны эзләп,

сандугачлар,
карлыгачлар, торналар!
Кайта күрмәгез,
сезне монда көтә әҗәл.
Ул һәр агач,
һәр үлән,
һәр ташка яшеренгән
алдавыч яшь бөреләр.
Мәкерле әҗәл:
чык та – әҗәл,
болыт – әҗәл…
Юк котылыр әмәл.
«Төз калган капкалар,
әй Ходаем,
охшаш капкасына Бухенвальдның», –
күз яшьләре тама сакалына
Бухенвальдтан исән калган картның.

Җир шарын кочаклагандай,
эчен тоткан хатын –
сыны каткан:
тумас элек үлгән баласы –
ана булмаячак башка –
әйләнгән ташка.
Ә радиодан шат сүзләр яңгырый,
бөтен Җир шарына ишетелә
ул шат сүзләр:
«Совет халкы чәчәк ата:
тиңнәр арасында тиң булып
башкорт халкы гөрләп чәчәк ата!» –
Мондый ялганның
әкияттә булганы юк хәтта.
(Йөрәгемне кыңгырау итеп коям!
Мин тойганны тойсагыз икән,
мин кичергәнне кичерсәгез икән!
Шулай булмаса,
мәгънәсе юк тормышымның:
Динес елгасы суының
бер тамчысын эчерсәгез икән!)
Хиросима!
Нагасаки!
Сезне бомбага тоткан пилотның
беләм язуын акылдан.
Халкым!
Сине радиация утында куырганнар
ала орден, ала дан!
Хиросима! Син дә!
Нагасаки! Син дә!
Ишеткәнегез юктыр әле
Аргаяш,
Коншак дигән исемнәрне?
Ишетмәсәгез ишетегез,
хәсрәтләрен иш итегез!
Аргаяштагы фаҗига,
Коншактагы фаҗига –
дәүләт сере иде бик күп ел.
Берия үзе
баш очындагы козгын кебек
саклый иде атом бомбасын.
Тимер кул!

Серне ачканнарга – өлем!
(Нигә «өлем» сөзе белән
рифмалаштырырга мәҗбүрмен сине, илем?!)
«Чиләбе-40»
атомчылар каласының күкрәгендә,
орден кебек, ике урам балкый иде:
берсе – Сталин,
икенчесе – Берия!
Мөмкин түгел иде монда керергә,
күрергә –
оран салырга!
Оран салган – телсез калган,
алай гынамыни – илсез калган...
Дулкыннан ярала дулкын,
упкынга иш бары упкын.
Юк ителгәч син, Хиросима,
юк ителгәч син, Нагасаки –
сезнең көлне күккә очырган
бомбага тиң бомба
кирәк иде илнең гөмбәзен саклар өчен.
Адәм тудыра әҗәлне,
әҗәл тудыра әҗәлне.
Миңа ышанмасагыз, газетадан укыгыз.
(«Башкортостан», 1989 ел, 11 октябрь.)
*«1947 елның 12 августында ядро бомбасына*
*сынау үткәрелә».*
Бомба ясалган урынны да әйтә алам:
Көньяк Урал,
Уралда – уран!
Әйтерсең лә Урал «ура!» сүзеннән ясалган.
Кычкыралар: «Ура!»
Урал башкорт сүзеннән
хасил булган, ди
кобаер –
моңаймас җирдән күңел моңаер.
Хиросима!
Нагасаки!
Аргаяшка да,
Коншакка да
кайгы килә сорап тормый,
урау юлдан урап тормый:
*«1948 елдан алып 1953 елга тиклем ачык*
*сусаклагычка радиоактив калдыкларны*
*ташлыйлар.*
*Аларның куәте 120 миллион кюрига барып җитә –*
*бу Чернобыль фаҗигасендә туган болыт*
*куәтеннән 2,5 тапкырга артыграк».*

Йөрәгемә чыдый алмыймын мин –
барыйм дисәм алга таба,
чүгеп төшәм,
җебеп төшәм.
Гөнаһым бар кебек анасының карынында
үлгән сабый алдында –
шул сабый көн-төн аңымда.
Эзәрлекли мине аның җаны.
Күбәләк булып та,
кырмыска булып та
кайталмый ул Ватанына.

Еланга да әйләнә алмый, ичмасам! –
Өзен өтерөчеләрне буар иде!
Мин өзем дә ашыкмыймын аны терелтергә –
ышанычын аклый алмам дип куркам,
җир тора бит тетрәргә!
Шул ук Көньяк Уралда
АЭСлар төзелә, –
тезелә, тезелә, тезелә...
АЭСлар гөя Җир шарын йотмакчы өзенә.
Мин ана булып та
сабыйга җан бирә алмыйм икән, –
яшь коеп көп яшәдем, –
йөрәгемнән кыңгырау коям!
Тавыш бирер диеп ышанамын
аның тавышына ил һәм җиһан!

## Кан басымы

Өземә гел иң югары таләп,
Кан басымы кебек югары.
Кан тамырым аша өтә, ахры,
Бу Вакытның бөтен юллары.

Тарих юлы өтә тамырымнан,
Мәңгелекләр сеңгән комына.
Батырлык һәм коллык төсе булып
Каплана ком минем тыныма.

Бөгенге дә минем кан юлымда
Кабалана, кайный, гөр килә.
Йә ул чыгымчылап китәр, шуңа
Куя алмыйм мин өз иркенә.

Таңым да бит, канның көчен алып,
Яралгачтын минем тамырда,
Көктә кояш, кан тамчысы кебек,
Саксызлыктан тора тамарга.

Көкрәк сукмасам да,
Прометейның
Җирдә мин ул, диеп, сыңары,
Өземә гел иң югары таләп,
Кан басымым һәрчак югары!

* * *

Әй ялгызлык өрти җаннарымны,
Утлы уйдан алып, суга сала.
Ала-сала...
Очы-кырые юк.
Янган җаным тагын уйга кала.

Дусларымның миндә эшләре юк,
Дошманның да коелганмы теше?
Кайда соң син, шушы минутларда
Миңа бер җылы сөз әйтер кеше?

Фәрештәләр, ярый, арыгандыр,
Кешеләргә изгелекләр ташып.
Алай булгач, килеп керсен шайтан,

Мине тапкан куанычтан шашып.

## Сагындыра

Мич ягуларыңны сагынам мин,
Йөри торгач, әнкәй, юлымда.
Әкияти тылсым – могҗиза бар
Дөрләп янган кузлар тынында.

Очкын чәчрәткән шул кузларны син
Сөндерәсең, салып чуенга.
Иртәгә дә көн бар:
Күмер кирәк
Самавырны тагын куярга.

Иртән-иртүк түр башында көн дә
Ак самавыр җырлый, пар бөркә.
Ул җырлагач, өебез гел котлы,
Гел кояшлы кебек һәр иртә...

Ә мин, әнкәй,
Куз сөндергән кебек,
Күңелемдә йолдыз сөндерәм.
Йолдыз димен инде уңышларны,
Булмаганда алар бик сирән.

Җир әйләнә,
Ләкин баш әйләнми:
Сатылмыймын, кеше сатмыймын.
Иртәгә дә көн бар, иртәгә дә!
Күкрәк тулы йолдыз саклыймын.

Йолдыз димен инде яхшы сүзне –
Миңа төбәп ихлас әйтелгән, –
Иртәгә дә көн бар, иртәгә дә! –
Балкып китә алар хәтердә,

Җан кергәндәй,
Болыт баскан көнгә,
Коты кайта балкып яңадан...
Әнкәй, әнкәй,
Күмер сөндерергә
Өйрәттең син сабый чагымнан.

## Син туктама, Вакыт!

И син, Вакыт!
Саф, самими мәлең
Калды микән бала чагымда?!
Шул сәгадәт-бәхет гомер буе
Тормышымда минем чагыла.

Ишекләрне бикләмиләр иде,
Төн йөзендә куркып кемнәндер.
Мондый мәрхәмәт ул кешеләргә
Дала киңлегеннән иңгәндер.

Мондый юмартлык ул кешеләргә

Кара урманнардан сеңгәндер.
Бер-берсенә алар ышанганга,
Кара чирөләрне җиңгәндер.

Бер-берләрең белән горурлану
Кыялардан җанга көчкәндер.
Егетләре шуңа – бөркет булып,
Кызлар былбыл булып өскәндер...

Ачык ишекләрдән чыгып киткәч
Офыклары ачык дөньяга,
Бикле ишекләргә
Килеп торып
Бәрелгәннәр – минем елъязма.

Юмартлыгым какты ят ишекне,
Игелегем какты ишекне.
Белмәгәннәр, күрмәгәннәр элек
Туган итте – мине ишетте.

Горурлыгым алдан барып керде
Ят өйләргә, кырыс йортларга.
Онытмадым ләкин беркемне дә
Хәерле көн белән котларга...

Ачтым,
          ачтым,
                    өр-яңадан ачтым,
Көптән ачсалар да дөньяны.
Һәркем ачкан өчен яңабаштан,
Иске дөнья һаман өр-яңа.

Очкан өчен булды фаҗигаләр:
Асылда без барыбер Икарлар.
Иң кыены гына алда, димен:
Җир шарына салып бикләрләр...

И син, Вакыт!
Һәр мизгелең матур!
Шуңа әйтәм:
«Вакыт, туктама!»
Ут күрше дә, башка күршеләр дә,
Ут беткәндә, миннән ут ала.

## Идеология

**1**

Кибетләрдә
Кара таңнан чират торып алган
Китапларын –
Бар байлыгын –
Карт фронтовик илтеп тапшырды,
Чанасына төяп,
Уртын чәйнәп,
Макулатурага.
Тора ул «номенклатура»да –
Теге дөньяларга.
Авыр кузгалуы,
Авыр чанасы.

Китаплары аның
Яшәлгән еллар чамасы.
Чанасына төяп бар гомерен,
Китеп баргандай ул
Теге дөньяларга.
Башта кирәк әле
Ашарга алырга.
Шунысы җанны җылыта:
Җәннәттә барысы да туган-иптәш, ди...
Ә ул фанилыкта шуның өчен көрәште.
Яудан кайткан котелогы белән кружка
Әле һаман ярый һәр эштә.

**2**

Фронтовикның ашказаны кычкыра: «Урра!»,
Тотына шуннан хыял корырга:
«Шәп макулатура хакы,
Килә аңа җилле аракы,
Колбаса да килә йөз грамм!»
Ач тамакка – бәйрәм, бәйрәм, бәйрәм,
Кайткан чакта тапмаса урам,
Кулыннан тартып алып китмәсә ризыгын
Берәр малай.
Бабай иренен ялый...
Нинди куаныч:
Валидолга да кала акчасы,
Макулатура җыючы булмаса алдакчы!

**3**

Өендәге буш китап киштәләре
Әйтерсең лә тәнендәге хасталары.
Колбасаны төреп
Алып кайткан гәзиттә
Шәрә кыз, әлбәттә!
Тфө! Аппетитны бозды, имансыз!
(Нигә аңа фронтовик бабай,
Олигархны давай!)
Шәрә кыз менеп ятты
Киштәгә – китап урынына.
Ята бирсен шулай кырын гына...
Аракыдан бабай төш күрә:
Өзен-өзе өшкерә-өшкерә,
Оҗмахка китеп бара аягөрә.
Тик нигәдер тоткан винтовкасын.
Берлин капкаларын ачкан кебек
Ачып кермәкчеме оҗмах капкасын?
Йә, тукта,
Китеп барган чакта,
Колбасасын да капкаласын.
Кем белә,
Оҗмахта да, бәлки,
«Развитый коммунизм»дагы кебек,
Сабынга да,
Шырпыга да
Торалардыр чират.
Торадыр чират
Хәтта ир-ат.
Байлыгы әле аның бетмәде –

«За оборону Сталинграда» медале бар,
Кирәк булса,
Тоз-мазарга алыр алмаштырып.
Их, бу корсакны
Берничек тә булмый алдаштырып.

**4**

Таң ата.
Фронтовик аракыдан өз-өзенә кайта.
Шәрә кыз гына
Калган макулатурага.
Төкерә бабай черт итеп
Шушы «культура»га.
Йоклап китим әле дисә, тагы
Тынгы бирми ач тамагы.
Корсагы ачка
Ярый инде валидол да иртәнге ашка.
Кояш чыкса да,
Ул түгел бит алтын акча.

## Гайсә пәйгамбәрнең кешеләргә эндәшүе

Хак сүземне мин аңлаттым яшәп,
Гади генә яшәп, көндәм генә.
Яши-яши җирдән акыл алып,
Яктылыклар алып көннән генә.

Кабереннән чыкты, мин җан өргәч,
Бер гөнаһсыз киткән бар адәмнәр.
«Сихерче!» – дип биткә төкерделәр
Имансызлар, әтрәк-әләмнәр.

Сезнең белән бергә көн иткәндә,
Пәйгамбәр дип беркем танымады.
Шиктән, үчтән, көнчеллектән тагын
Каннарыма күпләр җанын манды.

Миңа аткан ташлардан да бигрәк
Каты булды яман сүзләрегез.
Сез бит миңа катыйль булмадыгыз,
Үзегезгә катыйль үзләрегез.

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Бәйле башым! – Әле күрдегезме?
Төн каплады минем күзне түгел,
Атылып чыккан сезнең күзегезне...

Тагын, тагын телдегез сез тәнне,
Җаным тагын, тагын сабырланды.
Тик үчегез бер дә басылмады,
Йөрәгегезгә ул тамырланды.

Дүрт санымны кадаклаган чакта,
Җәнлек тиреседәй генә күреп,
Мин әрнедем бары шуңа гына:
Үлгермәгәнмен бит иман биреп.

«Үлде!» – диеп юкка көлде үчле,
Үтердегез бары сурәтемне.
Сурәтемнән генә тамган кан да

Илаһымның сөзе – сөрә инде.

Яшимен мин ачылмас сер булып,
Хак Тәгалә хозурында өзем,
Ул кайтармый әле сезнең янга,
Булсыннар дип минем кебек төзем.

Ярлыкадым сезне,
Килсеннәр дип
Олы-кечесе дә акылына,
Күзенә ак салган
Бу дөньяны
Күрмәсен дип шул ак чаклы гына.

Сез өбәсез, кат-кат өбәсез сез:
Җаным җылысымы тәреләрдә?
Гаҗизләнеп табынулар өчен
Кирәк идемени өтерергә?

Кайтмас диеп өметләнәм әле
Минем канга баткан җирнең кәре*;
Тик һәр гасыр җан ярамны ачар,
Мин бит – кешеләрнең пәйгамбәре!

## Коррида

Тамаша:
Коррида!
Коррида!
Урын юк – туп-тулы стадион.
Неоннар күзләрдә чагыла,
Күзләр дә хас неон, хас неон!

Яу бара!
Яу бара!
Син кара:
Кан сорый олысы-кечесе.
Патша да, кашка да, башка да –
Алышка түләгән кешесе.

Әй үгез котыра ярсынып,
Кан сауган ут чәчкән күзенә.
Котырта,
Котырта тореро,
Әй үгез, түз генә, түз генә!

Тореро, ах, елгыр –
Ул бии,
Тореро, ах, җитез –
Сикерә.
Ә үгез, беркатлы бахыр җан,
Җиңәм дип үкерә, үкерә,

Үкерә!
Качмасаң – үтерә!
Шпага җанына кадалды.
Тореро күкләргә чөелә,
Ул дан да,
Доллар да казанды!

Тамаша:

Кан ага, кан ага –
Йөрәге чак кага өгезнең.
Коррида!
Коррида!
Уенда
Таныйдыр кемнәрдер нәкъ өзен.

## Өйрәнергә...

Дус ярлыкамас...
*Әйтем*

Күзгә кергәч, шуны аңладым мин:
Җирдән өйрәнергә туганмын!
Шулай кирәк диеп кабул итәм
Карлар явып, сулар туңганын.

Бик гадәти җанның туңуы да –
Мизгел арасында кышы бар.
Кем аерсын:
Иңгә ак шәл салган –
Туңган агачлар да купшылар!

Кабул итмәс иде мине дөнья,
Мин булмасам көкнең көткәне.
Бик гадәти йөрәк янулары,
Яна, ләкин кояш бетәме?

Кәҗәмөгез диеп мөһер суккан –
Өпкәләмимен мин асманга:
Йолдызлыкта йолдыз сөзешәме –
Нуры гына төшә башкага.

Судан, диләр, дөнья яратылган –
Миндә дә бар диңгез хәтере:
Бик тиреннән генә алам әле
Кешеләргә әле әйтерне.

Җирдән,
Судан,
Күктән өйрәнәмен,
Тик хәтере дусның калмасын.
Тик шул өчәө генә кичерәдер
Мең гөнаһлы адәм баласын.

## Каралама

Гомер – каралама,
Ак кәгазьдә
Күпме хата:
Язган-сызганмын.
Сызганмын да,
Ләкин язмышларның
Урап өтеп булмый тозагын.

Ак кәгазьдә мин төшергән сурәт:

Ай-кояш та әнә кичәге.
Рәссам булалмадым,
Туры килми
Төсе яки көннәр исәбе.

Гармония кайгыларымыни
Икмәк юкта яки тоз юкта?!.
Кайтавазы өткән көннәремнең
Булса икән бары музыка!

Тагаракта җим чөпләгән коштай,
Ыгы-зыгы белән көн өтә,
Күреп кенә калдым, очып китте
Сөю кошы бигрәк биектә.

Гөнаһлардан азат булдым, диеп
Кага алмасам да күкрәкне,
Җир упкандай барып очканда да
Яшәргә бит намус өйрәтте...

Гомер – каралама.
Мин киткәчтен
Яшәп туялмаслык дөньядан,
Акка аны күчерәмен диеп,
Көчең сарыф итмә, и балам!

## Җиһан моңы

*(Орган концертында)*

Илаһмы син?
Бармакларың, көйче,
Телләренә булды тиюе,
Күк капусы ачылды да, мине
Чорнап алды асман сөюе.

Гөмбәзләрдән иңгән Галәм моңын
Тыңлап ятам җирдә мин – бәндә.
Җиһан моңы мине назлагачтын,
Бер әүлия микән мин әллә?!

Айлы төннең, таңның тынлыгы да –
Ничек сыйган тынлык бу моңга?
Мин бит өйрәнгәнмен җәйге таңны
Сайрап уятучы былбылга.
Тау-урманның курай тартуына
Әлмисактан* җаным күнеккән.
Бәлки, җирдә миндер бер фәрештә,
Моң агыла бөтен киңлектән.

Елакмы син?
Бу телләргә, көйче,
Кагылдың да... купты тайфуннар.
Һаваларга аша океаннар,
Дөньялыкны баса бар сулар.

Актарыла гына җир төпләре,
Вулкан кайный, вулкан атыла.
Җитә икән аның утлы тыны

Көкнең ничәнчедер катына.

Ахырзаманда да исәнмен бит,
Бәлки, җирдә мин бер иблистер?
Туфрагымда мине тотып торган
Нинди генә көч бу, ни хистер?

Илаһмы син, көйче?
Елакмы син?
Гайрәт-кодрәтеңдә айкалам.
Тайфун йотты микән кояшны да,
Ярый әле күктә ай калган...

* * *

Алтын кояш. Алтын дөнья.
Алтын – аяк астында.
Алтын тәңкә сибә-сибә,
Көз дә кышка ашыга.

Килгәнсең миңа ашкынып,
Сөзләрең алтын гына.
Ишек артында калдырган
Дәрәҗәң салкын гына.

Язың, җәең башканыкы,
Булсын миңа көз генәң.
Бәлки, көздер безнең бәхет,
Алтын – минем теземнән.

Алтын сәгатең ашыга,
Кадерле һәр минутың.
Шушы «сөю» шәрабы да
Булды куйды бер йотым.

Барысы да аңлашыла,
Алтын хыялым бушка.
Алтын сәгать, син көпсенмә:
Көп калмады ла кышка.

Алтын кояш. Алтын дөнья.
Тик бер сулыш – алтын көз.
Ишекне кага дәрәҗәң:
«Беттеме, – дип, – сөзегез?»

## Җыр

Соңгы җырым, булма син соңгысы...
*Нажар Нәҗми*

Иң соңгысы була калсаң, җырым,
Дәвам итче йөрәк тибешем,
Сиңа ышандырам гомеремнең
Яшәлмичә калган өлешен.

Ә яшәлгән көннәр, айлар, еллар
Миннән сиңа акыл булырлар.
Шулай дәвам итә гомерләр дә,
Шулай дәвам итә буыннар.

Хыяллардан көңел суынмады,
Мин яшәүдән өмет өзмәдем.
Өзелә-өзелә,
Кеше күзләреннән
Сине, җырым, сине эзләдем.

Иң соңгысы булсаң да син, җырым,
Яшәү чыңы булыр һәр сүзең.
Соңгы булсаң да син, соңламый кил,
Каршыларымын сине берүзем...

Калдырамын сиңа сөюемне,
Шатлыкларны сиңа бирәмен.
Үз телемдә үзем җырлаган җыр,
Синдә тибәр минем йөрәгем.

* * *

Арага дошман төшмәде,
Дуслар да кермәделәр.
Араны кем бутаганны
Алар да күрмәделәр.

Үзем генә беләм ничек
Бикләдең син төрмәгә.
Рәшәткәләр аша багам
Көн яктысын күрмәгә.

«Ризык китерсә иде» дип
Теләмим мин теләкләр.
Бакчамда туңып яталар
Сиңа дигән җиләкләр.

«Йөзе якты булсын илдә!» –
Дип теләдем шым гына.
Сине яраттым мәңгегә –
Бар гөнаһым шул гына.

Китереп тыкты төрмәгә
Куркаклык – синең җәллад.
Үземне җәлләмимен мин,
Утырам сине җәлләп.

* * *

Мин яшердем сине шигыремә
Яман күздән, ялган сүзләрдән.
Мин үзгәрдем еллар басымыннан,
Мәхәббәттән генә үзгәрмәм.

Сабый чактагыдай тугры җан мин,
Калдымы соң шундый якының?
Сабырлыклар бирде еллар дисәм,
Әй дөрли дә китә ялкыным.

Шигыремдә яши синең рухың,
Ә калганын инде кем белсен...
«Ул – минеке» диеп, әллә кемнәр
Сөенсәләр, әйдә, сөенсен.

Рәнҗеттермәм сине гайбәтләрдән,
Мин акылга инде утырдым.
Шигырьдә дә ләкин тынгы булмас:
Ялкынланып янган ут-җырым.

## Мәңгелек моң

*Абдулла Солтановка*

Җырлыйсың син басып кыя ташка,
Агыла да җырың агыла.
Урманнарның эчен айкап өтә,
Елга өсләрендә кагына.

Җырлыйсың син басып кыя ташка –
Көкрәкләрен киереп, ир җырлый!
Ир-ат сагышына төзалмыйча,
Урман-суы белән җир җырлый!

Мондый сагыш, мондый моң-зарларны
Ир йөрәге ничек көтәрә?
Җырлыйсың син басып кыя ташка,
Уем белән ашам күкләргә.

Җырың ача миңа мәңгелекне –
Бик биектә очам, сафлыкта,
Тазарына барам гөнаһлардан,
Моң, туктарга, зинһар, ашыкма!

Җырың ача миңа быуатларны –
Моңнарыңа сыйган быуатлар.
Антлар кебек аһларыңны җаным
Соңгы сулышкача кабатлар.

Җырлыйсың син басып кыя ташка,
Җиһаннарны урап, җыр кайта.
Моңның кайтавазы, шәфәкъ булып,
Офыкларны каплый еракта.

## Ул кояшка китеп бара иде...

*Рәми Гариповка*

Ул кояшка китеп бара иде,
«Имеш, берәө дөнья көчәре,
Патшаларга баш бирмәгән була», –
Яраннарның ташты өчләре.

Җырлый-җырлый атлавында булды,
Арттан килеп аяк чалдылар.
Өз-өзеңнән баш тарт!
Идеалларын
Корбан бәйрәмендә чалдылар.

Ни тамаша?!
Нинди кызык анда?!
Искитәрлек тагын ни купкан?!

Кояшына китеп барган чакта,
Батырганнар аны тубыктан.

Буйсынмады!
Сынды...
Соңгы тапкыр
Кулын югарыга ул сузды;
Дошманнары дуска әйләнделәр,
Бары кояш аны юксынды...

Ул кояшка китеп бара иде...

## Рәшит Назаров

Тәкъдир тактасына язмышларны
Яза торган иҗат каләмен
Ходай миңа үзе биреп торды,
Галәм иде иҗат дәөмәлем*.

Шундый илаһи көч тойдым җанда,
Җир бишеген гүя тирбәттем.
Җиһан миңа шигырь генә иде –
Мин аларны җанда иңрәттем.

Пәйгамбәрлеккә юк дәгъваларым,
Раббым иңдерсә дә кальбемә.
Юлын юлга салып шигырьләрен,
Калдым пәйгамбәрем хәлендә.

Раббыма юк үпкә-рәнҗешләрем,
Тәмугка да үзе ташлады.
Кичермәде микән
Күрмәгәнгә
Шигърияттән гайре башканы.

Яшен яшьнәп алган бер арада
Кулда тоттым Ходай каләмен.
Сүзләремне яттан белә халык –
Мин серле бер аңга әйләндем.

## Очу

*(Рудольф Нуриевның биюен беренче тапкыр карагач)*

Малай идем, ач-ялангач идем,
Хәер сорашмадым, бар горурлык.
Бик очасым килде күк йөзенә –
Карасыннар миңа бер борылып!

Җирдә мин бар: малай гына үзем,
Эчтә бер көч бии, котырына.
Тамак кайгылары юк миндә, дип,
Уфалардан очтым Питерына.

Питерда да шул ук тормыш икән,
Чигәләрне кыса, шомга салып.

Питерыннан очтым Парижына –
Авыз ачып калды мәнсез халык.

Париж миңа кысан сәхнә икән,
Бик очасым килде дөнья иңләп.
Очтым, очтым, очтым дөнья иңләп –
Ул бәләкәй икән, гөя иләк.

Мин көктәмен, җирдәгеләр миңа
Карап тора сузып муеннарын.
Искә төште шулчак балачакта
Калган әремнәрем, муелларым.

Алар миңа хәзер алыс хыял,
Хыял артыннан мин җиргә төштем.
Бер аунасаң иде әремлектә,
Бер иснәсәң иде муел исен!

Мине монда әҗәл тарткан икән,
Ул чакырган икән хыял булып.
Көкне каплап алган кара болыт:
«Очуыңны, – диде, – хәзер оныт!»

Җаным ашты көккә мәңгелеккә –
Оч, дип кабул итте өрдәгеләр.
Тәнем гади – аны туфрак алды,
Бигайбә, хуш инде, җирдәгеләр!

## Дала

*Каләмдәшем Кадим Аралбайга*

Чал далалар буйлап атта чаптым,
Чаптым да бит, иңли алмадым.
Барган саен офык ерагая –
Офыклары чиксез даланың.

Дөрт ягың да кыйбла далаларда,
Бөтен тарафларга юл ачык.
Кымыз белән сыйлар һәрбер тирмә,
Чәй кайнатып көтә алачык.
Далаларның бөркө кояшына
Яна-яна, көчкә өйрәндем.
Чәчәк итеп алам кылганын да,
Таналыкның кылыч күрәнен.

Җилең иссә, аяклардан ега,
Кырыссың шул, дала, кырыссың.
Туфракларың көлгә әйләнгәндә,
Янып бетә кебек тормышым.

Көңелләрем Таналыгың белән
Һәр яз саен таша – тамаша.
Анда уңа икән игенең дә –
Ат белән дә кереп адашам.

Сузсаң сузасың син моңыңны да,
Кич башласаң – таңнар атканчы.
Ана күкрәгенә сөт төшкәндәй,

Коеларга сулар кайтканчы!

Мин хаҗ кылдым Аркайымга гына,
Борынгылык тора бөркелеп.
Тынлыкны бит көктә бөркет саклый:
Бернидән дә төгел өркерлек!

Дала иңнәрендә борынгылык
Кылганнарга яткан чаң төгел.
Сулар һавам, эчәр суларым ул,
Каннан канга күчкән саф күңел...

Чал далалар буйлап атта чаптым,
Чаптым да бит, иңли алмадым.
Иңли алмасам да, бу иркенлек
Алга әйдәр бәхет-даланым*.

## Ил агасы

*Хөрмәтле академик Гайсә Хөсәеновка*

Кайгылардан йөрәк сыкраганда,
Бәрә-бәрә күкрәк төрләрен,
Ил агасы-ирләр елый микән,
Белсәң иде шуның серләрен.

Аркаларга пычак кадаганда,
Яшеренеп килеп көнчеллек,
Ил агасы-ирләр елый микән,
Куя микән әллә күрсенеп?

Көлемсерәп кенә куя микән,
Ваклык белән бер дә вакланмый.
Ирмен дигән ирләр илне саклый,
Үзен генә ләкин сакламый.

Кайдан көч табадыр агайларым,
Дошманы да көчле көчленең.
Көрәш мәйданында тик батырлар
Данга күмә халык исемен.

Уттан исән чыккан батырны да
Әйләндерә шул дан камырга.
Әйтегезче, олуг көенчә дә
Кеше булып ничек калырга?

Сезнең күзләр белән тарих үзе
Киләчәккә төби күзләрен.
Әйтегезче, сезнең йөрәгегез
Шушыларга ничек түзгәнен?

Һәр сүзегез, ахры, яралгандыр
Мең-мең сынау үткән халкыңнан.
Ил улының бөртек күз яше дә
Кадерлерәк бит ул алтыннан.

## О, Венера!

*Хөрмәтле Венера Мидхәт кызы Хәкимовага*

О, Венера!
Борынгылар сиңа
Алиһәбез диеп табынган.
Синең мәрхәмәткә ышанганның

Өз бәхете җирдә табылган.

О, Венера!
Синең исемең дә
Кадерлерәк булган алтыннан.
Таң калып та синең чибәрлеккә,
Язганнар, ди, хәтта акылдан.

О, Венера!
Рәссам кешелеккә
Бөләк иткән синең сыныңны.
Гасырлардан шулай гасырларга
Дәвам итәсең син юлыңны.

О, Венера!
Синнән төшкән нурдан
Бакчаларда пешкән алмалар.
Синнән төшкән таң яктысы белән
Дошманнарын җиңгән аллалар.

О, Венера!
Бүген дә син шулай:
Үзең матур, үзең акыллы.
Йөрәгеңнең ялкыннары белән
Нурлап яшисең син халкыңны.

## Динис Бөләковның
## якты истәлегенә

Менә әле, әле генә кебек
Сөйләшәләр икәү:
Син дә мин.
Сиңа тиң дә булмаганмындыр мин,
Булганмындыр, бәлки, тиң дә мин.

Соңгы телемеңне көлә-көлә
Бүлеп бирә идең башкага.
«Рәхмәт, сылу,
шулай идем шул», – дип,
Әрвахың еш миңа баш кага.

Көч-гайрәтең ташып тора иде,
Яратканга олы-кечене.
Безне сынар өчен
Әҗәл ала
Иң кадерле генә кешене.

Риваятьләр йөри телдән телгә:
Таң калдыра синең егетлек.
Син киткәчтен мәңге кайтмас җиргә,
Кояшның да чите гел китек.

Дөньябыз да төп-түгәрәк түгел –
Китекләрен булмый һич ямап...
«Кайгырмагыз әле!» – диеп,
Көлә-көлә
Син алырсың кебек кочаклап.

## Алма җыя хатын

*Хөрмәтле профессор*
*Фәрзәнә Сәгыйтовага*

Җырлый-җырлый алма җыя хатын,
Биек ботакларга өрелеп.
Җыры алысларга киткәнгәме,
Әллә каян тора күренеп.

Булгач була икән мондый уңыш –
Күтәралмый сына агачы.
Өйрәнгән шул хатын эш эшләргә
Беләкләре тәмам талганчы.

Йөзләре дә пешкән алмамыни,
Күз тимәсен генә үзенә!
Җырлый-җырлый алмаларын җыеп,
Кереп бара хатын күзенә.

Язларыннан кояшлырак күзе,
Алмалары нинди хуш исле!
(Өкенечләр кемдә генә булмый?!
Көзге җилдәй, алар үткенче...)

Алма җыя хатын –
Алмага да,
Хатынга да карап туймыйсың.
Аның хөрмәтенә күзнең гөя
Скрипкада килә уйныйсы.

* * *

Кичерә бел, димен, кешеләрне,
Тау илендә кыя данлана.
Эссе җилгә
Ачык далалардан
Урал кыяларын даулама!

Кичерә бел, димен, кешеләрне,
Мираж гына таулар далада.
Йөрәгеңә яткан кыялардан
Дала киңлекләрен даулама.

Кичерә бел, димен, кешеләрне,
Серен чиштем, димә, урманның.
Кара урманнарны кисә-кисә,
Серләренә генә уралдым.

Кичерә бел, димен, кешеләрне,
Кем күргән соң төбен диңгезнең?
Сиңа диңгез бары хыял гына,
Төгел бит ул җандаш игезең...

Кичерә бел, димен, кешеләрне,
Үз-үземә әйтәм кабатлап.
Хакыйкать ул – синең миһербанлык,
Син дә төгел ләкин актан-ак!

## Синең тавыш

*Яраткан актрисам*
*Илсөяр Гыйзетдиновага*

Мин үземне-үзем югалтканда,

Өзең белми мине табыштың.
Алиһәләр генә дөньясына
Гел чакырып торды тавышың.

Сәхнә-экраннанмы, эфирданмы
Чыңлап-зыңлап китсә тавышың,
Онытыла барлык хәсрәтләрем,
Онытыла әрнө-сагышым.

Йөзең нурлы, җырларың да нурлы,
Бер гөнаһсыз синең тавышың.
Саклар өчен шушы сафлыкны, син
Тормыш белән көпме алыштың?!

Көкләргә көз терәп ялварамын
Мин – бер гади генә танышың:
Ташламасын мине матурлыгың,
Ташламасын мине тавышың!

## Эчәмен әрем суын

Әрнөләрне басар өчен
Эчәмен әрем суын.
Җиргә, суга, һаваларга
Юк рәнҗөем, ачуым...

Шайтанны аңлыйм әле дип,
Тигәнәклектә ауныйм.
Пәри булып күренәмдер,
Ансын өзем дә аңлыйм.

Каннар тама учларымнан,
Йөрәктән каннар саркый.
Рәнҗешләрне онытырга
Ничек булырга сантый?

Туфрагыма төгелсә дә
Көпме кайгы, көпме кан,
Ап-ак булып ромашкалар
Быел да чәчәк аткан.

Минем кешелегемнән дә
Торадыр көкләр имин.
Минем дә бит көңелемнән
Сулар сафлана, димен.

Минем дә бит өметемнән
Өләннәр калка язын.
Юкка төгел һәр сулышым,
Юкка төгел һәр адым.

Мин дә балчыктан яралган,
Көйдергән мине кояш.
Кирза итек изгәндә дә,
Мин бит җиремә охшаш –
Игеннәр өскән җиремә,
Җимеш биргән туфракка.

Каралтмакчы булсалар да

Салып мине пычракка,
Ишетелә мәңгелектән
Кош сайравы колакка.

## Соңгы чара

Офык артларында яңа офык –
Актык көчең туплап барып кара.
Ерак түгел ара, ерак түгел,
Яңа офык булса соңгы чара.

Упкын төпләрендә яңа упкын,
Аска имә башың, күккә кара!
Теш-тырнагың белән җиргә ябыш,
Упкын әйтсә:
«Мин, – дип, – соңгы чара!»

Яраларыңны да ача күрмә,
Яра эчләрендә яңа яра.
Кояш нуры, көннең яктысыдыр –
Яраларны басар соңгы чара!

Бәхет, мәхәббәткә соң түгелдер,
Вакыт туктамаган – алга бара!
Озынайтса икән гомереңне
Соңгы сулыш,
соңгы адым,
соңгы чара.

## Кара каен

Җырларыңда моң-зар күп.
*Дустымның әйткәне*

Уралымда кара каен сирәк,
Сирәкләрнең, ахры, мин берсе.
Кайгы төсләрендә булсам да мин,
Шырлык эчендәге сер төсле.

Мин шәүләсе түгел ак каенның,
Кояш тарта, тарта болытлар.
Охшамасам әгәр,
Кичерегез,
Мин туганмын шундый булыплар.

Эчәр суым, сулар һавам бетеп
Тусам да мин әгәр киредән,
Барыбер дә үз төсендә итеп
Яралтачак мине җир генәм.

Тамыр җибәргәнмен тармак-тармак,
Яраларын ямап җир-суның.
Күпме сызлансам да,
Каралыгым,
Юк, билгесе түгел коруның.

Урман якты ап-ак каеннардан,
Көкшел таулар, зәңгәр һавалар.
Көңелегезгә шомнар сала калсам,
Ак каеннар сезне дәвалар.

## Ауды имән

Ауды имән,
Ул гөрселдәп ауды:
Ташлар тәгәрәде кыядан.
Имәнме соң инде давылларда,
Бураннарда өзен аяган?!

Ул өзеннән-өзе кинәт ауды,
Кисмәде дә беркем, чапмады.
Урман патшасыдай, көкрәк киереп,
Колач җәеп өсәр чаклары.

Яшен дә юк, яшьнәми дә әле –
Сукты дисәң әгәр яшеннәр.
Дөнья элеккечә:
Айлы төн яшь,
Таң атканда нинди яшь көннәр!

Ауды имән,
Аумас чакта ауды,
Чатнагандай җирнең калканы...
Кайтавазы тынды...
Бу дөньяның
Сап-сай елга кебек акканы.

## Юксыну

*Әдип дусларымның якты истәлегенә*

Көләгәсе калмый яктыларның,
Кала бары һәйкәл-сыннары.
Шалтыратам...
Бармакларым җыя
Мине гел юаткан саннарны...

Кемне уйласам да – шул юк инде,
Талантлылар, гади, көчлеләр!
Кәрләләргә әверелгән кебек
Булып калды миңа кешеләр.

Кечерәйтеп була, зурайтып та...
Кирәк икән, була шартлатып. –
Бөтен дөнья өрмәле шар кебек.
Карап торам шуңа шаккатып.

Шалтыратам,
Ни кылырга, диеп,
Кыюлыгым никтер чикләнгән:
«Хаксыз булсам,
Коткарыгыз, зинһар,
Миңа богау салган шикләрдән».

Шалтыратам,
Тавыш бирегезче!
Тынлыкның бит миндә юк эше.
Төннең көзе – тулган аем гына

Дәшә кебек:
«Суын, әй, Кеше!»

## Туган көнемдә үз-үземә

Көчле кешеләр дә картаялар,
Яңа әйберләр дә искерә.
Яңа елда яңа өметләрдән
Күкрәкләргә илһам, көч керә.

Ниләр булган әле, картайсам ни,
Ниләр булган әйбер тузганнан?
Үз вакыты җиткәч, нурга тулып,
Гөл ярала туфрак-тузаннан.

Матур кешеләрнең күңелендә
Мин дә яраламдыр яңадан,
Язмышыннан балкып узган өчен,
Узган өчен хыял-аңыннан!

Бу юату түгел үз-үземне,
Бу – яшәвем минем, ак көнем.
Гасырларга тиң бер гомер кичтем,
Сабыйлыкка кайта күңелем.

## Кош юлы

Дөньям куыш әле.
Әрем куыш.
Ә мин үзем – сабый кыз бала.
Төнге күккә багам куышымнан,
Нурын сирпеп, йолдыз кузлана.

Кузлана бит әнә Кош юллары,
Белгән юлым минем шул гына.
Сәфәрләргә мине кем чыгарсын,
Урман-таулар юлы шом гына...

Ирәмәлкәй – эче алтын сарай,
Табучы бар микән ачкычын?
Җирдән генә аны эзләмичә,
Нигә биеклеккә ашкындым?

Кызганма син,
Әрем куышында
Балачактан баккан кыз бала,
Алтын сарайларны ача алмый,
Гомеркәем инде тузганга.

Ә Ирәмәл күккә тарта һаман,
Болыт – аста, җиһан ачыла.
Җиһан белән күзгә-күз караша
Мәңгелеккә монда таш кына.

Кызганма син мине,
И кыз бала,
Тау башыннан якын Кош юлы.
Кыя ташта ләкин тайгаграк шул,
Барган юлым инде – кыш юлы.

## Ялгызлык

Яннарымда халык кайнашканда,
Ялгызлыкны тоям шул ныграк.
Җирдәгеләр җиргә сеңдерәләр,
Ә йолдызым минем нык ерак.

Төргә сеңдерәләр төрә итеп –
Төр булса да, барыбер җир инде.
Бәхетсезгә мин бәхетле кебек,
Япа-ялгызлыгым сер инде.

Ерактагы кояш яктырак, ди,
Ерактагы йолдыз серлерәк.
Серен ачар өчен гомер җитми,
Бер гомеремә – шул бер йөрәк.

* * *

Өйрәнелгән, күнегелгән дисәм
Синең кырыслыкка күптәннән...
Димем әнә калын боз катламын
Дулкыннарга салып күтәргән.

Шигъри түгел дисәм сагышларым,
Сүзләремнең дисәм чәчмәсе,
Шәмнәр кебек яна алмагачым,
Ялкынлана бара чәчкәсе.

Мәхәббәт ул миңа насыйп түгел
Дисәм дә мин, өзеп өметем,
Мин күргәнне син дә күрәсеңдер –
Язны күрми ничек ул мөмкин?
Бербөтен без, барыбер бербөтен.

Алмагачтай тагын ялкынланам,
Хисем ярсый тагын Дим сыман.
Вакыт мине бары сагынган ул...
Елмай инде миңа көн сыман.

* * *

Сабый бала сыман,
Күкрәгемә
Башың салдың –
Сөйдем чәчеңнән...
Мин уяндым,
Яшен суктымыни:
Мәрҗән тойгыларым чәчелгән...

Сибелешеп җирдә ята алар,
Өлгермәдем сиңа әйтергә.
Ә түшемдә иң бәхетле мәл, дип
Салып кына куйдым хәтергә.

Төшләремә керде теләгәнем,
Китми һаман, китми төнемнән...
Шул төшемә кереп качар идем
Һәм уяныр идем өнемнән.

Өбәр идем айның яктысында
Ай нурлары кебек чәчеңне.
Чарасызлыктан мин чакырамын
Дөньяларны айкар яшенне.

* * *

Тукта, Скрипка!
Җитәр, җитәр!
Уйнамачы!
Йөрәк арыган.
Минем җаным кылыңнан да нечкә, –
Мирас итеп сиңа калдырам.

Ә әлегә бик яшисе килә,
Әй кадерле миңа таң нуры.
Тукта, Скрипка!
Нервым җитми,
Өзелмәкче каным тамыры.

Бураннарда мин бит сабыр идем.
Язмы өзлектерде?
Ник дәшим –
Моңнарыңа кушылып ургылганда,
Җыелып килгән ачы күз яшем.

Ярдан чыгып ташкын, ургып-кайнап,
Җылы тоеп, бөре тулыша...
Тукта, Скрипка!
Өзгәләнмә,
Моңың каплана бит сулышка.

Син уйнарсың
Ләйсән явып өткәч,
Таралганда язгы җир исе,
Син уйнарсың,
Тәөге яшен яшьнәп,
Ачылганда каен бөресе.

* * *

Төнге күктә ай мөлдери,
Кемнең икән күз яше?
«Синең өзеңнең яшь бит ул! –
Җаным шулай эндәште. –

Әйтмәсәң дә күрер әле
Күз яшеңне син сөйгән.
Синең әрнүеңне сизеп,
Кайгыдан кара көйгән...»

Җаныма өзем сер чиштем:
«Син генә ташлап китмә!
Өзем җирдә өксесәм дә,
Күз яшем нигә күктә?»

«Өзеңне таныр өчен ул
Төгәрәк, якты, биек!
Күз тутырып карап калчы,
Күктән ул таммас элек».

## Ут эчендә бию

Кар өстендә учак кабыздык без,
Ул күкләргә ашып дөрләде.
Көткән икән, көтеп торган икән
Тыннарыбыз белән өргәнне.

Ялкын белән бергә биеп киттең,
Ыргылдың да учак эченә.
Син үзең – ут!
Җирдә бер ялкынның
Көче җитми синең көчеңә.

Биисең син бары минем өчен,
Күзләремнән минем күз алмый.
Әллә соң син Ут алласы микән,
Син илаһи, җаным, Алладай.

Ялкын эчләренә мине дә ал,
Булыйк әле, җаным, бербөтен.
Ялкынында тормыш, салкынында
Икебезне бергә биетсен!

Төш түгел бу, бөтенесе дә чын,
Иреннәрем тия иренгә.
Гомеребез яна бер учакта,
Җаныбызда тормыш терелә.

* * *

Күктәй төпсез фәлсәфәләр
Эзләмичә көннәремнән,
Әллә кая китеп барам,
Качам соң мин кемнәремнән?

Күңелдәге җәйләрне дә
Килми, килми кузгатасым.
Күзгә ачы җил сызгыра.
Аңлый микән үз хатасын?

Сызгыруы, билләһи, дим,
Кара җирне ярыр кебек.
Әллә кая китеп барам –
Үзем болай сабыр кебек.

Алтын түгел сары яфрак –
Хәзер инде мин акыллы.
Яндырса да таман миңа,
Тик саргайта күз ялкыны.

Яндырса соң ниләр булган,
Мин яралыр идем көлдән.
Әллә кая китеп барам

Шундый көндәм,
Шундый көндәм.

* * *

Кулым бармый
Шушы карт чияне
Бакчабыздан алып ташларга...
Тамырлары,
Яшәү генә эзләп,
Чат ябышты микән ташларга?

Әйләнәм дә килеп сугылам мин,
Җанымны ул өрти ни вакыт.
Сокландыра үзе иртә язда,
Чәчәкләре белән гөлт балкып.

Кояш сутын җыйган җимеш белән
Тулмаса да сыңар чиләгем,
Өйрәнгәндәй тешнең сызлавына,
Карт чиягә күптән күнгәнмен.

Җимешләре күбрәк иң очында –
Ят кошларга хөрмәт, сый-бәйрәм.
Буем җитми,
Буем,
Чия, ахры, миңа чит, хәрәм...

Кулым бармый, күпме омтылсам да
Төпләп ыргытырга чияне...
Җанга тамыр җәйгән сыныңнан да
Читләшәсем килә, сөйгәнем.

* * *

Буйсынганда кемнәргәдер буй-сыннарым,
Рухым белән буйсынмадым, мин сынмадым!

Уй югары – баш иелгән җиргә табан,
Күңел күктә – әрем йолкам үзем һаман.

Сырганакка сарыламын – «ефәк» кием,
Җир белән күк арасында минем көем

Яралы бер кош шикелле бәргәләнә:
Йолдыз коча, үкси ятып әремнәргә.

Чит кеше мин мәрмәр сарай эчләрендә
Барчасына – хистәш тапмый хисләремә,

Уйларыма уйдаш тапмый чыгып китәм,
Кирәк миңа кемдер бөтән, нидер бөтән.

Буйсынганда кемнәргәдер буй-сыннарым,
Рухым белән буйсынмадым, мин сынмадым!

Ачылганда офыкларның офыклары,
Кояш-айдан эзлимен мин ышыкларны.

Атлаганда киңлекләрдән киңлекләргә,

Вакыт сыймый сәгатьләргә, тәүлекләргә.

Гомерем дә, сыя алмый вакытларга,
Бәргәләнә-өзгәләнә ваклыкларга.

Мең гөнаһлы җир йөзендә калсын миннән,
Танырсыз сез шулчак мине шаһинәдән.

* * *

Мин кыяга мендем,
Аркан итеп
Ташка бәйләдем дә төземне.
Мендем дә бит,
Тормыш әнә җирдә, –
Аның белән ара өзелде.

Тез буынын дер-дер калтыратып,
Чаялыгым сыный өземне:
Кыяда да менә караңгылык –
Кояш чагылдыра күземне.

Бер ташына торам тотынып мин,
Аякларым тая, кул тая.
Нигә кирәк кырыс бу омтылыш,
Нигә кирәк ырыс – бу кыя?

Таянычым булыр дигән идем,
Бөркетләрем кая киткәннәр?
Мине батыр яки бахыр диеп,
Әкияткә качып беткәннәр.

Файдасы юк минем өҗәтлекнең –
Аякларым ташка орынды.
Табармынмы? –
Кояш хозурына
Эзләп менгән идем җырымны.

## Көлөем

Челтерәтеп көлеп җибәрдем мин,
Учлап сипкән кебек көмешләр.
Җил йөгерде, колын кешнәп куйды,
Кушылдылар миңа инешләр.

Кушылдылар миңа кигәвеннәр,
Бал кортлары очты чәчкәгә.
Чылтыратып көлеп җибәрдем мин
Үз-үземә җәйге сәхрәдә.

Ишетелде микән көлөләрем –
Кояш чыкты болыт артыннан.
Гомер биргән шушы көн алдында
Чырай бозарга мин тартынам.

Көлөемнең кайта кайтавазы,
Урап-урап ерак офыктан.
Сәфәрләре уңар –
Әнә берәү

Бәхет артыннанмы юл тоткан?!

Каршыма ук килеп чыгар болан,
Табигатьнең, диеп, көзе мин.
Алтын шатлыгымнан көләмен мин,
Баллы гына җәйнең өзе мин.

* * *

Аңлыйсыңдыр мине,
Көн буена
Скрипка тарткан чуак көз?!
Апамы син миңа, сеңелме син,
Серләшик бер икәө көзгә-көз.

Гел яшеннәр белән яшьни-яшьни,
Ничә яшемне мин туйладым?!
Апамы син, көзем, сеңелме син,
Барыбер мин – синең кунагың.

Өтә җете соңгы чәчкләрең,
Кыйммәтлерәк соңгы нигъмәтең...
Вакытларны ашыктырмак булып,
Йөрәгемне менә имгәттем.

Бәхет – алда, диеп алданырга
Нигә икән көңел көнеккән?
Соңгы чәчкәң, көзем, чәчәк аткан –
Вакыт җиткән, димәк, көн җиткән.

Акылым да бер имгәнер иде,
Сөзләрем буш булса әгәр дә:
Бар да алда диеп алданудан
Коткарасың син, көз, гамәлдә.

Апамы син, көзем, сеңелме син –
Анысын белә Ходай Тәгалә.
Скрипкаң синең бигрәк моңлы,
Ишетелә гаме галәмгә.

* * *

Яшен мине тагын эзләп тапкан,
Качкан булсам да тау арасына.
Сыннарымда – кыя горурлыгы,
Төн тынлыгы иде карашымда.

Ярсы, ашкын, тормыш, дигән идем,
Миннән башка гына, миннән башка.
Яшен мине тагын эзләп тапкан,
Көкрәп тора таулар, дәрья таша.

Шаулап сына олпат имәннәр дә
Кара урманнарның куенында.
Яшен ерта көннең, төннең йөзен,
Тагын калдым тормыш коенында...

Урманнар бар җирне саклашырга,
Кыялар бар көкне терәшергә...
Яшен мине тагын эзләп тапкан,
Мин кирәктер аңа көрәшергә.

## Алтын таҗ

Гәөһәрләре күзнең явын ала –
Патшабикә кигән алтын таҗ.
Кеше көңеленең нечкәлеген,
Нәфислеген саклый Эрмитаж.

Ә останың хыял биеклеге
Таҗда гына түгел, таста да.
Өпкәләре генә күренә шул,
Авызларын гына ачса да.

Нәфес белән нәфислекнең монда
Тигез тартмыйдыр шул бизмәне:
Һәр останың алтын гомередер
Патшабикәнең һәр бизәге.

Әй син Вакыт галиҗәнаплары!
Хакимгә дә гадел хөкемең.
Кабереңдә – нәфес.
Нәфислеккә –
Аткан таңың,
Алтын һәр көнең.

* * *

Куанычтан кычкырамын,
Тел торса да тотлыгып:
«Авырудан котылгандай,
Синнән менә котылдым!»

Дәрәҗәләр алдында син
Телсез, чукрак, сукыр да.
Начар китап булсаң, сине
Ташлар идем – укыр да.

Яхшы китап та түгелсең –
Түр башында сакларга.
Туры килде ләкин миңа
Һәр сүзеңне ятларга.

Туры килде һәр сүзеңне
Юарга яшем белән.
Йөрегән җырләреңне мин
Себердем чәчем белән.

Үткәннәрем калсын синдә,
Иярмәсен артымнан.
Әгәр син бер дан булсаң да,
Әйтер идем: артык дан!

## Дала туне

*Йомабикә Ильясовага*

Күкрәгеңә башым салып кына
Бер елыйм әле мин, ак далам.
Чәчәк-үлән күпме...
Кылганнан да
Кадерлесен ләкин табалмам.

Тын аласың, далам, көкрәк киереп,
Айлы төнең серле, күгелҗем.
Күкрәгеңә башым салып ятсам,
Тынгы табар төсле күңелем.

Йолдызларың синең якты, биек,
Кызык төгел миңа якыны.
Кызган башларымны суындыра
Әрем исе килгән салкының.

Тынлыгыңнан, далам, исерәм мин,
Төнең үзе – көмеш сабырлык.
Эзләп-эзләп көндез тапмаганны
Төннең тынлыгыннан табарлык.

Ай нурында мин ачыграк күрәм
Синең җаның, синең түшеңне.
Гүя сине кояш көйдермәгән,
Тузан капламаган өстеңне.

Сиңа, далам, сирәк төшкән бәхет –
Чыклар белән юдым битемне.
Әллә кемнәр салган яра өчен
Мин белмәгән дала кошы миннән
Төн буена гафу үтенде.

## Көнем белән төнем

Ике аккош очты кулларымнан,
Берсе – ап-ак, берсе – кап-кара.
Талпыналар күксел тау артына,
Туктатырга инде юк чара.

Юл чатына чыккан кыз баладай,
Артларыннан мин дә тартылам.
Очар канатларым булмаса да,
Күңелләрем белән талпынам.

Аккошларым, калдырыгыз миңа
Каурыйларыгызның карасын.
Аккош җыры итеп языйм әле
Йөрәгемнең кара ярасын.

Аккошларым, каурыйларыгызның
Бүләк итегезче акларын.
Аһ итәрлек шигырь языйм әле,
Бетмәс микән газап-аһларым.

Сезнең горурлыкка лаек бер моң
Мин табармын әле, аккошлар.
Оча алар...
Көнем белән төнем –
Бер күренеп калган балкышлар.

* * *

Чоңгылларга чумып алып чыктым
Кыйгак кына казның каурыен, –
Төшкә керә шулай сабый чаклар,
Тик сабыйлык белән авырыйм.

Чоңгылларда калган кара казан,
Сәрмәсәнем тавык кичәрлек.
Кипкән елга, кара елан булып,
Юлларыңны, Кешем, кисәрлек.

Атар таңга юлны киссә дә ул,
Өз-өзенә генә өпкәләр...
Канатларын әнә нгытырга
Дулкын таба алмый бәбкәләр.

Җир назлары, су назлары тулы
Бала чагым һаман исемдә.
Язгы ташкын кебек ярсу булды
Нәфрәтем дә, сөю хисем дә.

* * *

Сиңа тагын ниләр кирәк, язмыш?
Гөнаһларым өчен түләдем
Күзләремә кайтмас яшьләр белән, –
Шул идеме иң зур теләгең?

Чишмәләрдән сулар киткән кебек,
Күзләремнең яше корыган.
Исбатларга тырышма да, язмыш:
«Ак-карадан тормыш корылган».

Караңгыда мине калдырам дип
Уйладыңмы?
Шулмы хыялың?!
Күз-яшь коймасам да,
Хисләремне
Ап-ак чишмәләргә коямын.

Күз яшьләрем корыганнан бирле,
Җанда калды тозның ачысы.
Хыянәтчем,
Сиңа төште, кичер,
Күз яшемнең соңгы тамчысы.

* * *

Дошманыма рәхмәт инде!
Ул көнләшкән саен үсәм:
Вакытымның кадере арта,
Башым чыкмый минем эштән.

Дошманыма рәхмәт төшсен!
Гел күзәтеп уяу тора.
Гамьсезлектән оеп китсәм,
Әл дә ул бар уятырга!

Дошманымны хөрмәт итәм,
Аңлаганга минем көчне,
Юлларымны кискәндә дә
Кара елан булып үче.

«Дошманыма дан!» – димен мин,
Булмаганга икейөзле.
Матурлана барам һаман,
Чөнки миндә ике көзе.

## Шомлы төндә

Бу төнемне ничек өткәрергә?
Поезд тыкылдавы якында
Дулкынына салып тирбәтә көк,
Көйли кебек бәхет хакында.

Өз җаена гына көйли бирә,
Тыкылдавы шундый тип-тигез.
Юк, әйтмимен:
«Бәхет илләренә
Мине дә, – дип, – алып китегез!»

Самолетлар оча әллә кая,
Тавышлары – биек бер өмет.
Чакырмагыз мине, әй, очаклар,
Чакырмагыз алай өзелеп.

Таң атканчы бикле минем өем –
Өзем бикләп куйдым төрмәне.
Беркая да ашкынмыймын әле –
Башкынаем ниләр күрмәде?!

Көнегелеп бара шомлы төнгә,
Өр-яңадан чыкмас Чулпаным.
Ишетмимен йөрәк кагышымны,
Тыңлыймын мин сәгать сукканын.

## * * *

Сиңа сөзем кирәк түгел,
Сиңа өзем кирәк түгел.
Мине түгел, башкаларны
Эзли бугай синең күңел.

Кирәк түгел!
Мин аңлыймын!
Беләм мине ташларыңны.
Кирәк түгел!
Кара ташка
Бәрмим әле башларымны.

Эзли-эзли юл йөрерсең,
Түгелерсең, сибелерсең,
Тапкан башкаң гади булыр...
Мине эзләп тилмерерсең.

Минем кебек гади булыр –
Ялкыннары ялмый алмый.
Биекләр ул тик хыялда,
Безне хыял һәрчак алдый.

Шулчак сөзем кирәк булыр,

Шулчак өзем кирәк булыр,
Көңелләрең тулар, тулар,
Ә хисләрең дулар, дулар.

Тик мин булмам синең янда,
Йөзем балкыр берәр таңда.
Хыялыңнан – бик ерактан.
Мин бит сиңа – бик ерак таң.

## Алтын сарай

Балачактан бәп-бәләкәй өйдә
Буй җиткердем, канат ныгыттым.
Әкияттәге алтын сарайларны
Мин күптәннән инде оныттым.

Куыш эчендә дә яшәдем мин,
Җил җилләтә аны тиз генә.
Юллар таптым көннең чыгышына,
Киекләрнең карап эзенә.

Сукмак салдым көннең баешына,
Уралымда өлән ырымлы.
Юл күрсәтте әрем исе миңа,
Әрем – җирем кебек борынгы.

Юлга алып чыкты кычытканнар,
Кычытканга инде ни дисең?
Яраталар, ахры, гөлдән бигрәк...
Тик бу хакта килми сөйлисем.

Әкияттәге алтын сарайларны
Тик килмәде һич тә онытасым.
Куышларны ташлап чыгып китеп,
Язмышымны килде отасым.

Оталмадым инде язмышымны,
Мин һаман да әрем куышта.
Өкенерлек түгел, бер уйласаң:
Сандугачлар таңда сөз куша.

## Йолдызлы шәл

Кышлар озын.
Кайтмый озакладың.
Көтәм һаман... Күпме көттердең?!
Өксез ак бураннар өксегәндә,
Ап-ак бер шәл бәйләп бетердем.

Сайлап алып бөләк иткән идең
Якты төннең йолдыз сәйләнен.
Күңелдәге аның балкышын мин
Йолдызлы шәл итеп бәйләдем.

Куаныч та миңа, юаныч та –
Йолдызлы шәл генә, кадерлем.
Җан ачысы белән өкси буран –
Уртасында дулый бәгырьнең.

Әллә нигә буран кочагында
Ак сыныңны мин еш шәйләдем.
Эзлим диеп аны атлыксам да,
Сабырлыклар бирә ак шәлем.

Сиңа җиткерер дип сиптем әле
Ак буранга чәчәк бәйләмен:
Өксез ак буранның өксөендә
Сиңа дигән сагыш-сәламем.

Йолдызлы шәл салам иңбашыма,
Туңасыңмы син дә, сөеклем?
Сагышларга мин дә төзәр идем,
Буран өксемәсә шултиклем.

## Бакчадагы өйдә ялгызым

Зәңгәр сандык та ап-ак мич,
Башка берни юк өйдә.
Иремнең бер эш көлмәге
Эленеп тора чөйдә.

Киләм дә сыенган булам
Өемдәге шул мичкә.
Әллә нинди шик-шөбһәләр
Яшеренгән мөешкә.

Эчтәге сагыш бөресен
Улатасым килмичә,
Акыртамын радионы,
Нишләргә дә белмичә.

Гәзит тә укыйсы килми –
Алдыйлар алар күптән.
Китаплар укый-укый да
Язып барам өметтән.

Кара төндә җил сызгыра –
Җитми иде шул гына.
Радиоалгычны туктатып,
Тыңлап торам шым гына.

Тәрәзгә торам текәлеп –
Еракта ут күренә.
Күренөен күренә дә,
Охшаган ул бөрегә.

Ялгыз каласым юк бөтән,
Исән булсын баш кына.
Балта салып куйдым әле
Караватым астына.
Өз-өземнән көләрмен бер,
Атсын әле таң гына...
Кемнәр уйлый икән мине,
Кемнәр икән сагына?!

* * *

Өткән көннәр миңа көндәш төгел,
Бөгенгеңә килми көнчеллек.
Синең тормыш, минем тормышым да –
Йокысыз төн, сукыр өч тиенлек,
Аерма юк бездә, өстенлек...

Данбикәң дә миңа көндәш түгел,
Укалары бик тиз коела.
Ни кылырсың, шәрә торып калса
Бөтен галәм килгән җыенда?

Беркем, берни миңа көндәш түгел,
Мин тилмергән, мин бит тилергән.
Яулап алам сине бар дөньядан,
Яулап алам сине үлемнән:
Кулымнан да килә, теләмнән.

Мин күтәрмәс яра җирдә юктыр,
Үзем – оҗмах, үзем – тәмугтыр.
Яулап алам сине үз-үзеңнән,
Җаным – шагыйрь, рухым – алыптыр,
Син дә мине шулай танып тор!

* * *

Кояш батты...
Сагыш артты,
Артты кебек гөл күзендә.
Шәфәгы да сүнә бара,
Ниләр булыр төн йөзендә?!

Сөю батты...
Коенамын
Аның соңгы шәфәгында
Дигән идем...
Ялкыны бар
Төнен янган ак шәмемдә.

* * *

Каеннан өзелә, өзелә –
Өзелә теп-тере яфраклар,

Күкрәктән чыккандай, аһ, антлар,
Күкрәктән чыккандай ак аһлар.

Яфраклар коела, коела –
Коела инешкә, коега.

Антлар да, аһлар да таптала –
Биреләдем мин шундый тойгыга.

Биреләдем мин шундый тойгыга:
Бар нәрсә мәгънәсез тоела.

Ак каен сыена җилләргә,
Ә җилләр калдыра күлләргә.

* * *

Ах, чаганның
Җилдә җилфер-җилфер
Чуар-чуар чигән күлмәге!
Бөтерелеп җилдә бии чаган,
Ах,челтерәп аның көлгәне!

Күзем кызып карап торган булам,
Биергә юк инде дәрманым.
Тик шулай да кинәт кенә тойдым
Күңелемдә әле дәрт барын.

Күңелләрем кытыкланып китте,
Шәбәйгәндәй булды адымым.
Бу чаганның чегән биюенә
Мин дә биеп киттем – язылдым.

Чаган, чаган,
Иш булырбыз икәү,
Бармы тагын чегән күлмәгең?
Урлап качса мине берәр чегән,
Син гаепле, чаган, димәмен.

* * *

Мин сине урлыймын
Кемнәндер,
Син мине урлыйсың
Төннәндер...

Туктата алмый шул
Мең әмер,
Тыя да алмый шул
Мең әмир,

Туктата алмый шул
Мең вәзир.
Син – патша, мин – патша
Без хәзер...

Әй, язмыш, тотынма
Кылычка!
Бу бәхет болай да
Бик кыска.

* * *

Калын боз каплаган ишегеңнең
Бар икән лә кырык йозагы.
Ачкыч яраталмыйм,
Ишегеңне
Какмыйм әле...
Имеш, чыдамлы!

Мине адаштырган сукыр буран
Өтә генә минем өзәккә.
Бизгәк тота мине – беркеп туңдым
Бусагаңдагы һәр бизәккә.

Көткән кунак түгелмен мин бүген,
Теле тилчәле бер теләнче.
Югалырга кирәк миңа тизрәк,
Кеше күреп, кеше көлгәнче.

Туңган кулларымны алга сузып,

Көтәм җылы бер сөз – бер хәер...
Җанкисәгең идем кичә генә,
Йортсыз бер хәерче мин хәзер.

* * *

Тәрәзләрдән коккә карап ятам,
Хастаханәдә шул мин һаман.
Әллә кайдан көзне алып килгән
Кара болытларга көз салам.

Уем-уем көк тә, көзге көн дә –
Тәрәз уемыннан.
Кирәк шәм!
Мин яшәрмен әле әллә көпме,
Бу дөньяга әгәр кирәксәм.

Ә кешегә ярый алмый кояш,
Ай да ярый алмый еш кына.
Бер-берсенә ярый алмаганга,
Кешеләр дә шулай еш сына.

Мин яңадан аягыма бассам,
Булмасам да инде өр-яңа,
Башка күзләр белән карар идем
Зәңгәр күккә, якты дөньяга.

* * *

Өзгәләнмә, күңел, өзгәләнмә,
Иртәгә бит дөнья бетмәгән.
Үз хәлеңне тик үзеңнән сораш,
Сорашма син аны бөтәннән.

Көн йөзендә түгел мин әлегә,
Җир астында, әллә көктәме?
Алдат, күңел, алдат үз-үзеңне,
Ымсынырга сәбәп беткәнме?

Өзгәләнмә, күңел, өзгәләнмә,
Күктә булсаң әгәр – җәй канат,
Җир астында булсаң – тамыр җибәр,
Кояш нурын үзең эзләп тап!

Яшәү белән яшьтәш сабыр акыл
Гел озата килә үткәннән.
Сабыр булчы, күңел, сабырлар ит,
Иртәгә бит дөнья бетмәгән.

Көтмә миннән, көтмә тәүге сүзне,
Язмышларның башы – тәүге сүз.
Чыгып кына барган йөрәгемне
Учларыма кысам: «Зинһар, түз!»

Юлым сиңа илтеп куймасын дип,
Ябып куям ачык капканы.
Тик күрмичә калып буламыни

Баш очында кояш калыкканны?!

Сагыш сиңа илтеп куймасын дип,
Өз-өземә корам капкынны.
Тик күрмичә калып буламыни
Саргаеплар кояш батканны?!

Әйтмим ләкин сиңа тәүге сүзне,
Килгәндә дә хәлем-көчемнән.
Аны син әйт, бер азамат булсаң,
Дөнья бетәр, бәлки, өч көннән...

* * *

Ишегеңнән йөгереп чыгып киттем,
Шап яптым да калын ишегең.
Шартлаганда минем йөрәккәем,
Алтын сарайларың ишелсен.

Бөтен дөньяң җимерелеп төшсен –
Ярылганда сөйгән йөрәгем.
Артларыма борылмыйча киттем:
Калмаган шул инде кирәгем,
Ки-рә-гем!

Дөньяларың һаман балкып тора,
Шартласа да минем йөрәгем...
Мин хәрабә арасында ятам,
Башларымны ташка бәрәмен!

Тау-тау хәрабәләр арасында
Газап, әрнеш – барсы буталган.
«Мин яратам сине, бик яратам!» –
Шушы уйдан гына ут алам.

* * *

Ташка бәргәләнде башкайларым,
Мөкләнгән таш – бетмәс ваклыгың.
Күз яшьләрем ташны тишкәндә дә,
Хаклык түгел сиңа хаклыгым.

Сабыр төбе – сары алтын, диеп
Саклап калдым күңел аклыгын.
Акылымнан яза язганда да,
Коткарды бит мине акылым!

* * *

Көтәм әле.
Суык.
Өшетә.
Көн үтмәгән – бары төшлектә,
Дип алдыймын мин үз-үземне,
Күзгеләрдән алмый күземне.

Тәрәзәгә бәрә ядрә кар,
Яктылык бар, ярый тәрәз бар...

Бөген көз шул, җәй ул кичәге,
Телефон да бер таш кисәге.

Бу минутта син кем кияве,
Ә мин менә тәмуг кисәве
Дигән кешем кала тик көлгә,
Гөл кирәкми инде көңелгә.

Каргамыймын – кояш төшлектә,
Ни кылырмын әгәр кич җитсә,
Көтеп-көтеп бетсә түземлек,
Соңгы яфрак төшсә өзелеп?!

## Лачын исемле эткә

Исемнәрең синең бигрәк матур,
Кайдан тапканнар бу исемне?!
Ураласың аяк асларында,
Аерырлык төгел төсеңне.

Көлләвекне диңгез диеп атау
Белән бер бит синең исемең.
Җисемеңне, бәлки, белер идем,
Көчен тойсам әгәр тешеңнең.

Тешләреңне көптән койганнардыр,
Кайдан синдә шундый бахырлык?!
Тотып алып сатсалар да сине,
Дәрманың юк кире кайтырлык.

Чын лачыннар бетеп барган чакта,
Ишәя шул синең ишеләр.
Исемеңне әйтеп туеп булмый,
Муйнак булып йөри тешлеләр...

## Аяк тавышларың тупсада...

Аяк тавышларың тупсада,
Йөрәккәем кинәт туктала.

Кем икән ул ишек төбендә,
Нинди хәбәр икән телендә?

Җил йоклаган тымык иртәдә
Кем ашыга миңа, өртәлә?

Кем дигәнем – көннең өзедер,
Көн дигәнем – бәндә өзедер.

...Бездән туйган – кояш йончыган,
Ул кайдадыр тамды чык булып.

Иркен сулыш алды дөньялар,
Кош җылысын тойды оялар.

Мин дә тойдым өйнең бар котын,
Гомер калган сыман бер тотам...

Аяк тавышлары тупсада,
Йөрәккәем кинәт туктала.

Җир, күк изрәп калган тын кичтә
Тәрәзәмне минем кем чиртә?

Кем дигәнем – төннең үзедер,
Төн дигәнем – бәндә үзедер.

* * *

Кыска бер мәл – күкрәп яшен яшьнәүләре,
Кыска бер мәл – аңкып җиләк пешкән вакыт.
Җәй үзе бит, күреп сине туймаганга,
Елый төсле, тезләреңә синең ятып.

Еламыйм мин – үткән инде елар чагым,
Туймасам да сине мин дә, дустым, күреп.
Учлап-учлап эчерәмен мин чишмә суын,
Учлап-учлап җиләк кенә бирәм тиреп*.

Хәтерләрсең – хатирәләр калдыралсам
Җаннарыңа үтә авыр вакытларда.
Эзләрсең син, бәлки, минем җиләкләрне
Кыш йөзендә кара кардан, ап-ак кардан...

* * *

Зәңгәр дулкыннарын салмак кага –
Тынычланган диңгез беразга.
Яр буйлары, әй, чем-кара дулкын,
Игенчеләр яра буразна.

Буразнага төшкән алтын бөртек –
Җирнең җаны бит ул, җир коты.
Ябырылды җиргә кара афәт –
Каргаларның авыр болыты.

Акны каралардан аерам, дип
Әйтә алмыйм инде хәзер мин.
Җырдан җиргә төшкән акчарлаклар
Карга белән чүпли әзер җим.

## Кайт, туганым!

*Исламморат истәлегенә*

Сабый чакка кайта хатирәләр,
Игезәктәй үстек, туганым.
Кочаклашып икәү йоклар идек,
Булмады бит үшеп-туңганым.

Син уйнарга чыгып китәсең дә
Кайтмый йөдәтәсең ашарга.
Ә мин сине эзләп чыгып китәм,
Сөрлегәмен кайчак ташларга.

Кайчагында эткә юлыгамын,
Үзем һаман сиңа кычкырам:
«Кайт, туганым, өйдә аш суына!» –
Яңгыраплар китә кич урам...

Кабереӊ дә җиргә тигезләнгән,
Үсә анда кылган, актамыр.
Син юклыкка күңел һич тә күнми,

Туфрагыңны булам актарыр.

Кайт, туганым, син кичер дә мине,
Саклап кына кала алмадым.
Сиңа калкан булып яшәр идем
Насыйп гомеремнең калганын.

Без өстерер идек бала-чага,
Ашап кына тик бер табактан.
Чөйдә калган көлмәгеңне генә
Юып куйган булам кабаттан.

Җәйге тынлык, кышкы буранда да
Сине тапмак булып кычкырам:
«Кайт, туганым, өйдә аш суына!» –
Җавап бирми миңа буш урам.

* * *

Ай нурында атлар сынлана...
Каен арасында көмеш моң,
Кыңгыраулар куя көлешеп,
Ай нурында атлар сынлана.

Арыганнар атлар көнозын,
Җәйге көннең алтын сәгате
Бик кадерле булу сәбәпле,
Арыганнар атлар көнозын.

Көмеш моңнар китә еракка,
Тып-тын гына урман эчләре,
Татлы гына аның төшләре,
Көмеш моңнар китә еракка.

Таң эченә кереп югалыр
Кыңгыраулы гына бу атлар.
Уянырлар шулчак ир-атлар...
Таң эчендә атлар югалыр.

* * *

Кара урман арасында
Кабыгын салган елан.
Иске кабык иске инде –
Искедән елан туйган.

Теләгән килә алдыңа –
Иске кабык суелган.
Суелганын суелган да,
Барыбер шул ук елан.

Өзгәргәндер димә холкы, –
Каршыңа килеп чыкса,
Котылырмын дип уйлама,
Өтергәнче бер чакса...

Битлек алыштырган кеше
Бер елмая, бер көлә:
Эчләрендә кара елан
Сыгыла да бөгелә.

## Аккош биюе

Мине саклый бер төш сабый чактан:
Балет сәхнәсендә биимен.
Балет, димен, бәхет сәхнәседер,
Ак ефәктән генә киемем.

Сәхнә, дисәм...
Көктә аккошларның
Күтәрешәм икән биюен;
Җаным оча, тойгач канатларның
Канатыма назлап тиюен.

Сулышыбыз кебек и җиңел без,
Тирбәләбез кояш тирәли.
Тыны дулкын-дулкын бәрелә бит:
Диңгез котырына, җир әйди.

Диңгез, дисәм...
Бу бит кешеләрнең
Карашлары, безгә алкышы.
Бәхетсезлеген дә бәхет итеп
Ярата бит алар аккошның.

Сабый чактан саклый изге бер төш!
Сызлаганда соңгы тере теш,
Күрдем әле аны бүген төнлә.
Кычкырмады беркем:
«Җиргә төш!»

## Сагыш

Бу мәңгелек мәхәббәтнең
Миңа газаплары таныш.
Күз яшендә агып китте сөю,
Калды бары сагыш.

Мәңгелек бит дидем нәфрәтне дә,
Җан айкагыч каргыш.
Сүзләр белән җилгә очты нәфрәт,
Калды бары сагыш.

Үз-үземне җиңдем мәхәббәттә,
Җанда – бәйрәм, алкыш.
Җырларымда күккә очты җиңү,
Миндә калды сагыш.
Бөтен дөньям – сагыш,
сагыш,
сагыш.

* * *

Яшәү белән мин үлемнең
Арасында –
Кояш сүнеп бара, диләр
Карашымда.

Җир белән мин төпсез күкнең
Арасында –
Күктә очыр, төшер Җирнең
Арбасына!

Юкка гына, юкка сиңа
Мин ялварам:
Син бит өзең – өтергеч бер
Йөрәк ярам!

* * *

Онытасың бергә кичкән ут-суларны,
Онытасың бергә өткән минутларны.
Онытасың сөзләремне – гөл орлыгын,
Онытасың күзләремне – сагыш нурын.

Онытасың, җил искәнен оныткандай,
Онытасың, су эчкәнен оныткандай,
Онытасың, сырхавыңны оныткандай,
Онытасың, җир-суыңны оныткандай.

Әйләнгәнмен, күрәсең лә, искән җилгә,
Әйләнгәнмен, күрәсең лә, су-һавага.
Әйләнгәнмен, күрәсең лә, сырхавыңа,
Әйләнгәнмен көнегелгән бер дәвага.

Гадәтигә әйләнгәнмен, кадимгегә.
Онытасың дип әрнүем хәзер нигә?
Тынгы бирми җаннарыма горурлыгым,
Өлде җаным, калды бары горур сыным.

* * *

Караңгы төн йота буй-сыныңны,
Сузылып бит кала кулларым, –
Хәтерләтеп өксеүеннән тынган
Скрипканың өзек кылларын.

Тыным белән тартып алыр идем,
Җырларга да җитми тыннарым.
Бер әйләнеп кенә кара, җаным,
Сузылып бит кала кулларым.

Хатирәмне җырга әйләндерсен
Минсез яшәячәк елларың.
Әйталмадым әйтер сөзләремне,
Сузылып бит кала кулларым.

Сөюдән дә кадерлерәкмени
Миннән алып киткән юлларың?
Ни гаебем синең алларыңда?
Сузылып бит кала кулларым...

## Чаукалык

Миннән соң да алар яшәр диеп,
Бүләк итәм сиңа чаукалык.
Ак каеннар җырлар җырларымны,

Җилгә, давылларга чайкалып.

Серләремне чиштем каеннарга,
Кыймаганга сиңа әйтергә.
Мине онытсаң да өпкәләмәм,
Каеннарны гына хәтерлә.

Ак каеннар гына яши белә
Аклыкларын саклап, саф калып.
Сиңа әйтелмәгән сөюемне
Күкрәгендә саклар чаукалык.

* * *

Мин юк синең өчен...
Бу дөньяда
Мин яшимен артык баш кебек.
Әйтелмәгән сөю сүзләрем бит
Муеныма аскан таш кебек.

Сиңа сайлап әйткән сөю сүзем
Муенымда булыр гәрәбә.
Йөзләремә аның нуры төшәр,
Йөрәгемә төшәр – тирәнгә.

Шул сүзләрне сиңа әйталмыйча
Узып бара инде елларым.
Батып барам...
Муендагы ташка
Көче җитми минем кулларның.

* * *

Көкне болыт басты.
Биек күнем
Түбәнәеп калды әйтерсең.
Әле генә алтын ява иде,
Минем кебек, күз, син сәерсең.

Күкне баскан болыт өемнәре
Кояштан бит барыбер түбәндә.
Болыт аша аны күреп була,
Шул күкләргә түбәң тигәндә.

Алтыныңны үзең каралтасың,
Әй юләр күз – кәеф кешесе.
Алтынны тик алтын итеп тота
Кешеләрнең бары көчлесе.

* * *

Күкрәгеңә тамды күз яшьләрем,
Нигә шулай кинәт дертләдең?
Яндырамы әллә күз яшьләрем,
Калкан кебек юкса күкрәгең.

Хушлашабыз.
Миннән тартып ала –
Кара елан кебек юл яман.

Кунак кына булдың көңелемдә,
Икмәк-тозым салам, юламан.

Мин – тукталыш кына тормышыңда,
Куркытканда яңгыр, ут-яшен.
Ә шулай да утлы килеш сакла
Күкрәгеңә тамган күз яшем.

* * *

Ниләр эшләтим соң җан ярасын?
Кысып түзәм дә бит тешемне,
Онытылырга ул ирек бирми,
Сарыф кына итәм көчемне.

Мин, тыймакчы булып, кабаланып,
Җилегемә үткән яраны
Бер чабуда үзәм, өрсәләнеп,
Үткәннәрем белән араны.

Ә ул һаман сыкрап туктамагач,
Нишләргә дә белми тоз салам.
Дәрьяларга чумам, тотынырга
Булмаса да анда бер салам.

Үз җанымны үзем имлимен мин
Ай алдында, кояш алдында.
Акылымнан язмыйм әле, Тәңрем,
Мин аңымда әле, аңымда.

* * *

Алтын сәгать таккан таныш.
Юк, сорашмыйм мин хакын.
Сорар идем дә хакларын,
Үзе булса мең алтын.

Икенчесе колагында –
Затлы көмеш алкалар.
Хакын миңа әйтеп тормас,
Ул – атаклы малтабар.

Ис тә китми.
Телем әйтә
Күргәннәрне күз генәм.
Алтын булыр, көмеш булыр,
Булса да ул сүз генәм.

Бәясе соң бармы сүзнең?
Дөньялар шау буталчык.
Алтын, көмеш дигәнең дә
Уала шул – шыр балчык.

Комсыз күздән саклый җирем
Миңа дигән өлешне:
Куенына яшергән ул
Иң саф алтын, көмешне.

Насыйп булса, кулга керер,
Нәкъ мин булсам иясе.
Манчылмаган, шөкер, канга
Һәм юмаган күз яше.

## Томана

Коттедж дигән бик тәкәббер өйләр
Караш ташлый миңа һавалы.
Чит ил гражданы кебек алар,
Тормышларын беләм чамалы.

Исемнәре ят шул, җисемнәре
Бер баскынчы кебек, уйласаң.
Тамашалар кылып чыгар идем,
Таныш та юк анда, ичмасам...

Минем йортның тирә-ягы ачык,
Бер сандугач кына оясы.
Яңгыр өтсә өтә,
Беркемгә дә
Тик капланмый аның кояшы.

Хуҗасына охшап,
Котлы өем
Тернәкләнеп җиргә сырышкан.
Чәчәкләрем әнә нур көлтәсе –
Канәгатьләр минем тормыштан.

Ә коттеджлар, тәре явы кебек,
Басып килә иген басуын.
Иген басуларын җәлли-җәлли,
Капитализм дигән корылышка
Томанадай аяк басуым.

## Сиңа гына атап җыр чыгардым

Сиңа гына атап җыр чыгардым.
Кабул итмәгәнгә йөрәгең,
Моңнарымны аңлар җилләр белән
Дала киңлегенә җибәрдем.

Ак кылганнар, скрипка кебек,
Моңнарымны сызсын – еласын
Көне-төне.
Сыктар һәрбер өне,
Дала көткән сыман Илаһын!

Елап туйгач,
Моңым искән җилдәй
Далаларның иңләр киңлеген,
Җанындагы утка чыдый алмый...
Дөрләп янар бергә көңелем.

Койма яңгыр булып,
Кинәт кенә
Өзен-өзе, бәлки, сөндерер.
Далаларга сеңеп һәр тамчысы,
Миннән җиргә сәлам көндерер.

Моңнарымны, җаным, ишетмәссең,
Моңнарымны, җаным, күрмәссең.
Хәтереңдә генә җырым булып
Яшьнәп-көкрәп куяр яшен-ут.

## Кое

Мин бәләкәй чакта кызык иде:
Тик бер кое олы авылга.
Чират торсак та без эчәр суга,
Алмый идек һич тә авырга.

Халык шунда җыелышыр иде –
Мәктәп ихатасы туп-тулы.
Мәктәп юлы белем юлы иде,
Мәктәп юлы – эчәр су юлы.

Бозлар ката кое чиләгенә,
Ай-һай тирән иде коебыз.
Судан бигрәк олыларның сөзен
Тыңлау иде бөтен уебыз.

Белә идек авыл хәбәрләрен
Чират көтеп торган арада.
Кое суы белән шатлык-кайгы
Һәрбер өйгә шундук тарала.

Бер өк шатлык иде җаныбызда,
Тәнебездә бер өк чир-хафа.
Башка кое эзләмәгән картлар,
Эзләр иде – тәмле булмаса...

Җимерелгән имән буралары –
Кое көптән инде ташландык.
Истәлеккә диеп, тирәсеннән
Кызым белән икәү таш алдык.

Һәр кешенең өз коесы хәзер –
Күршегә дә ябык капкасы.
Сулар кушып биргән әйрәннәре
Йөрәгемне басмый – ай, ачы!

## Янгын

Тоташ дала иңләп, янгын килә,
Күккә ашкан кызыл канаты.
Җиргә бәргәләнә, өрсәләнә,
Канатлары аның кат-катлы.

Ялмап килә янгын бар дөньяны,
Шәүләләре аның кап-кара.
Җәнлекләрне – җәнлек,
Кошларны кош
Өз артыннан әйдәп коткара.

Шуыша да янгын тагын оча,
Кылганнардан күчә кылганга.
Минутлар ут инде минутларга,
Дөнья ут эчендә калганга.

Гайрәтләнгән янгын каршысында
Күбәләк ни, мин ни; без – мәхлук.
Аяк асларында җир убыла,
Яшен яшьнәгәндәй шартлый күк.

Күпә-көндезен дә ялгышудан
Акылымнан яздым, тавыштан:
Һомай кош дип уйладым мин утны

Тәөдә күргән чакта алыстан.

* * *

Җиргә кемнәр
Килгән, өлгән –
Шуны белгән
Өлән, өлән.

Яши-яши
Шуны күрдем:
Өлән, өлән
Тотып тора
Җирнең өзен.

Мин өзем дә –
Әллә чәчәк,
Әллә өлән...
Җирне мин дә
Тотып торам,
Тотып торам –
Шундый көндәм.

Шуңа да мин –
Мәңгелек сер,
Шуңа да бит
Мәңгелек җир!

* * *

Юлыма тоз сипмә, дустым,
Файдасы юк бу эшнең.
Дөнья – бозлы мәгарәдер...
Шул уй белән килештем.

Юлыма гөл сипмә, дустым,
Таптар аны көнчелләр.
Миңа язганын танырмын –
Өссен гөлләр, көлсеннәр.

Юлга чыгам – көл сибәргә
Уйласа берәр мәкер,
Әй дускаем, тый син аны,
Кулларыннан эләктер!

* * *

Таң – тантана гына,
Нуры белән
Мәдхия-җыр яза өзенә.
Таңны каршылауның куанычы
Гөл күзендә, кеше күзендә.

Таңны каршылауның куанычы
Сандугачның гына телендә.
Төзми җыр башлыйлар башка кошлар
Әле монда, әле тегендә.

Таңгы мәдхиягә кушылам да

Сизми калам кояш баюын.
Дөнья куган чакта,
Төнем, аяп,
Тотып кала итәк чабуын.

Тантана да, бераз сагыш та бар
Төн алдыннан яткан силлектә.
Уйларымны тарта моңсу шәфәкъ,
Сөнә-сөнә алыс киңлектә.

Ак шәм яндырмыйча торам өзем,
Иртәрәк дип әле ахшамга.
Сандугачлы төнне тик ай саклар,
Мин асманга төштә ашканда.

## Туганлык

Төшемә дә керми сөйгәннәрем,
Өзем өчен генә чибәрмен.
Кояш эзләп тапмас карурманда
Ялгызлыктан рәхәт чигәмен.

Саклый микән газиз әрвахларым:
Әтиемме, әллә әнием?
Ялгызлыкны тоймый,
Әйтерсең лә
Туганнарым белән яшимен.

Шушы имән, карагайлар белән
Бармы икән әллә туганлык?
Ырыс – җәйләр, кырыс бездә кышлар,
Тамырларыбыз да шуңа нык.

Минем язмышымны кабатлыймы,
Шарлама да таштан ташлана.
Ахирәтләр генә булышырбыз,
Син, шарлама, мине ташлама!

Бөек канбабалар – йолдызлыклар
Саклыйлардыр мине көкләрдән.
Бу ышаныч кайдан килә миңа,
Икмәк калганда да төтәрәм.

Кояш эзләп тапмас карурманда
Шундый рәхәт миңа.
Тын көнем.
Як-ягыма көз тутырып багам:
Ул – абыем минем, ул – энем.

* * *

Ачуың булды ишекне –
Ачылды иске ярам:
Роза чәчәген эзләдем
Ак кардан, кара кардан.

Эзләдем гомер буена,
Белсәм дә мин булмасын,
Ни уй төшкәндер башыма:
Эзләдем җир туңгачтын.

Ачуың булды ишекне:

Роза – кулыңда!
Бәйрәм!
Розалар яра төсендә,
Ачылды тагын ярам.

## Ком сәгате

Ком сәгате куеп алларыма,
Дәва бир, шәфкать туташы...
Сәхәрләрдән уем юл алды да
Сахарага барып тоташты.

Чөллекләргә сеңгән вакыт өзе,
Океаннар сеңгән, мең кавем.
Бушлыкларга патша булып ята
Пирамидасында фиргавен.

Уем кайта туган җирләремә:
Тик бер күрер өчен яшәрлек.
Менә шушы ком сәгатеннән дә
Вакыт ага кебек яшәреп.

* * *

Кысрыклый тормыш!
Әйтерсең
Миңа чыкканнар сунар.
Адашуым табигыйдер,
Көннең күзе дә сыңар.

Көннең күзе – ялгыз кояш,
Булса да күңел күзем.
Оятсыз бу дөньяларны
Нишләтим мин берүзем?!

Нигә гарьләнәм соң әле
Намуссыз берәү өчен?
Кояш та күреп бетерми
Берьюлы җирнең өстен.

Мин түгел галәмнең күзе,
Намусның да бизмәне.
Шөкер итәм:
Ни кылсам да,
Кояш миннән бизмәде!

## Тигәнәк

Карурманда түгел адашырлык,
Адашырлык түгел тауларда.
Хәлдән таеп егылсаң да җиргә,
Яраланган кебек яуларда.

Кышлауларга, җәйләүләргә илтер
Аягыңнан тартып тигәнәк.
Кеше эзен саклый тигәнәкләр,
Үсә учакларны тирәләп.

Алабута дөрес юл күрсәтер:
Нигезләр соң нигә ташландык?
Шулардан да фәһем-гыйбрәт алып,
Яңа тормышыңны башларлык.

Адаштым дип кайгырырлык түгел,
Дөньялар бит, әйе, куласа.
Юлны баскан алабута хәтта,
Тигәнәк тә хәтта юл ача.

## Тигезләмә

Математик мәсьәләләр гади
Тигезләмәләргә корылган.
Тигезләргә кирәк бары уйлап,
Шулай килә, диләр, борыннан.

Мин аларны уйнап чишә идем,
Бала идем – ихлас, беркатлы...
Уйландырмый иде кеше җаны,
Уйландырмый иде ир, хатын...

Җир шарына бәрелә минем маңгай,
Ярылыр ул, беләм, аңлыймын.
Яшәү белән үлем – тигезләмә,
Тик тигезли генә алмыймын.

## Кардиоүзәк

Йөрәк шартлавыннан җир тетрәми,
Чайкалдырып кардиоүзәкне...
Үзәк өзелгәндә,
Тәрәз аша
Дөнья хәлен күзем күзәтте.

Кардиоүзәк.
Кала тулы бизәк:
Мең-мең тәрәзләрдә ут балкый.
Ымсындыра җанны, ашкындыра,
Йөрәксетә мине – ут бакый.

Бөтән мәртәбәләр кирәк түгел,
Йөрәк типсә, үзе мәртәбә!
Дөнья малы артларыннан куу –
Көн итүләр, китеп мәртләргә…

Күз иярми:
Җилә машиналар,
Дөньямны куып җитмәкче?
Менә мин дә яңа аңлап торам:
Язмышыңа йөрәк – җитәкче!

Тормыш үзе миңа күз кысkandай:
Неон уйный җәйгор төсендә.
Кардиоүзәк,
Авызың бер пешкәчтен,
Өреп кап, дип искә төшерә!

Йөрәк шартлавыннан җир тетрәми! –
Шаккатырган мине шул гына.
Дөньяларга менә тәрәз аша
Карап торам шуңа шым гына.

* * *

Мин арыдым, Раббым, заманымнан,
Утлы куласамы дөньясы?
Ялкыннары җанны ялмап ала,
Тыннарымны кыса колачы!..

Теләгәнен бирче, әй Ходаем:
Патшасына – тыныч тәхетне,
Йорт-җирсезгә – җылы гына почмак,
Баласызга – сабый... тәүфыйклы!

Җиргә тапталганга – пар канатлар,
Каһарманлык – рухы сынганга.
Мин мохтаҗмын бары бәхетлегә –
Аркадашка яки туганга;

Мин мохтаҗмын көңеле бөтеннәргә –
Шулар булса икән юлдашым!
Юк, мин көчле түгел, көкләрне дә,
Юк, күтәреп тормый иңбашым.

Мин арыдым.
Дөнья,
Буш карының,
Күрмәгәнем җирдә калмады.
Җаннарымны бүлеп бирсәм дә бит,
Бишкә бүлгән кебек алманы.

* * *

Сафтыр диеп, дәрьяларга төштем,
Җаным-тәнем, әйдә, тазарсын.
Кыя ише идем мин кайчандыр,
Таныйлармы хәзер тауларым?

Урманнарга кердем,
Күкрәгемне
Саф һавалар гына киңәйтер.
Яшь каендай идем мин кайчандыр,
Каеным, дип, хәзер кем әйтер?

Шөлгәнташка кердем,
Җанчишмәнең
Калмаганмы диеп тамчысы.
Телләремдә бал да майдыр иде,
Нигә хәзер тозның ачысы?

Китапларга чумдым хаклык эзләп, –
Гасыр тузаннары китапта.
Син – хаклык, дип миңа әйтерләрме,
Уйланамын хәзер шул хакта,
Уйланамын хәзер шул хакта.

## Шайтан таягы

Кемнәр кем булган,
Әрекмәннәр гөл булган.

*Әйтем*

Шайтан таягына мода, диләр:
Өстерәләр икән бакчада.
Гәзит хәбәр итә, яңалыкны
Йоктырмакчы булып башкага.

Чыдамлы ул, чыгым кирәк түгел,
Матуры ул, имеш, чәчкәнең.
Ә мин роза утырткан идем бит,
Кара суыкта да өскәнен.

Ә мин һаман ышанамын әле:
«Кеше, – диеп, – җирнең кунагы.
Хушландырсын, – диеп, – дөньяларын
Хушбуй исе, роза куагы».

Шайтан арасында котырынып
Чәчкә ата шайтан таягы.
Тик мин көптән беләм бу дөньяның
Кыйбла икәнлеген кай ягы.

## Актриса язмышы

Илбаш аңа олуг исем биреп,
«Халык даны» диеп котлады.
Аракыны аркадашы иткән
Ире кимсенүдән тукмады.

Сәхнәсендә – горур Илаһия,
Патшабикә – алтын сарайда.
Куыш өенә ул кайтып керсә,
Сулыш туктый, күкрәк тарая.

Күгәргән йөз, шешенгән күз тагын –
Иртән-иртүк битен буяды:
Елмаерга тиеш ул сәхнәдән,
Матурларга тиеш дөньяны!

Тиеш, тиеш,
Илаһия, имеш! –
Үз-үзенә куйган таләбе.
Ялангач кул белән тота һаман
Дөнья – утлы гына табаны.

Җаны пешә! –
Таба төшә-төшә...
Ычкындырмый ләкин табаны,
Яратканын күреп кешеләрнең,
Сәхнәләрне тоеп табаны...

Ни булды соң бүген сәхнәсендә:
Башын төйгән кебек алкаш!
Ай!

Өксеп елый...
«Бик шәп уйный!» – диеп,
Тамашачы торып алкышлый.

## Алма елы

Кемгә ничек?
Берәөләргә быел,
Бәлки, Маймыл елы булгандыр.
Сабак бирә тормыш:
Кайсы кеше
Маймыл булыр өчен тугандыр.

Кемгә ничек?
Быел алма елы
Булды миңа.
Алма уңышы –
Кунак сые җитәр яренгәчә,
Ә кыш озын өткен кылычлы.

Урманнарны кырып салган чакта,
Кылыч тия минем тәнемә.
Кырыс кышлар өйрәнгәнме инде
Алма исе, алма тәменә?!

Билләремне буып куйыйм да мин,
Утыртыйм бер ябь-яшь алмагач:
Алмагачлар тагын чәчәк атар,
Көңелемне минем аңлагач.

Кышка төяп алып китеп барыш
Җәй җылысын, җәйнең чуагын.
Алма елы,
Олыладың мине:
Бөтен галәм – минем кунагым!

* * *

Нигә өзгәләнәм?!
Ә бит белә
Барысы да аның кемлеген.
Җирем көчәреннән ычкынгандай,
Өзелгәндә дуслык кендегем.

Мин дә белә идем кемлекләрен,
Баскыч идем – күккә өрләде,
Күпер идем – дәрья котырганда,
Су басканда якын-тирәне.

Сузса икән миңа изге бер җан
Касәләрдә суның кәөсәрен.
Авыр миңа,
Тотып торган кебек
Япа-ялгыз
Җирнең көчәрен.

## Кеше – сер

Эндәшәмен сезгә кайта-кайта:
Һавам, суым, янә ут, җирем!
Кайтарыгыз, зинһар, асылыма:

Кеше бит мин, димәк, мин – сермен!

Илаһи бер сер итеп тә күрми,
Чирле итә мине шәһәрем.
Ташлап качсам аны бөтенләйгә,
Озын булыр гомер сәфәрем!

Әй шәһәрем, җанны кыйный-кыйный
Ашатасың миңа калачың...
Килә минем кеше күңелендә
Сер һәм хыял булып каласым.

## Цунами

*«Фәйләсүф» шагыйрьгә*

Суның җирдә формуласын
Ачканнар күптән.
Шулкадәр дә күп ачканнар –
Чиста су беткән.

Судан куа кешеләрне,
Ярсып, цунами:
Су кайный ялкын-ут булып,
Бетеп чыдамы.

Цунаминың гайрәтендә
Кипкән инешнең
Чебек үнен бөген төштә
Мин дә ишеттем.

Күңелемнең формуласын
Табалсаң, табыш...
Цунамида ялкынлана
Минем дә сагыш.

## Җир әйләнә...

Әй Ходаем!
Бирче сабырлыклар,
Җир шарында ялгыз басып торам.
Җир әйләнә...
Үксез ялгызлыгым –
Бар галәмгә гүя сүзсез оран,
Җир шарында ялгыз басып торам.

Чөлләр кайный барханнары белән,
Актарыла әнә диңгезләре.
Җир шарында ялгыз басып торам,
Җил-давыллар исә гел тискәре.

Җәһәннәмгә җанны түңкәрерләр...

Көч бир, Ходай!
Көч бир
Йөрәгемә –
Шушы газапларны үткәрерлек.
Җир үзәге – Урал искә төшкәч,
Күңелләрем китте күтәрелеп,
Очмас җаным, очмас түңкәрелеп.

Кешеләргә ышанычың бетсә,
Җирнең тарту көче ниләр генә?
Кайгысы юк миндә Җир шарының,
Өз тизлеген белеп җилә генә –
Каршы килеп кара теләгенә?!

* * *

Өз вакыты җитми, кояш чыкмый,
Өйрән инде, көңел, сабырлыкка.
Игенче дә иген урмый әле,
Чалгы яный әнә чабынлыкта.

Өз вакыты җитми, ай калыкмый,
Нигә минем ярсып ашкынуым?
Көтәргә бит кирәк төзем генә
Бодайларның тоташ баш кысуын.

Дулкынлана басу җил-давылда,
Яңгырларда бии, әй бөгелә.
Биесә дә, бары өмет кенә,
Алтын иген төгел ул бөгенгә.

Ач тордың ни, тук тордың ни – һич тә
Өз вакыты җитми, пешми иген.
Басуыңны көз карасы кебек кара,
Йөрәгеңне басам дисәң бөген.

## Дөнья – хәрәкәттә!

Сине зур дип мин бик алданганмын –
Көңелем кайтты:
Бәләкәйсең икән!
Дәвалар юк синең авыруга:
Интегәсең икейөзлелектән.

Көңелем кайтты синнән...
Әйтерсең ул –
Әсирлектән котылган бер качак.
Азатлык та аңа җиңел төгел,
Көңелләрем кайтты, кайтты аксап.

Яши бирсен әйдә ике йөзең,
Бер-берсеннән булып матуррак.
Урам аша гына яшәсәң дә,
Көңелләрем синнән, шөкер, ерак!

Җавап көннәрендә кайсы йөзең
Җавап тотар икән ахирәттә?
Теге дөньяларга кәнәфидә
Китеп булмый...
Дөнья – хәрәкәттә.

Мин гөлләмә сиптем киткән чакта:
Якты көнең булсын бәрәкәттә.
Җәрәхәтле көңел канат кагар,
Дөнья бит ул һаман хәрәкәттә.

## Кендек

*(Кояш-ана)*

Барган саен офык ерагая,
Дөнья карыннары шундый иркен!
Әнкәм минем, кендегемне кисеп,
Тоташтырган гөя нурга беркөн.

Нур-кендеккә тоташтырган гөя,
Зиһенемә теләп яктылыклар.
Язмышлары якты булсын диеп,
Яктылыктан туа яхшылыклар...

Янсам янам көлгә калдырганчы
Үземнең дә җанны, башканы да.
Шундый кайнар минем күз яшьләрем,
Тишеп үтәрлек ул ташларны да.

Ә шулай да якты күк йөзендә
Чырай сытарга мин кыенсынам.
Кулым җитсә, гөлләр чәчәк ата,
Кеше үсә җаным җылысыннан.

Төс ташламый, көч ташламый әле,
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Кояш-ана!
Балаң күреп мине яратканга,
Җаннарымда бөтен галәм яна.

## Култамга

Бу дөньяны акыл, йөрәк тота,
Дәрәҗәләр тотмый дөньяны.

*Нажар Нәҗми*

Әй акыллы сүзләр, Нажар агай,
Яшәү кануны ише генә!
Эчтән, тыштан язып куярлык бит
Олы, кече түрә ишегенә.

Хәлләр ләкин бүген башкачарак,
Дөньяларны тота култамгалар.
Култамганы хәтта медаль итеп
Муеннарга яшьләр еш тагалар.

Күлмәкләргә аны төшерәләр –
Патшаныкы яки «йолдызныкы».
Булса – килешер дә иде, бәлки,
Култамга бит уйнаш бер кызныкы.

Дөньяларны тота култамгалар,
Сәясмәннәр бөтен Җир шарында
Ышаналар бүген кешелекне
Култамгалар гына сакларына...

Менә мин дә торам чират көтеп,
Түгә-түгә күпме йөз суымны,
Бер култамга өчен күнә буе, –
Кызган башым монда тиз суынды.

Шул култамга хәл итәргә тиеш
Минем язмышымны иртәгәсен.
Документ дип аны йөрәгеңнең
Төрләрендә генә йөртәсең.

Мин үзем дә куям култамгалар,
Шигырь язган кебек янып утта,
Нажар агай бик хак әйткән, диеп:
«Бу дөньяны акыл, йөрәк тота!»

## Сандугач ул таңда гына сайрый

Таң канаты белән кагынганда,
Дөнья гел яңадан туган кебек.
Ә сандугач сайрый илһамланып,
Минем тыңлаганны, ахры, белеп.

Дәртләнеп тә китеп кагына ул,
Чык бөртекләрендә юынгачтын,
Кояш нурларында юангачтын,
Мең-мең мәшәкатьтән суынгачтын.

Сандугач ул тик тынлыкта сайрый,
Ишетсен дип аны уйлы кеше.
Кешеләргә никтер тәмлерәк шул
Таң алдыннан гына күргән төше.

Көңелләре тулы моң гынадыр:
Өзгәләнә кошкай, и өзелә.
Ул Ходайның үзен уятадыр,
Сайраса да бары үз-үзенә.

## Сиңа дәшәм, сөеклем!

Өзгәләнәм дөнья дигән
Мин тап-тар бер төрмәдә.
Әллә кайдан, алыслардан
Карашларың төбәлә.

Әллә кайдан, алыслардан
Ишетелә тавышың,
Ул тавышың аңлыймыни
Минем кайгы-сагышым?

Синең кесә телефоның
Инде тагын кесәңдә,
Күрми дә ул, белми дә ул,
Йөрәк шартлап өлсәм дә.

Гомер үтте: «Син, син!» – диеп,
Җавапсыз мәхәббәтем.
Кирәкми дә инде хәзер
Хәерең-мәрхәмәтең.

Сине хәтерләмәс өчен,
Нинди дәва табарга?
Их, миңа да чишмә булып
Җырлый-көлә агарга,

Юк булырга язмышыңнан.
Сине сөюем – газап.
Сусаганда су эчәрсең,
Инешкә ятып азак.

Җаныңдагы ут басылыр,
Күзләрең дә ачылыр.
Шул чишмәдә асылымның
Бер гөнаһсыз башыдыр...
Мин ялгызым бу төрмәдә,
Көкләр бит шуңа баса.
Ни кылырмын – уйларым да
Караңгыда адашса?!

Өмет өздем, дигән идем,
Юк, өзелми өметем.
Өзелмәве сиңа гына
Сизелми ул, егетем.

Ситсы күлмәкле яшь бер кыз
Килеп баскач алдыңа,
Яшьлегеңдә
Син – тәкәббер –
Күз салдың салкын гына.

Син бит миңа җәй көне дә
Карлы буран буласың.
Тәүге һәм соңгы сөюем,
Килми минем туңасым.

Сорашмыйсың хәлләремне
Син бүген дә, сөеклем.
Әйтергә дә куркыныч шул:
Мин бит – тере үлекмен.

Кесәңдәге телефонны
Борчымас ла тавышым.
Исләреңә төшсәм әгәр,
Тыңла чишмә агышын.

## Йокысыз төн

*(Тулган Ай)*

Җанны йолкасың син күкрәгемнән,
Күзгә генә карап, тулган Ай.
Өемдәге тимер балконымнан
Чак торамын менә егылмый.

Әй тулган Ай,
Түпләреннән генә
Кузгатасың, ахры, диңгезне.
Диңгез кебек, җаным актарыла,
Тыныч тоелса да төн йөзе.

Диңгезме соң өзен аяп торыр,
Дулкыннарны йота дулкыннар.
Яшен белән яшен чәкәләшә,
Упкыннарда кайный упкыннар...

Диңгез кайта, ахры, ярын ялап,
Таңнар якынлаша башлагач.
Тынычлана җаным.
Йокымсырый
Елга-көлләр, кырлар, таш-агач.

Дәрьялар да сиңа тартылганда,
Вулкан атылганда көчеңнән,
Әй тулган Ай,
Ниләр таптырасың,
Җанны айкап, чебек кешеңнән?!

* * *

Өч могҗиза мине әсир алды:
Җир,
яңә көк,
яңә хатын кеше.

*Мостай Кәрим*

Гомер елларымның төбәсенә
Менеп баскач, багып тирә-якка,
Эндәштем мин гөя кыялардан:
– Җирем, Һавам, Утым,
Мине сакла!

Эндәштем мин шулай Мәхәббәткә
Яшь чактагы кебек ярсу белән:
– Мәхәббәтем!
Мин бит синсез Утсыз,
Һавасыз да, аерылам Җирдән!

– Бала багасың син:
Яңартасың
Җирне, Көкне, Һава, Утның көчен! –
Шулай диде миңа Мәхәббәтем, –
Изге миңа, Хатын, синең исем!

Дөньяның бит өзен саклап килә
Мәхәббәткә тугрылыгың көче.
Гөнаһларым булса, гафу итче,
Мин баш иям сиңа, Хатын кеше!

* * *

Кендегеңне ачма, кыз бала,
Модаларга алай алданма!

Модалар бит алар бер көнлек,
Кара аңа бары төкереп!

Кендегеңне ачма, кыз бала,
Өзең – бала, өзең өк – Алла!

Тоташкан Җир синең кендеккә,
Тоташкан Ир синең кендеккә;

Хәтта Ай да, хәтта Кояш та
Тоташканнар, өзең тугач та.

Тоташыр аңа бәләкәчең –
Бәхетең һәм синең җан көчең,

Тоташкандай син дә анаңа –
Анаң рухы белән янарга!

Кендегеңне ачма, кыз бала,
Өзең – бала, өзең өк – Алла!

* * *

Яңа гасыр,
Синең капкаларың
Төгел нигә оҗмах капкасы?
Барысы да, их, яңарса икән
Кояш батып, кояш калыкканчы!

Барысы да иске гасырдагы:
Шул ук сугыш, шул ук хакимнәр.
Яңа гасыр,
Капкаларың аша
Киләчәккә өтә катыйльләр.

Өметемне ләкин яңартамын,
Өзгәртәмен кара төсләрен.
Оҗмах, бәлки, теге дөньядадыр,
Тәмуг итмә җирнең өсләрен,
Яңа гасыр!

* * *

Төп-төгәрәк Җир калдырам сезгә,
Чатнамаган Кояш калдырам.
*Мостай Кәрим*

Төп-төгәрәк Җир калдырдың безгә,
Ул һавасы, суы, урманнары!
...Аяклардан ега каршы җилләр,
Адаштыра кара бураннары.

Кыл өстендә чакта ни кылырга,
Утны кулдан ничек төшермәскә?
Кайдан гына эзләп табарга соң,
Мин мохтаҗмын синең бер киңәшкә.

Сине кайдан эзләп табарга соң,
Син калдырган Җир ул гомер сыман:
Юк итәргә саксыз сөз дә җитә,
Бөтен галәм туймый аны сынап.

Көчем калган чакта тамчы яшем,
Тамчы кайнар каным чаклы гына,
Син тапшырган Җирне саклар өчен
Сыенамын синең акылыңа.

Сыенамын янә хәтеремә,
Кот калмады син киткәннән бирле,
Ишетәсеңме мине, Мостай агай!
Тик бер сөзең җитә.
Сөз – гомерле!

## Печән чапканда...

Бир әле, бир, Мансур, чалгыңны,
Шушы алны өзем чыгаем.
Талчыбыктай чактан чабылган,
Онытылмагандыр, мөгаен.

Кияө булып килгәч даладан,
Өйрәттем бит чалгы янарга.
Чалгы тотуыннан егетнең
Кемлекләрен була таныргa.

Нечкә билле, җиңел сөякле
Булмасам да, гөя кавырсын.
Бир әле, бир, Мансур, чалгыңны,
Авыртса ни йөрәк, авыртсын!

Уйларымнан башым язылыр
(Ул еш кына аска иелә...).
Кәләш чакларыма кайтыйм бер
Көйле генә чалгы көенә.

Миңамы соң ханым булулар?!
Җиргә береккән шул көңелем,
Беләм инде, кара эшләрнең
Бер генә дә оят төгелен.

Дусларым да һаман элекке:
Печән чапкан, сыер сауганнар,
Бәхилләшергә дә өлгерми,
Эш өстендә җиргә ауганнар.

Иртә таңнан кара кичкәчә
Мал тапканнар хәләл көч белән.
Кайчакларда салмыш булсалар, –
Нишләргә соң инде? – кичерәм...
Бир әле, бир, Мансур,чалгыңны,
Әзер торсын салкын әйрәнең...
Сандугачлы синең бәйрәмең,
Гөл-чәчкәле минем бәйрәмем.

## Ватаным

Кошлар оча тагын җылы эзләп,
Күрә алырмынмы кайтканын?
Күкрәгеңнән моңнар китмәсен дип,
Сине уйлыймын мин, Ватаным.

Күрә алырмынмы таң атканын,
Карап калам кояш батканын.
Йөзләреңнән нурлар китмәсен дип,
Сине уйлыймын мин, Ватаным.

Хушлашулар сала сагышларга,
Карап туймам сулар акканын.
Җиргенәмнең көче китмәсен дип,
Сине уйлыймын мин, Ватаным.

Күрә алырмынмы яшеннәрнең
Яңа язлар алып кайтканын?
Яшел кыяк яраларга шифа –
Сине уйлыймын мин, Ватаным.

* * *

Халык арасында, угры кебек,

Эзли идем синең карашны.
Һаваларга ашмас һавалану
Дәрәҗәңә иде ярашлы.

Колагыма элеп куя идем
Ишетелеп калган һәр сөзең;
Җиде диңгез аръягында кебек
Кеше арасында син өзең!

Бер кеше юк.
Без икәөбез бөген!
Ләкин гөя кеше арасы.
Аңдыгандай* аңсыз тамашачы,
Капшагандай көнчел карашы.

Күзләр серләштеләр,
Чынаякта
Эрегәнче генә бер шикәр.
Ашыгабыз кеше арасына,
Син – эшмәкәр,
Мин дә – эшмәкәр.

Өкенечләр өкендерер иртән,
Кеше арасында гел мәхшәр.
Оҗмах тәме булып тоелачак
Минем кулдан эчкән чәй, шикәр.

## Ахирәтем Мәрьям апа Гималовага

Син кисәтеп әйткән алтын сөздән
Телне тешләп калдым бер мәлгә.
«Әҗәл турында син көп сөйләмә,
Тел тәкъдиргә, – дидең, – тирбәлә».

Телне тешләдем дә көңелемнән
Кара тәөбә әйттем, ак тәөбә.
Янам диеп утны мин каргамам,
Тел тәкъдиргә, дидең, тирбәлә.

Төкермимен эчкән коема мин,
Тудырган бит – җирне хурламам.
Мин төгел ул туймас комсызлыктан
Өз бәхетен өзе урлаган.

Дошман диеп алмам мин битеннән
Мине кансыраткан кешенең.
Мин сабырмын – алда көн бетмәгән,
Тешем коелса да, тешлемен.

Син бар дөнья мине ярата ул,
Сөйкемлесе итеп тумыштан.
Олы булалмыймын мин икмәктән,
Олы булалмыймын тормыштан.

## Кичә генә...

*Асылгуҗа истәлегенә*

Кичә генә бар да чын иде бит,
Барысы да бөген – истәлек.

Истәлекләр исне алган чакта,
Җил иссә дә китәм сискәнеп.

Кичә генә ут күршеләр идек,
Күршең кемдер теге дөньяда?
Өебездә әле, Асылгуҗа,
Син калдырып киткән ут яна.

Караңгыда аны балкытамын,
Җанны җылытмасмы яктылык?
Өзең исә тупсабызда һаман
Торасыңдыр кебек атлыгып.

Тәмәкеңне көйрәтәсең сыман,
«Чык әле, – дип, – Фокки, бар сөзем».
Сөзебез гел ил хакында иде,
Алдан белеп торам мин өзем...

Таптанасың кебек яхшы аттай,
Сабыр гына торып буламы, –
Ил хакында зурдан сөйләгәндә…
Гомер буе җаның дулады.

Кичә генә бар да чын иде бит,
Барысы да бүген – хатирә.
Әй Ходаем, телем әйләнми бит:
«Үтеп китте», – диеп әйтергә.

## Абдрахман

*(«Абдрахман» җырын тыңлаганда)*

Ахырзаман килеп җиткән кебек,
Абдрахман, җанны өксетәсең.
Әйтерсең лә минем шушы юлдан
Беркайчан да инде юк үтәсем.

Әйтерсең лә шушы кояшка мин
Күз тутырып багам соңгы тапкыр.
Абдрахман, ая минем җанны,
Давыл чакыр миңа, яңгыр чакыр!

Сагышыңны давыл алып очсын –
Калкыналмам юкса бу моң-зардан.
Үз көчемә тагын ышаныйм мин,
Килгәндә дә җиргә ахырзаман.

Бу тормышка тагын ышаныйм мин,
Сатса сатсын инде башны дуслар.
Дуслык барлыгына шикләндермә –
Яман уйдан мине сакла, коткар!

Шушы юллар мине чакыра бит,
Күзем күрә әле кояш нурын.
Абдрахман, җанны өксетәсең,
Әллә чынлап бу ахыргы җырың?

## Соңгы инсан

Бу әсәрне тәмамларга

Калган бер-ике сөйләм.
Көне-төне уйлаганга,
Чыгалмый ятам өйдән.

Башым тубалга әйләнде,
Җитәр, дим, тукта, тукта!
Минем көчем дә калмаган
Куярга соңгы нокта.

Бу әсәр – гөя язмышым,
Язганмын әллә юкка?
Тиз-тиз генә, тиз-тиз генә
Куярга кирәк нокта.

Яңа әсәр башлар идем,
Дөп-дөрес нокта куйсам...
Киңәшләшергә кеше юк,
Мин – гөя соңгы инсан.

* * *

Гасыр уртасында туганмын мин,
Кап уртада.
Язмыш серләре!
Маңгаема алдан язылгандыр:
Әйтерсең мин – Җирнең көчәре!

Мин туганда,
Шушы карт тарихның
Төшеп беткән, ахры, тешләре.
Мәңгелектә аны яшәтергә
Миңа калган барлык эшләре.

Мин туганда,
Сабый киләчәкнең
Чыкмаган да әле тешләре.
Мин өсәм дип,
Гомер буе шулай
Бирәмен мин хәләл көчләрне...

«Җир төгәрәк дөнья булсын диеп
Әйләндерәм Кояш тирәли», –
Һәркем шулай уйламаса әгәр,
Яшәргә дә ул бит өйрәнми.

## Урман

Әй карагай!
Урман патшасы!
Патшалыкта синең ниләр бар?
Көңелемдә минем электән
Хөрмәтеңә моңнар-көйләр бар.

Эзләп киттем сине, карагай,
Бик арыдым эзләп табалмый.
Актарылган төбең-тамырың,
Хәтерләтә урман яу кырын.

Кайда да бер тормыш:

Усаклык
Басып бетергән бит урманны.
Гөя көткән алар кырагай
Карагайны көн-төн кырганны.

Кайда да бер тормыш:
Батырлар
Юк ителә килә борыннан.
Төз курпылар –
Япь-яшь агачлар
Тик кояшка таба борылган…

Әй карагай!
Урман патшасы!
Кыл өстендә икән хәлләрең…
Мин җиткерми кем җиткерсен илгә
Синең аянычлы хәбәрең?!

## Бикле көймә

Минем көймәм ярда бикле тора,
Ачкычлары башка кулларда.
Сугылганда зынҗыр зынҗырларга,
Авыр чыңнар ята комнарга.

Күрмәгәнне күреп калыйм диеп,
Чыгалмадым ерак сәфәргә.
Кечерәеп калган хыялларым
Ак кәгазьгә ятты – дәфтәргә.

Сыгылыплар төшәм көчсезлектән:
Кулымдагы зәңгәр ишкәкләр
Канат түгел.
Инде канат түгел,
Бары көсәк, авыр көсәкләр...

Чүгеп калган юка иңбашыма
Ап-ак тун салганда ак кышым,
Капланыр ул көймә.
Шунда гына
Бирәчәкләр аның ачкычын.

## Ике дустым бозылышканда...

Уң кулым тоткан гөлләрне
Сул кулым тотмасынмы?
Икегез дә бик кадерле –
Дөньяның тоткасымы?

Уң күзем күргән ямьнәрне
Сул күзем күрмәсенме?
Тия күрмәсен сезгә дип,
Тотып калам яшенне.

Күзләремнән икегез дә
Яшьләр булып тамасыз.
Чәчәк сузам – минем өчен
Икегез дә талант сез.

**Ятим дөнья**

Ихатаны баскан кычытканнар,
Утынлыкта чери имәннәр.
Әрсез әрекмәннәр, әрепләшеп,
Тупсага ук барып менгәннәр.

Бикле тәрәзләрне ачам да мин,
Ишекләрнең алам йозагын.
Кеше җаны җылытмаган өйнең
Сөртеп куям салкын тузанын.

Инәемнең төсе бөтен әйбер:
Кояш нуры балкый калакта.
Көнел бушаганчы елыймын бер,
Кеше күрмәгәндә аулакта.
Утырамын күзләремне йомып,
Истәлектә генә кунакта.
Инәемнең хәсрәтле бер җыры
Иңрәп-иңрәп китә колакта:

«Уфаларга барам, дисең,
Барганнарың юкмыни?
Ат күкрәгемә, кызганма,
Наганнарың юкмыни?»

Ил язмышын сыйдырган иде бит
Инәемнең саллы сиксәне.
Ил дигәнең аның җилкәсендә
Дөньяны гел сөтте, сипләде.

Җиңелрәк, бәлки, булгандыр да
Күкрәгенә төбәп атсалар.
Җилекләрен суырганда тормыш,
Суыргандыр җанын патшалар...

Ишек-тәрәзләрне бикләп куям –
Күрмәсеннәр минем эчтәген.
Кая гына карасаң да хәзер –
Инәемнән калган истәлек.

Кулкайларым китә әй калтырап,
Капкаларга салам йозакны.
Ятим дөнья мине каршы алды,
Ятим дөнья мине озатты.

Мин кемгәдер ялварам да кебек:
«Нервыларың ныкмыни?
Ат күкрәгемә, кызганма,
Наганнарың юкмыни?»

* * *

Бөрене соң кем яратсын инде,
Нигә уем бөре хакында?
Балаларын саклап, алдан чаба
Инә бөре – өер башында.

Аталары арттан гына бара,
Бар дөньяга гөя күз-колак...
Капкыннарга алдан барып каба

Инә бөре – монда көп тозак.

Йөрәгенә алдан барып тия
Сунарчының өлем утлары.
Улап ауганда да уйлыйдыр ул:
«Очмасын, – дип, – балам котлары!»

...Президиумда – ирләр, ирләр, ирләр.
Бар да төрә – ваклы-эреле...
Колагыма керми чыгышлары,
Мин уйлыймын инә бөрене.

* * *

Гомер тузды,
Узды, узды инде,
Йотып көз яшен йә тузанын.
Каен төпләреннән чишмә чыга,
Чәйгә генә тотам суларын.

Гомер тузды,
Җилләр кебек узды,
Тартып-йолкып каен тузларын.
Яраларым тиз төзәлер кебек,
Чәйгә тотам чишмә суларын.

Кояш кызды,
Сусаганда миңа
Тормыш сузды нигә тозларын?
Яши-яши сусыннарым бетми –
Чәйгә тотам чишмә суларын.

Зарлануы оят инде миңа,
Ишетмәсен тагын кызларым, –
Каен тузын учта тота алар.
Чәйгә тотам чишмә суларын.

## Тынлык

Ядрә яңгыр
Тәрәзәгә бәрә...
Өйдә тынлык иде хакимем,
Буйсынырга әзер аңа гына
Талган йөрәк, талган акылым.

Шушы хакимлектә җиңел миңа
Карарларны кабул итүе.
Йөрәгемә басмый
Йөрәксезнең
Канга баткан кирза итеге.

Шушы хакимлектә алтынланам
Һәм шушында килә каласым.
Алышларда фида яшьлегем дә,
Тик яуларга килми барасым.

Ядрә яңгыр
Тәрәзәгә бәрә,
Бәрми генә торса ни булган?!

Бәхет хөрмәтенә дип күтәрдем –
Шампан көбекләнгән бокалым да
Төшеп кенә китте кулымнан.

## Миләш пешкән

Соңгы яңгыр тамчылары
Тама миләш мәрҗәненнән.
Елый көкләр бертуктаусыз
Әллә миңа рәнҗеннән.

Чөгә бара иңбашларым –
Тора алмыйм көкне терәп,
Яңгыр тамса да керфеккә,
Чыгымчылап чыга йөрәк.

Йөрәгемне басар өчен,
Калмаган бер яшел яфрак,
Шәрә калган шушы имән
Язмышымдай тармак-тармак.

Көлләвекләр әйтерсең лә
Көк ярчыгы – сибелешкән.
Җирнең бу бит җан ачысы:
Миләш пешкән,
Миләш пешкән!

* * *

Нинди чаялык бу, шаянлык бу:
Җиргә ыргыганда шарлама,
Карап туеп булмый агышына,
Кайтавазы ерак тарала.

Сикерә дә, тау гайрәтен алып,
Кала бара тар бер инешкә.
Шауламый да, ашыкмый да хәзер –
Инешләргә шулай килешә...

Яшьлегемдә калды шарлама чак,
Тыныч кына челтер инешмен.
Шарламадан яшәү көче алып,
Үз көемне көйләп килешем.

* * *

Еракта бер яшен яшьнәгәндәй
Сызылып кына китсә җаныңнан
Билгесез бер сагыш көтмәгәндә,
Мин яшәгән илләр ягыннан,
Мин сагына икән диеп уйла,
Язмасам да сиңа мин хатлар.
Дөньяларга сыймый – хисләремне
Көк йөзендә яшен кабатлар.

Еракта бер яшен яшьнәгәндәй,
Көңелеңнән китсә кыелып
Билгесез бер шатлык көтмәгәндә,
Тапмый йончыганда җылылык,

Мин ярата икән диеп уйла,
Очрашмасак әгәр без кабат.
Китсәм җирдән әгәр, кояш, ай да –
Миннән сиңа булыр әманәт.

* * *

«Исән калсын өчен җирдә җаның,
Чыныгырга нинди утларда?
Уттан чыккач янып-яраланып,
Нинди җиңү белән котларга?» –

Сорамыйм мин ләкин, сорый калсам,
Яраларың кабат ачылыр.
Газабыңның, бәлки, соңгысыдыр,
Бәлки, әле яңа башыдыр.

Газабыңның, димен, соңгысыдыр,
Сөзләремне минем җил алсын.
Васыятьләр әйтер көн килсә дә,
Өмет вәгъдә иткән көн калсын.

Язсын сине, сары таңнан торып,
Хәерле көн белән котларга.
Синең көңелеңне аңлау өчен,
Янарга соң нинди утларда?

* * *

Яратса да мине патшалар,
Яратса да мине башкалар,
Кирәк миңа синең игътибар,
Күтәримме әллә ихтилал?!

Ялган тормыш, ахры, тормышым,
Гел кояшлы һава торышым
Булганда да,
Җанда гел буран,
Бураннарыма бер кил, уран!

Бөтен патшам, ахры, уйдырма,
Тәмле сөзләре дә туйдыра.
Сөймимендер – күрәм ялганын,
Сөйлимендер – бала-чагамын.

Күтәримме берәр ихтилал? –
Күккә очар дөньям, ихтимал...
Янгын ерактан ук күренә –
Чагылырмын, бәлки, күзеңә.

* * *

Урамнарга сыймый,
Алмагачлар
Безнең туебызны өткәрә.
Ак тәңкәләр сибә өстебезгә,
Ак тәңкәләр сибә эзебезгә –
Мондый бәхет сыймый күкләргә.

Баш очында йолдыз тәңкәләре,
Җиһан тынган, безгә таң калып.
Никах укый тын төн ай телендә,

Ишетәдер аны Сәрмәсән дә,
Ишетәдер аны Таналык.

Айлы көкнең фатихасын алып,
Мин бит җаның белән кавыштым.
Кочагыңнан берөк ычкындырма,
Ишетәмен йөрәк кагышыңда
Мин ашыккан вакыт тавышын.

* * *

Ниләр эшләтим соң җан ярасын?
Кысып төзсәм дә мин тешемне,
Онытылырга ул ирек бирми,
Сарыф кына итәм көчемне.

Мин тыймакчы булып, кабаланып,
Җилегемә өткән яраны
Бер чабуда өзәм, өрсәләнеп,
Өткәннәрем белән араны.

Ә ул һаман сыкрап туктамагач,
Шул ярама тагын тоз салам.
Дәрьяларга чумам, тотынырга
Булмаса да анда бер салам.

Өз җанымны өзем имлимен мин
Ай алдында, кояш алдында.
Акылымнан, юк, язасым килми,
Мин аңымда, Тәңрем, аңымда.

* * *

Минем көңел кителгән дип,
Кителмәгән җирнең чите.
Көңел, көңел,
Рәнҗешеңне
Син чир итмә, бер җыр итче!

Минем көңел кителгән дип,
Кояш та бит кителмәгән:
Таң калдырып калка таңда,
Яшәвенә өкенмәгән.

Минем көңел кителгән дип,
Дәрьялар да саекмаган.
Өпкә-рәнҗеш аша төгел,
Дөньяларга аек багам, –

Диеп шулай юанудан
Өчле төгел, көчле бит мин,
Төп-түгәрәк җир кебек мин,
Таңгы кояш төсле бит мин.

## Җир, көчемне кайтар!

Кара яздан тагын чәчәк чәчтем.
Җылы туфрак алып учыма,
Такмакладым:
Җир, көчемне кайтар,

Көчемне син җилгә очырма!

Чәчәкләрем чәчелеп чәчәк атсын,
Ашым аш һәм эшем эш булсын!
Гомер юлым иртә уңмаса да,
Һичьюгында юлым кич уңсын!

Кычытканлык кичә микән язмыш,
Гөрләп өсә кая карама.
Җиләк җыйганда да чагып ала,
Тоз сипкәндәй ачык ярага.

Синнән олы була алмыйм, җирем,
Кычытканнар өтеп алса да.
Тик шунысы гына өкенечле:
Көчем бик аз калган, калса да...

Җир, көчемне кайтар!
Таң калдырсын
Көннәремнән тезгән гөлләмәм.
Мин чәчәкләр генә бөләк итәр
Кешеләрем –
Өзе бер галәм.

* * *

Яшәө булып аңкый яшел өлән,
Сөю булып назлый гөл-чәчкә.
Нигә әле,
Дөнья матур, диеп
Онытылып китеп көлмәскә?!

Бер-берсенә генә сыенганга,
Каеннар да тормый сыгылып.
Гел кояшка гына сузылганга,
Өзләрендә ап-ак сылулык.

Көксел таулар – көксел борынгылык,
Өзе ерак, өзе якында.
Эчтән генә яна Янгантаулар,
Ташлары да кайный ялкында.

Салаваттан калган эзләрне бит
Кара урман белеп яшергән.
Яшен кылыч кайрый кыяларда,
Яулар уза минем хәтердән.

Юрөзәнгә төшеп агызсам да
Хәтер салган моңсу уйларны,
Төпләренә генә салып куяр,
Кара көймәс барыбер буйлары.

Җәннәт – монда,
Бер кат килеп көрсә,
Килеп җитә кунак яңадан.
Көч аламы җирем ничә гасыр
Агып яткан башкорт каныннан?!

Яшәө булып балкый яшел өлән,
Сөю булып аңкый гөл-чәчкә.
Нигә әле,
Дөнья матур, диеп
Онытылып китеп көлмәскә?!

## Көзге урман

Чың-чың гына чыңлый чуак көн,
Бу чуар көн – чуар өметем,
Бу аяз көн һәм мин – бербөтен!

Төшеримче, урман, сурәтең,
Сөнгән илһамымны көйрәттең,
Сөнми әле, сөнми гайрәтең.

Каендадыр урман алтыны,
Сылулыгы килә артымнан,
Мин язармын, ахры, акылдан!

Бик язасым килә акылдан,
Арыганмын инде көн туйлап,
Акыл – алтын, диеп гел уйлап...

Иркәләнеп кенә урманга,
Онытылу кирәк дөньядан,
Дөнья дигән кысан оядан.

Миләш, балан учак тергезсен,
Тергезсен дә әйтсен: «Тере син,
Җылыбыздан җаның эресен!»

Аркаланыйм әле имәнгә –
Сер бирмичә кара көйгәнгә,
Имән ирне җаным сөйгәнгә.

Артыш бирсен миңа ырымын,
Эчкә оялаган пәриләр
Ырымыннан аның кырылыр.

Килми минем әби буласым,
Ә чыршылар мине аясын,
Япь-яшь булып килә каласым.

Мин теләгән генә беркөнне
Акыл керер миңа яңадан
Урман акылыннан, аңыннан...

Ә әлегә торам һуш китеп:
Көз ул төгел мизгел карчыгы,
Һәрбер яфрак – кояш ярчыгы.

* * *

Печән өстендә кайтамын,
Юрта гына йөк атым.
Күз белән йолдыз ауларга
Йолдызлы күккә бактым.

Сәрмәсәннән рәхәт салкын
Тарала акрын гына.
Йөк өстендә тирбәләмен
Акрын гына, тын гына.

Эңгердә эри көн үзе –

Югалта балкышларын.
Җәйне алып кайтып киләм,
Җылытыр дип кышларын.

Хөрмәтләгән кебек мине,
Өйләр әнә ут ала.
Капка ачып керөемә,
Аш исе ихатада.

Йөк белән бергә авамын –
Әнкәй кочаклап ала...
Кайда икән шул чактагы
Печән чапкан кыз бала?!

Инә кортын югалткачтын,
Туздырылган көч – йортым.
Чит кеше мин, кердем менә
Су эчәргә бер йотым.

Туган тупса төпләрендә
Чит кеше мин, чит кеше.
Әллә качып калыйм микән,
Таныш кычыткан төсле?

Кычыткан да чакмый мине,
Бәләкәчтән ул – дустым.
Ишеткәндәй булам үзем
Әнкәемнең тавышын.

Китим әле, кеше-кара
Яшемне күрмәс элек.
Китим әле, капкаларга
Яңа йозаклар элеп.

Истәлекләр чыкмасыннар
Озатырга артымнан.
Мин печән ташыган арба
Чит кулларда... ватылган.

**Август**

Әй иркәли тынлык.
Ишетелә
Чәчәкләрдән орлык коелганы.
Челләләрдә көйгән каеннарның
Рәхәтлектән генә оеганы.

Үләннәрнең бал кортлары җыйган
Хуш исләре әнә аңкып тора.
Иген пешә, иген җитешә дип,
Алтын басулар да балкып тора.

Сискәндерә кинәт
Ботагыннан
«Тып-тып» итеп алма сикергәне.
Хәйран калып, бөтен дөнья тыңлый
Скрипка сызган чикерткәне...

Көнгә карап
Сабырлана акыл.
Талгын җылыта бит кояш әнә.

Җирдә бар нәрсә дә, кояш кебек,
Берәр генә данә, берәр данә.

Әй иркәли тынлык,
Чуак тынлык,
Уйларымның әле изрәгәне...
Өемнең дә тынычлыгы кайтыр,
Ачып куйдым көнгә тәрәзләрне.

## Бәйрәм

Җиңө көне
Кабатлыйдыр кебек
Әнкәемнең сөзен:
«Әй балам!
Кунак чакырабыз,
Әтиеңнең
Әрвахына бөген аш салам!

Капка ачмадым мин, эңгер төшкәч,
Ир-атларга, өзең беләсең.
Күрше-күлән килсә, куша идем:
«Ач, балам, – дип, – ишек киләсен...»

Җиңө көне!
Кала салютлары
Ишетелми безнең авылга.
Онытмый бит ләкин бер кеше дә
Токмач кисеп, ашын салырга.

Ишек какмый керергә дә мөмкин,
Уртак бәйрәм, уртак кайгы да.
Чыкмый ләкин кайгы күкрәкләрдән,
Ядрә кебек, җанга каныга.

Капкалары ачык кешеләрнең,
Әрвахлары, әйдә, шатлансын.
Аш саламын – бар авылга җитәр,
Ә сабыйлар атка атлансын!

Тәөге тапкыр атта җилгән көн дип
Исләрендә калсын!
Тантана!
Куанырлар әти белән әни:
Малай-шалай атка атлана!

## Эш өстәлем

Эш өстәлем!
Безнең ара ерак –
Кайчагында айлар үтмәле.
Мин чабамын вакыт белән бергә,
Эш бетмәле түгел, бетмәле...

Бер көн килеп сиңа баш теримен,
Хәл калмагач аяк атларга.
Дәваханәм бит син, намусханәм...
Өйрәнгәнмен синең шартларга.

Шартларың да тормышымдай гади:
Тигез тактаң, каты утыргыч,

Бер чынаяк чәй дә бирәр көмәч...
Сакчы миңа – тузан суырткыч.

Тузан кунса синең йөзләреңә,
Илһам килми миңа якын да.
Чөнки сөзем яшәү турында бит,
Чөнки сөзем үлем хакында.

Эш өстәлем!
Сиңа киләм гүя
Гомеремне кабат башларга...
Ә миннән соң синнән
Бишек ясасыннар,
Ашыкмасыннар тик ташларга.

## Эчтәлек


Шагыйрәнең су юлы. *Роберт Миңнуллин* ...

Тарпаннар ...................
Хәләл көчем ..................
Очсызландык ..................
Вакыт тамгалары ................
Әүлия чишмә ..................
«Сәнәгать тә сәнгать булса икән…» .......
Кырыслык ...................

**Күңел халәтләре**

Укучыма .................
Намус ..................
Илһам ..................
Өмет ...................
Фатиха ..................
Көнчеллек ................
Дан ....................
Хәйлә ..................
Шатлык .................
Кайгы ..................
Мәхәббәт .................
Мәкер ..................
Бәхет ..................
Зар ....................
Горурлык ................
Укучыма теләк .............
Сөйләшәмен Кояш телендә ...........
XX гасыр белән хушлашканда... ........
«Сабантуйдан башын алып качты...» .....
Һава монологы .................

**Салаватнамә**

Юрөзәндә июнь пейзажы .........
Тамырлар ................
Тавыш бирче, Салаватым! ..........
Салават кылычы ...............
Туу (*Поэма*) ................
Иҗат ........................
Иртәрәк тә түгел, соң да түгел... .........
Кояшлы галәм ..................
Мөхәррир ....................
«Шундый бер көн килер...» ...........
«Мөлдерәпләр миңа карамачы!..» ........
«Бу галәмдә әгәр Ходай булса...» ........
Гомер музыкасы ................
Шәҗәрә .....................
Су юлы ......................
Хатын ......................
Балага әйткән сүзләр ...............
«Җир-сугынам минем...» ............

  Каенлыкка кайтам ................
  «Калдырмагыз безне!» .............
  Ант ........................
  «Ходай миңа мөһер суккан...» ..........
  Минем илем ...................
  Көнекмә .....................
  Халкым өзе таный ................
  Акмулла .....................
  Тагын да җыр турында .............
  Бөздәгем .....................
  Туганнарым ...................
  «Алтын йөгертелгән сөзләреңә...» ........
  «Көткән идем синнән...» ............
  «Күзеңнең дә синең...» .............
  Соңладың! ....................
  «Ялгызлыкка качтым бөген таңда...» ......
  «Шагыйрьләр ул, бер сандугач булып...» ....
  Җырланыр җыр ................
  Хәбәр көтәм ...................
  Эволюция ....................
  Яңа ел бәйрәменнән соң ............
Качак ......................
Ялвару ......................
«Коен дисәң, коен төгел...» ...........
«Эчләремә генә сыялмыйча...» ..........
«Күзләреңнең явын алсаң иде...» ........
Сак-Сок .....................
«Йолдыз белән йолдыз аралыгы...» .......
«Укталам да...» .................
Көнчелгә .....................
«Мәкер кабер казый...» .............
«Акны ак дип...» ................
«Кул тимәгәч...» ................
«Һәр кешегә кояш булып булмый...» ......
«Өзе бәхет бит ул...» ..............
«Кеше туа...» ..................
Сөйләшә .....................
«Минем кайгым...» ................
Кабер ташындагы язудан ............
«Күккә бактым...» ................
«Зәп-зәңгәр күк...» ................
«Байлыгым юк минем...» ...........
«Утка – ут...» ..................
Җил йокласа... .................
«Яңа тәпи баскан сабый кебек...» ........
Мәхәббәт .....................
Тарихи хәтер ..................
Мәрсия ......................
«Ике бөре чыкты юлга...» ...........
Кыңгырау (*Поэма*) ................
Кан басымы ...................
«Әй ялгызлык...» ................
Сагындыра ....................
Син туктама, Вакыт! ................
Идеология ....................
Гайсә пәйгамбәрнең кешеләргә эндәшүе ....
Коррида .....................
Өйрәнергә... ...................
  Каралама ....................
  Җиһан моңы ..................
  «Алтын кояш...» ................
  Җыр .......................
  «Арага дошман төшмәде...» ...........
  «Мин яшердем сине шигыремә…» .......
  Мәңгелек моң ..................
  Ул кояшка китеп бара иде... ..........
  Рәшит Назаров .................
  Очу .......................
  Дала .......................
  Ил агасы ....................

О, Венера! ....................
Динис Бөләковның якты истәлегенә ......
Алма җыя хатын ................
«Кичерә бел...» .................
Синең тавыш ..................
Эчәмен әрем суын ...............
Соңгы чара ...................
Кара каен ....................
Ауды имән ...................
Юксыну .....................
Туган көнемдә өз-өземә ............
Кош юлы ....................
Ялгызлык ....................
«Өйрәнелгән, көнегелгән...» ..........
«Сабый бала сыман...» .............
«Тукта, Скрипка!..» ..............
«Төнге күктә ай мөлдери...» ..........
Ут эчендә бию ..................
«Күктәй төпсез фәлсәфәләр...» ........
«Кулым бармый...» ..............
«Буйсынганда кемнәргәдер...» .........
«Мин кыяга мендем...» ............
Күләем .....................
«Аңлыйсыңдыр мине...» ...........
«Яшен мине тагын эзләп тапкан...» ......
Алтын таҗ ....................
«Куанычтан кычкырамын...» .........
Дала төне ....................
Көнем белән төнем ...............
«Чоңгылларга чумып алып чыктым...» .....
«Сиңа тагын ниләр кирәк, язмыш?..» ......
«Дошманыма рәхмәт инде!..» ..........
Шомлы төндә ..................
«Сиңа сөзем кирәк түгел...» ..........
Алтын сарай ...................
Йолдызлы шәл .................
Бакчадагы өйдә ялгызым ...........
«Үткән көннәр миңа...» ............
«Кояш батты...» ................
«Каеннан өзелә, өзелә...» ............
«Ах, чаганның...» ................
«Мин сине урлыймын...» ...........
«Калын боз каплаган...» ............
«Тәрәзләрдән күккә карап ятам...» .......
«Өзгәләнмә, күңел...» ..............
«Ишегеңнән йөгереп чыгып киттем...» .....
«Ташка бәргәләнде башкайларым...» ......
«Күтәм әле...» ..................
Лачын исемле эткә ...............
Аяк тавышларың тупсада... ..........
«Кыска бер мәл...» ...............
«Зәңгәр дулкыннарын салмак кага...» .....
Кайт, туганым! .................
«Ай нурында атлар сынлана...» .........
«Кара урман арасында...» ............
Аккош биюе ...................
Сагыш ......................
«Яшәү белән мин үлемнең...» ..........
«Онытасың бергә кичкән...» ...........
«Караңгы төн йота буй-сыныңны...» ......
Чаукалык ....................
«Мин юк синең өчен...» .............
«Күкне болыт басты...» ............
«Күкрәгеңә тамды күз яшьләрем...» ......
«Ниләр эшләтим соң җан ярасын?..» .....
«Алтын сәгать таккан таныш…» ........
Томана .....................
Сиңа гына атап җыр чыгардым ........
Кое .......................
Янгын ......................

«Җиргә кемнәр...» ................
«Юлыма тоз сипмә...» .............
«Таң – тантана гына...» ............
Туганлык ....................
«Ачуың булды ишекне...» ..........
Ком сәгате ...................
«Кысрыклый тормыш!..» ...........
Тигәнәк .....................
Тигезләмә ....................
Кардиоөзәк ...................
«Мин арыдым, Раббым...» ..........
«Сафтыр диеп...» ...............
Шайтан таягы .................
Актриса язмышы ...............
Алма елы ....................
«Нигә өзгәләнәм?!» ..............
Кеше – сер ...................
Цунами .....................
Җир әйләнә... .................
«Өз вакыты җитми, кояш чыкмый...» .....
Дөнья – хәрәкәттә! ...............
Кендек .....................
Култамга ....................
Сандугач ул таңда гына сайрый ........
Сиңа дәшәм, сөеклем! .............
Йокысыз төн ..................
«Гомер елларымның төбәсенә...» ........
«Кендегеңне ачма...» .............
«Яңа гасыр...» .................
«Түп-түгәрәк Җир калдырдың...» .......
Печән чапканда... ................
Ватаным .....................
«Халык арасында...» ..............
Ахирәтем Мәрьям апа Гималовага .......
Кичә генә… ...................
Абдрахман ....................
Соңгы инсан ...................
«Гасыр уртасында туганмын…» .........
Урман ......................
Бикле көймә ...................
Ике дустым бозылышканда… ..........
Ятим дөнья ...................
«Бөрене соң кем яратсын...» ...........
«Гомер тузды...» ................
Тынлык .....................
Миләш пешкән .................
«Нинди чаялык бу...» .............
«Еракта бер яшен…» ...............
«Исән калсын өчен...» .............
«Яратса да мине...» ................
«Урамнарга сыймый...» ............
«Ниләр эшләтим соң…» ............
«Минем көңел...» ................
Җир, көчемне кайтар! ...............
«Яшәө булып аңкый...» ............
Көзге урман ...................
«Печән өстендә...» ................
Август ......................
Бәйрәм ......................
Эш өстәлем ...................
Литературно-художественное издание

**Тугузбаева** Факиха Хадыевна
(**Тугузбаева** Факия Хадыевна)

## Путь к жизни

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Тугызбаева** Факиһа Һади кызы
(**Тугызбаева** Факия Һади кызы)

# Су юлы

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Рәссамы *А.Р.Хисмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.04.2010.
Форматы 70х90 1/32. Шартлы басма табагы 8,78.
Тиражы 2000 д. Заказ О-436.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru. e-mail: tki@tatkniga.ru.**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан,  Декабристлар урамы, 2.